PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№10 (298) – ОКТЯБРЬ 2016

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Балык Бистәсендә – балыкка, Теләчедә – кондызга

«Саҗидә апа» исемле тыюлык

Алабуга тарихы кайдан башлана

КАНАТЛАР КУЙГАН ХЫЯЛ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары: Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Троицкая
Чыгарылыш мөхәррире: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Ольга Туманская
Линар Закиров
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Веб-редактор: Олеся Бондаревская, bond@tatmedia.com
Авторлар: Алинә Идрисова, Катерина Котова, Альберт Нигамаев, Ксения Семина, Айсылу Хаҗиева, Гадел Хәиров, Фаяз Хуҗин, Ольга Шмелёва
Фотографлар: Солтан Исхаков, Ната Смирнова, Александр Эшкинин
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Әхмәрова
Тышлыкта – Ирек Вилданов. Александр Эшкинин фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды:**

420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № М-2646

Басарга кул куелды: 20.10.2016

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе: Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com
Коммерция директоры: Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com, тел. (843) 222-09-76
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе: Юлия Фәсәхова, тел. (843) 222-06-05
Махсус проектлар бүлеге белгече: Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru
Бухгалтерия: Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ТАБИГАТЬ ТАРАФЫННАН РАСЛАНГАН

Без кайчак ниндидер вак-төякләр аша иң әһәмиятле нәрсәгә төшенәбез: гафу итмәстәйләрне дә кичерергә кирәк икән – йорт-җиреңә тынычлык иңәр, чөнки үпкә-рәнҗеш эчтән генә үзебезне үк – «ашарга», ә үч алу ниятләре психикабызны бозарга сәләтле. Кешене нәрсәдер өчен генә яратырга ярамый – шул чакта гына безне дә сөярләр, үз итәрләр. Хисләребезне бәяли алмаганнарны җиңел күңел белән җибәреп, иреккле калырга кирәктер. Хәлебездән килгәндә, хәтта таныш булмаганнарга дә ярдәм кулы сузыйк – һәм көчебез беткәндә бөтенләй ят кешеләр безгә булышыр. Чөнки ничек кенә итсәң дә, кай тарафтан гына карасаң да – яхшылык һәрвакыт кире әйләнеп кайта, барлык үзгәрешләр дә яхшылыкка илтә. Бу тормыш тарафыннан да, табигать тарафыннан да расланган. Ел фасыллары алмашынуына гына күз салу да җитә. Кемдер җәй үтүгә пошына. Ә нигә? Табигатьнең җете төсләренә күмелгән уңышка бай көз фасылы нәрсәсе белән начар? Карның эреп агуы һәм кышның үтүе, алда табигатьнең яз дип аталган уяну фасылы көтүе начармыни? Яңгырдан соң ялтырап кояш чыгуын күрү, шәфәкъ утларын беленер-беленмәс таң нурлары алыштыруын тою рәхәт түгелмени? Һәр нәрсәдән дә уңай якларны табарга мөмкин. Әгәр яман уйларга батмыйча, үткәннәргә үкенмичә, билгеле булганча, иң зур гөнаһ саналган моң-зарга бирелмичә яшисең икән. Һәм гөнаһ булган өчен генә түгел, бәлки моң-зарга күмелеп без янәшәбездәге матурлыкны, яхшы гамәлләрне күрми башлаганга да. Һәм тагын әле, ниндидер яңалыкка шатлануга караганда, зарланып утыру җиңелрәк булганга да. Бөтен бәла шуннан: тирә-юньгә күз ташлап, иңнәребезне киереп, көлдән күтәрелеп, яңа көнгә шатланырга теләмәүдән башланадыр. Безнең бүгенге геройларыбыз кебек елмаерга, киртәләргә карамастан, үз дигәнебезгә ирешергә өйрәник. Җаныбыз-рухыбыз хезмәт итсен, чөнки ул көн-төн, армый-талмый хезмәт итәргә тиеш.

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы: «Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче: «Татмедиа» АҖ

420097, Казан, Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
864 сум 24 тиен

Солтан Исхаков фотолары

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Республиканы яхшы якка үзгәртәбез
Әйләнә-тирәне үзгәртеп, ничек итеп үзебезгә яхшырырга

6. Суның якынаюы
Сулыкларны саклау елында Татарстанда ике дистәдән артык яр буе төзекләндерелде

16. Бакчабыздагы виноград тәлгәшләре
Татарстанда виноградны кайда үстереп була

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

26. Орден ияләре
Александр Лаврентьев вертолет заводын ничек алга җибәргән

28. Саҗидә Сөләйманова юбилее көннәрендә
«Кече Ватан патриотлары» шагыйрәнең туган көнен ничек үткәрделәр

34. Шифаханә-курортларга сәяхәт
Үзебезнең Карловы Вары кайда урнашкан

40. Татар ашлары
Дәүләт серенә тиң рецепт кемдә саклана

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

46. Картлык – шатлык
Фотохудожник Солтан Исхаков һәм аның җиңү яулаган фотосы

50. «Хәтәр» картлар
Элеккеге тоткыннар картлыкларын кайда үткәрәләр

54. Ата-аналарыгызга шалтыратыгыз. Һәм аларны кичерегез
Йөрәктәге сызлану-рәнҗешләрне ничек басарга...

56. Татарстан аксакаллары
Зирәклек кайдан килә

58. Канатлар куйган хыял
Ирек Вилданов самолетын ничек төзегән

64. Кызыклы татар авыллары
Казансу кайдан башлана

68. Татар-халык йолалары
Татар фольклоры Кырымга нигә кирәк

72. Алабуга тарихы
«Шайтан каласы» элек нәрсә булган

76. Башкала зиратларының киләчәге
Яңа бистә зиратын кем туздырган?

80. Сәүдәгәрләрнең соңгы сәламе
Элекке чакларны хәтерләгән йортлар

84. Мөдәррис Әгъләм
«Ахыргача барам...»

86. Китап киштәсе
Музыкантлар нинди китаплар укый

96. Баллы күлләр
Татарстанча шотланд балладасы

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

30.09

Герман Греф, «Саклык банкы» ГАҖ идарәсе рәисе, – Сочидагы Халыкара инвестиция форумында:

– Татарстанда федераль Хөкүмәт тәкъдим иткән барлык механизмнар да менә дигән итеп эшләп китте. МИЗда, АСИҮТка кагылышлы бөтен нәрсәләр дә, технопарклар да. Татарстанда югары дәрәҗәдә халыкара ярышлар үткәрелде, алар төбәктәге социаль инфраструктураны күтәрде. ТРндагы Иннополис турында бар халык сөйли – димәк, традицион сәнәгатьтән иң заманча технологияләргә инвестицияләр җәлеп итүгә күчеш маневры нәкъ менә үз вакытында ясалган. Бу, идарә итү югары профессиональ дәрәҗәдә оештырылганда, төбәк хакимиятенең ничек уңышлы эшли алуына бер мисал булып тора.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

16.09

Виталий Мутко, РФ спорт министры:

– Без ел саен республика территориясендә 30га якын спорт чарасы үткәрәбез. Казан Россиянең үзенчәлекле визит карточкасына әверелде. Халыкара оешмаларга бирелгән бөтен заявкалар рәхәтләнеп кабул ителә, чөнки Казан – Россия һәм дөнья спортының ышанычлы партнёры.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

11.09

Нонна Гришаева, актриса, – XII Казан халыкара мөселман киносы фестиваленең ябылу тантанасында:

– Дөресен әйткәндә, мин бирегә аерым бер дулкынлану белән килдем, чөнки Казан – бабаларымның шәһәре: минем бабамның әтисе Гордий Семенович Саблуков, көнчыгышны өйрәнү буенча күренекле белгеч, Казан рухани академиясе профессоры, исламны өйрәнүче, Коръәнне беренче тәрҗемә итүче булган, ә соңыннан патша аны Казанский фамилиясен биреп олылаган.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Дөньяны үзгәртеп, **НИЧЕК** үзебезгә дә яхшырырга

Яр буйларын **КАЙДА** матурлаганнар

Виноградны безнең якларда **НИЧЕК** үстерергә

БЕЗ РЕСПУБЛИКАНЫ ЯХШЫ ЯККА ҮЗГӘРТӘБЕЗ

Рөстәм Миңнеханов, әйләнә-тирәне үзгәртеп, үзебезнең дә уңай үзгәрешләргә омтылуыбыз турында.

ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ ТР ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ЮЛЛАМАСЫННАН

Республиканың социаль-икътисадый үсешенең уңай тенденцияләре, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны, тынычлык һәм татулыкны саклау безгә иң мөһим бурычны – кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшырту мәсьәләсен хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Озак еллар дәвамында уңышлы эшләү нәтиҗәсендә үзенчәлекле капитал – ышаныч капиталы формалашты. Без халык һәм партнерлар алдындагы барлык йөкләмәләребезне үтибез, актив рәвештә республиканы яхшы якка үзгәртәбез, үзебез дә уңай үзгәрешләргә омтылабыз.

Милләтара һәм конфессияара тынычлык һәм татулык – республикабызның конкурентлыкта өстенлеге ул. Дөньядагы тискәре тенденцияләр, шулай ук алар белән бәйле килеп туган каршылыклар фонында болар аеруча әһәмият ала.

Халкының булышлыгыннан һәм шәхсән катнашуыннан башка Татарстан уңышлы үсә алмый. Дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарына халык белән эшләүнең нәтиҗәле формаларын табарга, киң җәмәгатьчелекне, шул исәптән территориаль иҗтимагый җирле үзидарәләрне республикада перспективалы проектларны тормышка ашыруга җәлеп итәргә кирәк.

Хакимият органнары тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне электрон рәвешкә күчерү эшен дәвам итү мөһим. Бу – коррупциячел күренешләрне киметүнең иң нәтиҗәле чарасы. Моннан тыш, күпфункцияле үзәкләр күрсәтә торган хезмәтләрне арттыру төрләр белән турыдан-туры элемтәгә керү зарурияттен юкка чыгарырга мөмкинлек бирә. Аларның эшчәнлегенә тормыштагы төрле хәлләр буенча «бер тәрәзә» принцибын кертү бурычы тора.

Республикабызда 2017 елны Экология һәм иҗтимагый киңлекләр елы дип игълан итү яшәү өчен уңайлы мохит тудыру юнәлешендә башланган эшне дәвам итү булып тора. Россиядә Экология елы игълан ителүне исәпкә алып, без шәһәребездә һәм авылларыбызда агачлар-үсемлекләр утырту, сулыкларны чистарту, яр буйларын төзекләндерү эшен дәвам итәчәкбез. Йорт яны территорияләренә аерым игътибар бирү зарур.

Россиянең тышкы сәясәте юнәлешләре кысаларында чит ил партнерлары белән хезмәттәшлек итүне арттыру республиканың уңышлы үсешенә нигез булып тора. Ватандашларыбыз белән элемтәләрне ныгыту эшен дәвам итәбез.

Нефть-газ-химия комплексы Татарстан икътисадының әйдәп баручы өлкәсе булып тора. Нефть чыгаруны арттыруны, шулай ук нефтьне максималь дәрәҗәдә үзебездә эшкәртүне максат итеп куябыз. Югары үзле нефть чыгару, түбән үткәрүчән туплагычлы һәм сланец катламлы нефть ятмаларын эшкәртү өлкәсенә инновацияләр кертү актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала.

Агымдагы елның ахырында «ТАИФ-НК»ның Авыр калдыкларны тирәнтен эшкәртү комплексын эшләтеп җибәрү, ТАНЕКОда автомобильләр өчен товарлыклы автомобиль бензины алырлык икенчел тирәнтен эшкәртү процессы комплексын этаплап тапшыру, республикада чыгарыла торган нефтьнең 2/3 өлешен эшкәртергә мөмкинлек бирергә тиешле ЭЛОУ-АВТ-6 беренчел нефть эшкәртү җайланмасын эшләтеп җибәрү **нефть тармагының өстенлекле бурычлары булып тора.**

«Түбән Кама Нефтехим»да күләме буенча хәзерге вакытта гамәлдәге җитештерүгә тәңгәл пиролиз продуктларын эшкәртү буенча үзара бәйле производстволар һәм ЭП-600 – этилен җитештерү буенча яңа производство төзү – **иң әһәмиятле бурыч булып тора.**

Газ-химия тармагында «Аммоний-2» проектын тагын да үстерү, шулай ук «Казан Органик синтез»да эшләп чыгарылган продукция күләмен икеләтә арттыру буенча перспективалы проектларны тормышка ашыру – **безнең якындагы киләчәккә планнарыбыз.**

Республиканың машина төзү комплексында КАМАЗда алып барылган җитештерү күләмен саклап калу эшен аерым билгеләп үтәсем килә, предприятиенең киләчәккә планнарында – яңа кабиналар һәм двигательләр чыгару, Милли технологик инициатива кысаларында проектлар эшләү; «Форд-соллерс» предприятиеләрендә автомобиль һәм автокомпонентлар экспортлауны киңәйтү; Горький исемендәге заводта заказлар портфелен формалаштыру; Казан вертолет заводында «Ансат» һәм Ми-38 вертолетларын серияләп чыгару, шулай ук еракка очыш авиациясен үстерү программасы кысаларында Казан авиация заводын тулысынча яңарту.

Республикада масштаблы проектларны тормышка ашыру инфраструктураны алгарышлы үстерүне таләп итә. Россия Хөкүмәтенең, шәхсән Дмитрий Анатольевич Медведевның ярдәме белән «ИнноКам» Территориаль аерымланган инновация үзәге концепциясен гамәлгә ашыру кысаларында Чаллы шәһәрендә алгарышлы үсеш территориясе булдыру турында карар кабул ителде. Ул киләсе 10 елга илебез икътисадына этәргеч бирүче үсеш ноктасы буларак билгеләнде.

Дөньякүләм дәрәҗәдә IT-университет эшләп килүче Иннополис шәһәренә без зур өметләр баглыйбыз. Бүгенге көндә бу югары уку йорты абитуриентлар кабул итүнең сыйфаты ягыннан илебездә иң яхшы ун университет арасында. Иннополиска резидентлар һәм инвестицияләр җәлеп итү буенча эшне көчәйтергә кирәк.

Республиканың барлык индустриаль мәйданчыклары объектларын нәтиҗәле тутырыга, шулай ук үз производствосын ачып җибәрү өчен Россия төбәкләренең берсен сайлау алдында торган яңа инвесторлар белән эшләүгә аеруча зур игътибар бирергә кирәк.

Стратегик әһәмияткә ия бурычларны хәл итү өчен транспорт-логистика инфраструктурасының тиешле дәрәҗәдә үсеш алган булуы мөһим. Свияжск төбәкара мультимодаль логистика үзәгенең конкурентлыкка сәләтле өстенлекләрен нәтиҗәле файдаланырга кирәк.

Мәскәү – Казан югары тизлекле тимер юлы магистрален төзү проектын тормышка ашыру икътисад үсешенә яңа этәргеч бирәчәк. Ул безнең бизнес вәкилләренә яңа элемтәләр урнаштырырга һәм зур агломерация базарларын якынайтырга, ә Татарстанга – инвестицияләр җәлеп итүне арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Инновацияле икътисад булдырмый торып, республика алдында торган бурычларны хәл итү мөмкин түгел. Республикада инновацияләрне эшләү һәм коммерцияләштерү өчен барлык шартлар булдырылган. Әлеге процесска, инновацияләр кертү нәтиҗәләре буенча стимуллаштыру системасын булдырып, күбрәк предприятиеләребезне тарту тиеш.

Предприятиеләргә үз интеллектуаль активларын капиталлаштыру, уникаль эшләнмәләрне балансларына куюя шарт. Бу – кредит рейтингын үстерү һәм инвестицияләр җәлеп итү мөмкинлекләрен арттыру өчен зур резерв булып тора.

Кече һәм урта бизнесны үстерү элеккечә өстенлекле юнәлеш булып тора. Административ киртәләрне киметү буенча без планлы төстә эш алып барабыз. Моңа республиканың биш эре шәһәрендә ачылган бизнес өчен күпфункцияле яңа үзәкләр эшли башлавы ярдәм итә. Әлеге тәҗрибәне башка муниципаль берәмлекләрдә дә куллана башларга вакыт.

Кече һәм урта бизнесның реаль секторда үсешенә муниципаль сәнәгать мәйданчыклары зур этәргеч бирә. Хәзер республикада шундый илле ике мәйданчык бар. 2020 елга аларның санын йөзгә җиткерү бурычы тора.

Авыл хуҗалыгы җитештерүе нәтиҗәлелеген арттыру эшен дәвам итү зарур. Уңай тәҗрибәләрне гамәлгә кертү нигезендә артта калган коллективларның үсешенә этәргеч бирергә кирәк.

Республика шәһәрләрендә өч агросәнәгать паркы эшли. Федераль дәрәҗәдәге «Агромир Казан» логистика үзәген төзү эшләре алып барыла. Шулай ук бездә шәһәрләрдә һәм район үзәкләрендә фермер хуҗалыклары һәм шәхси хуҗалыклар продукциясен сату өчен кече агропарклар төзү проекты эшләнде.

Товар җитештерүчеләребез һәрчак үсештә, һәм шулай ук республикадан читтәге товар җитештерүчеләр арасында да көндәшлеккә сәләтле булырга тиеш. Инде гамәлгә куелган «Милли сәүдә маркасы» проекты моңа ярдәм итәргә тиеш. Безнең брендның киң танылуы һәм кулланучылар тарафыннан продукциянең югары сыйфатлык күрсәткечe буларак кабул ителүе гаять мөһим.

Республикада меңгә якын бакчачылык ширкәте бар. Бакчачыларга тиешле уңайлыклар тудыру – хакимият органнарының бурычы. Сүз иң гади ихтыяҗлар турында бара: болар – бакчаларга су һәм ут кертү, юллар уздыру, чүп түгүне оештыру.

Яңа технологияләрне күпләп куллану, яңа профессияләр һәм белгечлекләр барлыкка килү мәгариф системасын, аеруча һөнәри белем бирү системасын вакытында камилләштерү таләбен куя. **Барлык белем бирү программалары да икътисад ихтыяҗларын исәпкә алып төзелергә тиеш.**

Мәгариф оешмасы һәм предприятиесе катнашында квалификацияле кадрлар әзерләү бурычларын хәл итүдә төзелүче ресурс үзәкләре челтәре ярдәмгә килә. Быелга республикада мондый егерме үзәк төзелгән, якын арада аларның санын утызга җиткерергә ниятлибез.

Конкурентлыкка сәләтлелекне мәгариф эшчәнлегенә дөнья стандартларын кертү өлешендә методикага нигезләнгән һәм системалы эш алып бару тәэмин итәчәк.

Киң колачлы проектларны гамәлгә ашыру республика Хөкүмәте, предприятиеләребез һәм әйдәп баручы югары уку йортлары ярдәме белән махсуслаштырылган үзәкләр төзүне таләп итә: машина төзү буенча – Чаллыда КФУ һәм КАМАЗ катнашлыгында; нефть химиясе буенча – Түбән Камада Технология университеты, нефть химиясе һәм нефть эшкәртү предприятиеләре катнашлыгында; нефть һәм газ чыгару буенча – Әлмәттә, КФУ һәм Татнефть компаниясе базасында Югары нефть мәктәбе ачып.

Татарстан өчен телләр өлкәсендәге сәясәт аеруча әһәмияткә ия. Рус телен укытуны камилләштерүгә моңа кадәр дә җитди игътибар бирә идек, киләчәктә дә шулай дәвам итәчәкбез. Моннан тыш, заман безнең алда чит телләр, иң беренче чиратта, инглиз телен үзләштерү дәрәҗәсен яхшырту бурычын куя.

Шул ук вакытта, милли мәгариф безнең бәхәссез өстенлекләребезнең берсе булып тора. Быел 2030 елга кадәр Милли мәгарифне үстерү концепциясе кабул ителде. Без Татарстан алар өчен туган йортка әйләнгән барлык халыклар телләрен саклау һәм үстерү юнәлешендә эшләргә тиешбез.

Яшәү һәм эшләү өчен уңай мохит булдыру элеккечә безнең иң зур бурычыбыз булып тора. Агымдагы елда без соңгы биш ел эчендә халыкның өчтән ике өлешенең торак-көнкүреш шартларын яхшыртырга мөмкинлек биргән республика программаларын гамәлгә ашыруны дәвам итәбез.

Халыкның тормыш сыйфатын яхшыртуда сәламәтлек саклау тармагы аерым роль уйный. Югары технологияле медицинада без уңай нәтиҗәләргә ирештек. Ресурслар туплауда сайлап алынган стратегия кадрлар потенциалын һәм кыйммәтле медицина җиһазларын нәтиҗәле файдаланырга мөмкинлек бирде.

Сәламәтлек саклауның республика гражданнары барыннан да ешрак мөрәҗәгать итә торган башлангыч звеносы эшен камилләштерү таләп ителә. Дәүләт сәламәтлек саклау тармагының көндәшлекле өстенлеге пациентларга игътибарны арттыру һәм югары сыйфатлы хезмәт күрсәтү булырга тиеш.

Сәламәтлек саклау культурасы күнекмәләре формалаштыручы профилактика чараларына, гражданнарны үз сәламәтлекләрен саклау һәм аның турында кайгыртуга кызыксындыру уятуга аерым басым ясау үтә мөһим.

Президент Юлламасының тулы тексты белән ТР Президенты сайтында танышырга мөмкин.

PRESSA.RU

... Гомуми белем бирү мәктәпләре белән тәэмин итү Сыер абзарларын капиталь төзекләндерү Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү Балалар бакчалары төзү Яшүсмерләр клубларын капиталь ремонтлау Спорт мәйданчыклары төзү «Уңайлы мохит» программасы Социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмаларын капиталь ремонтлау Балалар сәламәтләндерү лагерьларын капиталь төзекләндерү **Сулыкларны саклау елы** Мәдәният объектларын капиталь ремонтлау ФАПлар төзү, сәламәтлек саклау объектларын капиталь ремонтлау Ветеринария хезмәте күрсәтү биналарын төзү Ветеринария берләшмәләрен һәм авыл хуҗалыгы идарәләрен капиталь төзекләндерү Участок ветеринария пунктларын төзү һәм капиталь төзекләндерү Силос-сенаж траншеяләрен төзү Яшелчә саклагычларын капиталь ремонтлау Тузган торак Социаль ипотека Күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү...

ПРЕЗИДЕНТ ПРОГРАММАЛАРЫ.
НӘТИҖӘЛӘР

БАЛЫК БИСТӘСЕНДӘ – БАЛЫККА, ТЕЛӘЧЕДӘ – КОНДЫЗГА

Татарстанда быел игълан ителгән «Сулыкларны саклау елы»нда күпчелек районнардагы елга-күлләрнең яр буйларын тәртипкә китерделәр. Алар халыкның иң яраткан ял урыннарына әйләнде. Олыларның теләк-тәкъдиме бер: бу матурлык озакка саклансын иде. Җил-яңгырдан түгел, ә үзебезнең арадагы куллары кычытып торучы бәндәләрдән.

БАЛЫК БИСТӘСЕ

БАЛЫККА – ҺӘЙКӘЛ

Без килгәндә Балык Бистәсендәге Кама елгасы яр буенда төзүчеләр чөгә балыгының һәйкәлен урнаштыралар иде.

– Ул районыбыз гербында да чагылыш тапкан, – дип аңлатты безгә район мәдәният бүлеге башлыгы Наталья Чернова. – Яр буе проектын төзегәндә, кызу гына бәхәсләр булып алды, халык та катнашты, алар балык тематикасының күбрәк булуын теләде. Күреп торасыз, тәкъдимнәрен исәпкә алып, һәйкәл дә корып куйдык. Совет чорында бу урында пристань булган, пароходлар туктаган, киптерелгән балык, карбыз сатылган. Кайчандыр тау башында ак храм булган, аны 70нче елларда шартлатканнар. Хәлле кешеләр шул урынга агач чиркәү төзетеп куйды, – диде ул.

Яр буена керә торган капкада да балыклар «йөзә». Әңгәмәдәшебезгә аның металлдан эшләнүе бик ошый, буяганчыга кадәр, ул тагын да матуррак иде, ди. Наталья ханымның металлга мәхәббәте көчле булып чыкты, без моны сөйләшү барышында абайлап алдык.

– Мин тумышым белән Биектау районының Чебакса авылыннан. Ул беркайчан да крепостной бәйлелектә булмаган, анда гомер-гомергә тимерчеләр яшәгән.

– Димәк, металлга тартылуыгыз менә кайдан килә! – дип үзебезчә фаразлап куйдык без.

Фото: Александр Эшкинин, Ната Смирнова

ҖИЛДӘН ЫШЫКЛЫЙ ТОРГАН УТЫРГЫЧЛАР

Балык Бистәсендәге яр буен ике ел элек бетонлап, быел архитектур формалар белән баетканнар. Бетонга сары һәм ак төстәге буй-буй калын сызыклар сызылган. Халык архитекторларга аларны дулкын һәм балыклар рәвешендә ясарга тәкъдим иткән, әмма белгечләр үз дигәннәрендә нык торганнар. Монда тагын таяктай кукраеп торучы яктырткычлар да бар. Озакламый җилдән саклый торган беседкалар да урнаштырылачак, җил кайсы яктан исә, утыргычны шул якка борып куеп, ышыкланырга мөмкин булачак.

– Яр буе халыкны үзенә магнит кебек тартып тора. Төзелешне әби-бабайлар да контрольдә тотты, дисәк тә була, кайдадыр җитешсезлек тапсалар, шундук бармак төртеп күрсәтәләр иде. Кичен монда кеше бик күп була, бала коляскалары тартып әниләр дә чыга. Җәен яр буе өстендә урнашкан хастаханәдән дә һава суларга төшәләр. Халыкны парк культурасына өйрәтергә кирәк әле. Монда тормыш концерт вакытында гына түгел, даими кайнап торырга тиеш, – ди мәдәният бүлеге җитәкчесе.

БАЛЫК БИСТӘСЕМЕ, МУРМАНСКИМЫ?

Ел саен июль уртасында монда балыкчы көне үткәрелә. Иртәнге биштә олысы-кечесе, хәтта хатын-кызлар да балык тотарга килә. Соңыннан кемнең күпме тотканын санныйлар. Берничә казанда балык шулпасы әзерлиләр, «су аучылары» һәм аларның хатыннары, сәхнәгә менеп, балыкта булган мәзәк хәлләрне сөйлиләр.

Су янында ук, бетон диварда безгә кабат балыклар «очрады».

– Мин Интернетта граффити ясаучыларны эзләп таптым да безнең яр буен бизәргә тәкъдим иттем. Егет-

Автор:
Линар Закиров

– Чыннан да, шулай килеп чыга икән бит! Балык Бистәсенә 16 яшемдә килдем. Ул вакытта монда зәркән эшләнмәләр һәм җияк (коклюшка) ясау сәүдәсе киң таралган иде. 5–6 ел элек үзебезнең хатын-кызлар, яр буендагы бер почмакка урнашып, коклюшкалар ясый башладылар, – диде Наталья Чернова.

Онытыла барганны кире кайтару дигәннән, яңа яр буенда борынгы уеннарны да уйнатырга булганнар. Башта городки уенына тукталганнар. Әмма кеше күп җирдә куркынычсызлык кагыйдәләрен саклау таләп ителгәнгә, бу фикердән баш тартып, халыкка ходулида йөрергә мөмкинлек тудырганнар.

PRESSA.RU

ләр миңа башта төрле хәшәрәтләрнең сурәтләрен җибәрделәр, алар шуның ише фантазияне ярата бит. Ә мин аларга шыртлака (ерш), судак кебек балыкларның сурәтләрен күрсәттем. Аларга бу эш ошады. Инстаграмнан күренгәнчә, җирле халык ул балыкларны бик ошата: кемдер аларны сыйпаган, кемдер ашаткан кыяфәт чыгарып фотога төшкән, – диде Наталья Чернова.

Инвалидлар өчен дә мәйданчык бар. Корылмалар арасында коляска белән хәрәкәтләнергә була. Балалар мәйданчыгы шулай ук балыклы стильдә. Әмма тауучыкның бер читендә ни сәбәпледер «Мурманск» дип язылган. Наталья ханым сөйләвенчә, мәйданчык Казаннан Мурманск шәһәренә җибәрелергә тиеш булган. Әмма район төзүчеләре, балыклы яр буе төзелүен белеп, корылманы шушында җибәрттергәннәр.

– Әлегә нишләргә икәнен белмибез, бәлки, Балык Бистәсе дип язарбыз, бәлки, шул килеш калдырырбыз, – дип елмайды районның «мәдәният министры».

«БИСТӘЛЕЛӘР КИЛГӘН, БАЛЫК ИСЕ ЧЫКТЫ»

Икенче бер почмакта тренажерлар урнашкан. Анда әбиләр бик рәхәтләнеп шөгыльләнә икән. Шул арада каршыбызга 70 яшьлек Зәйтүнә апа Сафина килеп чыкты. Ул һәркөн иртән ярты сәгать велосипедта йөри. Ни өчен иртәнме? Кеше күрмәсен өчен, ди. Зәйтүнә апа яшь чактан ук спортка гашыйк, йөгерү һәм чаңгы ярышларында бервакытта да беренчелекне бирмәгән. Аяк тренажерларының берсенә атланып, шөгыльләнә башлагач, без «Охо!» дип гаҗәпкә калдык.

– Адымнарым менә шундый зур! – диде ул.

– Гадәттә, ничә минут шөгыльләнәсез? – дим.

– Белмим. Санаганым юк. Туйганчы. Кайвакыт монда чират та була.

– Бүгенге сыман һәрвакыт итәк кигән килеш хәрәкәтләнәсезме? – дип сорадым.

– Гел итәктән. Мин «Өмет» ансамблендә җырлыйм. Екатеринбургка кадәр бардык, әмма бер тапкыр да чалбар кигәнем булмады, – диде ул.

Икенче бер тренажерда үз авырлыгыңны күтәрергә кирәк. Монысы Зәйтүнә апага бераз кыенгарак туры килде, үзе 78 килограмм авырлыкта булса да, барыбер максатына иреште.

Мария апа Елисеева да «Өмет» җырчысы, ансамбльгә тугыз ел йөри. Ул мондагы матурлыкка сокланып туя алмый.

– Бер сүз белән әйткәндә, могҗиза! Аеруча кичен. Кама өстеннән салынган күпердәге утлы баганалар шулкадәр матур җемелди. Элеккеге сыман пароходлар да йөрсә иде... Заманында Казанга отчет белән барсаң, «ә-ә, бистәлеләр килгән, балык исе чыкты», дип шаярталар иде. Яр буендагы матурлыкны саклап калырга кирәк. Җимерү җиңел ул, ә төзү гаять авыр.

ТЕЛӘЧЕ

ӘЧЕГӘН ЕЛГА

Теләче авылын, урталай бүлеп, Тюлячка елгасы агып үтә дә Мишәгә коя.

– Су буеның татарча атамасы бармы? – дип сорыйм район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Альфред Шәйдуллиннан.

– Теләче рус авылы буларак барлыкка килгән, шуңа да елга исеме русча атама белән тарихка кереп калган. Татарлар соңыннан гына күченеп килгән. Хәзер монда күбрәк татар халкы яши. Теләче үзенең базары белән данлыклы, заманында монда октябрь аенда Покрау ярминкәсе үткәрелгән, күрше-тирә районнардан килеп, бал, умарта, халык өчен ул заманда бөтен кирәк-яракны сатканнар. Яр буе паркындагы балалар мәйданчыгын да умартачылыкка бәйләп эшлädек, – диде әңгәмәдәшем.

Тюлячка соңгы елларда бик ташландык хәлдә булган, халык өйдә җыелган чүбен дә шунда ташлаган. Май заводы да «пычрак эшкә» үзеннән өлеш керткән: бөтен шакшы суын шунда агызган.

– Ул вакытта елга суы әчегән сөт рәвешендә аксыл төстә иде, дөресен әйткәндә, анда бака да юк, аяк киемен дә юарга чиркана идек. Моңа түзәр чама калмагач, заводны канализация ясатырга һәм чистарту җиһазлары урнаштырырга мәҗбүр иттек. Хәзер балык та, бака да бар, кошлар да сайрый башлады, – дип елмайды Альфред Шәйдуллин. – Тюлячканың тирә-ягын узган елда район бюджеты хисабына тәртипкә китерә башладык. Алты миллион сум тотылды. Предприятие-оешма эшчеләрен, мәктәп укучыларын, укытучыларны җәлеп итеп, дүрт-биш мәртәбә өмә үткәрдек, кычытканнарны йолкыдык. 200ләп талны кисәргә туры килде. Авыру, инде ава башлаганнары, че-



регәннәре дә шактый булды. Бу эш рөхсәт нигезендә башкарылды.

«КЕШЕ КЫЧЫТКАННЫ ДА КҮРЕРГӘ ТИЕШ»

Тюлячка паркының икенче өлешенә быел тотынганнар. Безнең күзебезгә балалар, спорт мәйданчыклары, эскәмияләр чалынды. Казанның 200 һәм 2000 сумлык кәгазь акчаларга эләгүен теләп, яр буенда флешмоб та үткәргәннәр. Кызганыч, җиңү бәхете Татарстанга тәтемәде.

– Эскәмияләр, утыргычлар табигый чималдан эшләнде, тимер әйберләре сирәк, күбесе затлы агачтан ясалган. Паркка керә торган капка мичкәне хәтерләтә, чөнки Теләче бондарьлар, ягъни кисмәк ясаучылар белән дан тоткан. Төзелә башлауга, халык, кызыксынып, читтән күзәтеп йөрде. Эшләр тәмамлангач, чит авыллардан да килеп паркка сокландылар. Әбиләр дә, кичке алтыда чыгып, таякка таянып, тирә-якны бер кат әйләнеп чыгалар. Халык чын күңелдән сөенде, төзүчеләр дә күңелләрен биреп эшләде. Кешенең культура дәрәҗәсен үстерү өчен бик кирәкле урын бу, – диде башкарма комитет җитәкчесе урынбасары.

Парк проекты әзер булгач, аны халыкка районның «Батыр» спорт комплексында тәкъдим иткәннәр. Теләчеләр үз тәкъдимнәрен дә җиткергән. Кайберләренә колак салганнар. Әйтик, халык гозере буенча Wi-Fi үткәргәннәр.

– Парк белән хозурланганда, яр буенда кукраеп утырган кычытканнарга игътибар иттек әле… – дим.

– Кычытканны чабып атуның бернәрсәсе дә юк. Әмма район хакимияте, Наталия Фишман (Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның ярдәмчесе. – Авт.) һәм экологлар тәкъдиме буенча, елганы табигый хәлдә калдырырга килеште. Табигать кочагына килгәч, кеше кычытканын да күрергә, суына да орынып карарга тиеш.

КОНДЫЗЛАРНЫ КҮРМӘДЕК

Тюлячканың бер урынында «Кондызлар плотинасы» дип язып, каршы як ярда бу җәнлеккә һәйкәл дә куйганнар. Гөлназ Антонова кызы Латыйфа белән Казаннан Теләчегә туганнарына кунакка килгән. Кондызларны да күрәселәре килә. Әмма җәнлекләр әлегә Казан кунакларының күзенә чалынмаган.

– Без монда беренче тапкыр, Казандагы бөтен яр буйларын йөреп чыктык инде. Табигать кочагына чыгарга балалар мәҗбүр итә. Бал кортлары төшерелгән мәйданчык кызык ясалган, кечкенә-кечкенә йортлары да бар. Элек монда бернәрсә дә юк, сасы ис чыгарып, пычрак елга агып ята иде. Шуңардан менә нинди матурлык ясап куйдылар. Кешеләрнең кәефе күтәрелә, өйдә утырганчы, шушында килүең яхшырак. Мондый матур урыннар күбрәк булсын иде, – диде Гөлназ ханым.

Альфред Шәйдуллин әйтүенчә, бу елгада гына түгел, район буенча да кондызлар күп. Алар Тюлячканың икенче ягында зур-зур плотиналар өеп куйганнар. Әмма берәүнең дә алардан килеп зарланганы булмаган.

Илдус Зарипов, Теләче районы башлыгы:

– Тюлячка буен чистартуга мин дә кушылдым, үзең катнашмасаң, кешене ияртеп булмый. Теләче халкы яшеллеккә күмелеп яшәсә дә, моңарчы районыбыз шушындый матур урыннарга бай түгел иде. Тюлячканың озынлыгы берничә километр, 800 метрын рәтләдек, тагын 1,5 километрын җиренә җиткерәсе калды. Анысына сукмаклар салып, гадирәк итеп эшләрбез.

Сабан туе уза торган мәйданда ябыла торган чаңгы базасы төзедек, анда кием алыштыру урыны да бар. Мин дә чаңгы шуарга яратам. Кичке сигездә эш беткәч, 10–15 километр йөреп алам. Былтыр анда кыш буе гаиләләре белән чаңгы шудылар.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАНДА СУЛЫКЛАРНЫ САКЛАУ ЗОНАЛАРЫНЫҢ КОРЫЛМАЛАР КАРТАСЫ


Мамадыштагы Ошма елгасы яр буе
35,2 млн сум
Красный Ключ бистәсендәге Кама елгасы яр буе
101,87 млн сум
Алабуга
Мамадыш
Яр Чаллы
Түбән Кама
Чаллыдагы Габдулла Тукай исемендәге яр буе
186,5 млн сум
Актаныш
Мөслимдәге Ык елгасы яр буе
30,37 млн сум
Актаныштагы Актаныш буасы яр буе
32,03 млн сум
Зәй
Мөслим
Сарман
Зәйдәге Фәрдиев исемендәге парк
48,42 млн сум
Сармандагы Татар Илеге елгасы яр буе
19,4 млн сум
Әлмәт
Азнакай
Азнакайдагы Кара елга яр буе һәм Җиңү паркы
20,37 млн сум
Әлмәттәге шәһәр пляжы
163,7 млн сум
Лениногорск
Урыссу
Бөгелмә
Лениногорскидагы Камышлы буалар каскадының яр буе
47,75 млн сум
Бөгелмәдәге Я.Гашек урамында урнашкан яр буе
63,65 млн сум



PRESSA.RU

СҮЗ КӨЧЕ

Бу мәктәптә укыту методикалары гадәти түгел. Хәер, укучылары да үзенчәлекле бит. Иң беренче дәрес үк тулысынча укуга чумудан башлана. Күп нәрсәне укучылар беренче тапкыр ишетә, ә параллель рәвештә, хәтер төпкелләреннән, инде күптән онытылган нәрсәләр баш калкыта...

Автор:
Катерина Котова

КАМИЛЛЕККӘ ЧИКЛӘР ЮК

Атаклы «Лобачевка» залында алкышлар яңгырый. КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбенә аны тәмамлаучыларның алкышлары бу.

– Йә, нәрсә? Башлыйбызмы? – дип сорый аудиториядән Югары мәктәп директоры Игорь Привалов.

Бүген биредә Татарстан дәүләт хезмәтенең иң яхшы өлеше – республикабызның яшь, перспективалы киләчәге җыелган. Квалификация күтәрү турында таныклыклар берьюлы өч аппарат – Президент Аппараты, Дәүләт Советы һәм ТР Министрлар Кабинеты хезмәткәрләренә тапшырыла.

– Үзегез өчен файдалы нәрсә ачтыгызмы? Дөресен әйтегез! Ниндидер аңлашылмый калган нәрсә бармы? – дип үзенең төп соравын бирә Игорь Привалов.

Шунысын да әйтергә кирәк: биредә дежур комплиментлар яки әдәп саклап дәшми калу хупланмый, кире элемтәне исә үз нәтиҗәлелекләрен күтәрүнең иң мөһим инструментына саныйлар. Камиллеккә чикләр юк. Әлеге мәктәп хезмәткәрләре өчен буш сүзләр генә түгел бу. Квалификация күтәрү буенча алар эшләгән барлык курслар буш урында пәйда булмаган – һәркайсының нигезендә дәүләт хезмәткәрләренең конкрет теләкләре ята. Ихтимал, һәр программаның уңышы менә шул даими, чын диалогта яшеренгәндер дә.

«ЧИНОВНИК» НИДӘН БАШЛАНА?

«Дәүләт гражданлык хезмәтендә эш хаты» курсы идеясен беренче булып ТР Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесе Александр Белов тәкъдим итә. Хәер, аның зарурлыгы инде күптән мәгълүм була.

– Мин район администрациясе башлыгы булып ун елга якын эшләдем, – дип сөйли Игорь Привалов. – Шунлыктан үз фикерләрен кәгазьдә төгәл аңлата алмау һәм документлар тутыра белмәүнең безнең дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең иң зур проблемаларыннан берсе булуын үз тәҗрибәмдә татып беләм. Ә хәзер мондый хаталы хатларның гади гражданнар кулына килеп эләгүен күз алдыгызга китерегез – алар бит имиджны боза һәм хакимият абруен төшерә! Менә шулардан «чиновник» сүзе башлана да инде – асылда, ул сүгенү сүзе кебек яңгырый, һәм мин моның белән катгый килешмим. Безнең «Эш хаты» программасы бу проблеманы хәл итәргә тиеш.

«УКУ – КҮҢЕЛЛЕ ШӨГЫЛЬ!»

Былтыр әлеге курсны республиканың 800 дәүләт һәм муниципаль хезмәткәре тәмамлаган. Югары мәктәптә, быел мондый ажиотаж булмас, дип уйлаганнар, тик ялгышканнар! Декабрь азагына кадәр биредә 900 тыңлаучыны кабул итәргә планлаштыралар. Урыннардагы җитәкчеләр, программаның нәтиҗәлелеген тоеп, үз хезмәткәрләрен укытуны дәвам итәргә тели. Хәер, соңгылары үзләре дә кабат «мәктәп» партасы артына утыру теләге белән яна.

– Ике көнлек курс искиткеч төпле итеп төзелгән – барлык

белем дә эштә кирәк булачак, – дип сөйли ТР Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе Искәндәр Хәйруллин. – Бу курстан соң киңәйтелгән программаны да үтәсем килә башлады. Рус теле бик бай бит – нюанслары күп, ә эш хаты белән без үз эшчәнлегебездә көн саен очрашабыз. Сүз уңаеннан, безгә мәктәптә методик кулланма да бирделәр әле. Бик шәп булышчы! Документны ничек итеп дөрес төзергә, проблеманы формалаштырырга, грамоталы текст язарга – хәзер һәр очракка кул астында «шпаргалка» бар.

– Укырга бер дә күңелсез түгел! – дип коллегасына кушыла ТР Президенты матбугат хезмәтенең баш киңәшчесе Мария Полякова. – Бу инде Татарстан дәүләт хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү программасы кысаларында мин катнашкан икенче семинар, һәм рәхәтләнеп яңа курслар һәм тренингларны көтәм. Бу өлкәдә даими эшләгән кешегә рус телен кабат өйрәнү кирәк тә түгел кебек. Миңа, ТР Президенты матбугат хезмәтендә эшләүче буларак, текстлар, басмалар, интервьюлар белән даими эшләргә туры килә... Әмма көндәлек практика камиллеккә чик булмавын дәлилли. Курслар синең белемнәреңне системалаштыра, эшкә яңа иҗади көч белән керешү мөмкинлеге бирә.

> **– Шәхсән мине биредә укытып кына калмадылар, бәлки гаҗәпләндерделәр дә, – ди Искәндәр Хәйруллин. – Беренче чиратта, үзләренең хәбәрдарлыклары һәм безнең эш спецификасын белүләре белән. Педагоглар безгә иң еш очрый торган конкрет проблемаларны яхшы белә.**

ГАҖӘПЛӘНДЕРДЕЛӘР!

– Шәхсән мине биредә укытып кына калмадылар, бәлки гаҗәпләндерделәр дә, – ди Искәндәр Хәйруллин. – Беренче чиратта, үзләренең хәбәрдарлыклары һәм безнең эш спецификасын белүләре белән. Педагоглар безгә иң еш очрый торган конкрет проблемаларны яхшы белә. Барысы да тулысынча исәпкә алынган, шунлыктан курс бик гамәли булып чыккан. Бу минем өчен көтелмәгән сөенеч булды.

Программаны Казанның танылган филологлары, КФУ укытучылары Алексей һәм Елена Бастриковлар төзегән. Алар үз эшен чын тикшеренүдән башлаган.

– Без аудиториянең шактый катлаулы буласын аңлый идек, аларны рус теле кагыйдәләре һәм нормалары белән генә шаккатырып булмаячагын да, – дип сөйли Алексей Васильевич. – Дәүләт хезмәткәрләре специфик документлар белән эшли, шунлыктан без ТР Президенты Аппараты һәм ТР Министрлар Кабинетына мөрәҗәгать итеп, алардан безгә реаль материалларны һәм хатларны күрсәтүләрен үтендек, аларда очраган хаталарны туплодык.

Бик күп мәгълүматка анализ ясап, Бастриковлар махсус укыту блогы эшләгән, анда дәүләт стандартының барлык таләпләрен, шулай ук министрлык һәм ведомстволарның эчке регламентларын исәпкә алган.

– Без укытуга тренинг элементларын керттек, – дип сөйли Алексей Бастриков. – Кейс-метод ярдәмендә билгеле бер эш хаты язуга конкрет ихтыяҗ тудырабыз. Һәм, төркемнең бер өлеше аны төзесә, икенчесе экспертка әйләнә. Бу аларга барысына бергә оптималь вариантка ирешергә мөмкинлек бирә.

Вазгыятькә тулысынча чуму беренче минутлардан ук башлана. Һәм менә инде тел – үзара хезмәттәшлек ысулы гына түгел, бәлки дөньяны тану, мәгълүматны саклау, һөнәри аралашу коралы да... Алда – рус һәм татар телләре (икенче дәүләт теле дә курс программасына аерым блок итеп кертелгән) дөньясына мавыктыргыч, көтелмәгән ачышларга бай ике көнлек сәяхәт. Әле моның белән генә дә бетми. Махсус алымнар ярдәмендә галимнәр тыңлаучыларда хатирәләр чылбырын уята: һәм менә, ниндидер акылга сыймаслык рәвештә, мәктәп һәм югары уку йорты программаларындагы инде әллә кайчан онытылгандыр кебек тоелган белемнәр хәтердә баш калкыта.

– Кайвакыт кеше үзе алдына җитәкче куйган бурычны ничек үтәргә белми аптырый, – дип аңлата Алексей Бастриков. – Безнең бурыч – профессиональ максатларга ирешүдә куәтле система буларак телдән файдалану механизмын эшләтеп җибәрү.

Сүз уңаеннан, «өч аппараттан» җыелган хәзерге төркем Бастриковларда аеруча кызыксыну уята.

– Без, педагог буларак, концептуаль белемгә ия, ә менә дәүләт хезмәткәрләре көндәлек эшләрендә очраша торган специфик белем һәм нечкәлекләргә тыңлаучыларыбызның үзләреннән өйрәндек, – дип сөйли Алексей Васильевич. – Дәресләрдә өйрәнү процессының үзара, ике яклы булуы исә бик шәп.

ХАТ ЭТАЛОНЫ

– Әйе, безнең эшебез күп очракта кәгазь белән бәйле, әмма мин һәрвакыт кабатлыйм – һәр кәгазь артында иң беренче чиратта кешене күрә белергә кирәк, – дип мөрәҗәгать итә КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбен тәмамлаучыларга ТР Дәүләт Советы секретаре Лилия Маврина. – Мондый эшнең җаваплылыгы зур. Хакимиятнең абруе, республика халкының аңа мөнәсәбәте шул эшкә бәйле. Алай гына да түгел, халыкның тормышы да аңа бәйле. Хатларны без күп язабыз. Һәм без моны үзебезне ишетсеннәр, проблема хәл ителсен өчен эшлибез. Нәтиҗә – яхшы хатның критерие нәкъ менә шул түгелмени?

Бу постулат хакимият органнары өчен генә түгел, бәлки башка дәүләт һәм коммерция структуралары өчен дә гамәлдә һәм актуаль. Югары мәктәпкә төрле оешмалардан мөрәҗәгать итәләр. Мәсәлән, сентябрьдә бу программа буенча «Татэнергосбыт» АҖ хезмәткәрләре төркеме укыган.

КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры урынбасары Наталья Аксенова әйтүенчә, алар ирешелгәннәргә канәгать булып туктарга җыенмый. 2017 елда камиллекләрен арттырырга теләгән һәркемне тагын да катлаулырак яңа эш хаты курсы көтә.

PRESSA.RU

«МАЙСКИЙ» ТЕПЛИЦАСЫ БИРГӘН ИММУНИТЕТ

Кешенең азык рационында антиоксидантларга бай яшелчәләр була икән, ул салкын тию (ОРВИ) яисә көзге кәеф төшү кебек сезонлы күңелсезлекләрне җиңел генә үткәреп җибәрә алачак. Бу турыда «Майский» теплица комбинатында да яхшы беләләр, һәм шуңа күрә зур кыйммәткә ия булган ликопин антиоксидантлы томатлар үстерүгә бик зур игътибар бирәләр.

ЯКТЫЛЫК ЯРАТУЧЫ КУЛЬТУРАНЫ – ХАЛЫККА

Яшелчәләрне зур масштабларда үстерү – үсемлекләрне утырту һәм уңышны җыеп алу гына түгел бит ул. Биредә һәр үсемлекне күзәтергә, аның физиологик торышын «укый» белергә, барлык ихтыяҗларын да үтәргә кирәк.

«Майский» теплицасының мәйданы – 42 га. Ел саен биредә 33 тоннадан артык яшелчә – кыяр, помидор, берничә сорт салат, укроп, петрушка, редис, борыч һәм баклажан үстерәләр. Һәм, әлбәттә, җиләк. Яктылык культурасы технологиясен кулланып, комбинат белгечләре помидорны – бер квадрат метрдан 86 кг, ә кыярны 167 кг күләмдә җыеп алалар, бу, мәсәлән, Голландиядәге күрсәткечтән күпкә югарырак.

«Майский» предприятиесе эшчәнлегенең 42 елы дәвамында бай тәҗрибә туплаган, ә ул куллана торган технологияләр даими камилләшеп тора. Шул исәптән, биек теплица конструкцияләре дә. Хәзер төзелә торган теплицалар элеккеләреннән күпкә аерылып тора. Бу үсемлекләрнең төрле фотосинтез активлыгына бәйле. Кыярлар өчен 5 метрлы терәкләре булган теплицалар кулай булса, помидорларның фотосинтетик активлыгын көчәйтү өчен биегрәк теплицалар кирәк. Нәкъ менә помидорлар үстерү өчен хәзер терәкләренең биеклеге 6 метрга җитә торган теплицалар төзелә дә инде. 5,5 га мәйданда төзелеп бетеп килә торган теплицалардан помидорларның беренче уңышын быел октябрьдә җыеп алырга мөмкин булачак инде. Алдагы елда исә тагын 5,1 га лы иске теплицаларны үзгәртеп кору планлаштырыла.

Ләкин, нинди генә алдынгы инфраструктура булмасын, бары тик аның белән генә яшелчә үстерүне берничә тапкыр арттыру мөмкин түгел. Аны өстәмә тукландыру һәм яктылыкны баланслау, микроклиматны саклау, авыру һәм корткычлардан саклауны тәэмин итеп кенә арттырырга мөмкин. Ә бу беренче карашка бик гади генә булып күренгән гамәлләр комбинат белгечләренең нәтиҗәләрне даими һәм төгәл исәпләү һәм тикшереп торуларын таләп итә. Димәк, теплица гына түгел бу, ә чын лаборатория.

Мисал өчен яктылыкны гына алыйк. «Майский»да яшелчәләрнең күп өлеше көз, кыш һәм яз көне үстерелә – бу вакытта яктылык идеаль була алмый, ә кайчагында бөтенләй дә булмый.

«Майский»да яктылык культурасы дип атала торган технология кулланалар, ягъни яшелчәләрне ясалма яктылыкта үстерәләр. Моның өчен теплицаларда көйли торган электрон аппаратлы яктырткычлар һәм үзебезнең илдә җитештерелә торган көмеш йөгертелгән махсус лампалар куела.

КОРТКЫЧЛАРГА КАРШЫ ЕРТКЫЧЛАР

Сүз уңаеннан, «Майский» яшелчә үстерү ноу-хауларын куллану буенча гына түгел, ә үзе үзен энергия һәм җылылык белән тәэмин итә торган тулы бер комплекс төзү буенча да Татарстанда пионер була. Иң элек комбинат территориясендә өч җылылык үзәге, аннары – үзләренең энергия үзәген һәм Мәскәү инвесторлары белән хезмәттәшлектә 71 МВт лы егәрлекле тагын бер үзәкне төзиләр. Хәзер биредә 22 гектар мәйданны – газ халәтендәге һәм 42 гектарга якын җирне сыек углекислый газ белән тәэмин итү өчен төтен газларын чистарту һәм углекислый газны сыегайту станциясе төзиләр. Станция төзелеше 2017 елда тәмамланачак.

Су сибү, CO_2 бирү, микроклимат автомат рәвештә гамәлгә куела, ә үсемлекләрне карау һәм уңышны җыю кул белән башкарыла.

Реклама

Үсемлекләрне тамчылап су сибү юлы белән өстәмә тукландыралар. Балансланган эремә төгәл бер вакытта һәм кирәкле микъдарда бирелә. Ә төзелә торган углекислый газны чистарту станциясе аны барлык станцияләргә дә тигез күләмдә җибәрергә мөмкинлек бирәчәк.

Өстәмә тукландыру микъдары һәм составы бик җентекләп тикшереп торыла. Яшелчәләрнең һәр партиясе нитратның күпме булуына тикшерелә. Үзләренең агрохимия лабораториясеннән тыш сыйфатны читтәге оешмалар да – Роспотребнадзор, ТР буенча Россия авыл хуҗалыгы үзәге, "Тест-Татарстан" Республика сертификацияләү методик үзәге һ.б. тикшереп торалар. Барлык продукциянең дә Экологик яктан туры килү сертификаты бар. Азык продукциясенең куркынычсызлык менеджменты ISO системасына нигезләнгән.

«Майский» яшелчәләренең экологик куркынычсызлыгына тагын үсемлек корткычларына каршы агулы химикатлар белән түгел, ә энтомофаглар – бөҗәкләр дөньясындагы ерткычлар хисабына да ирешелә. Аларны комбинатның уникаль биолабораториясендә үрчетәләр. Бөҗәкләрнең 11 файдалы төренең 800 млн нан артык вәкиле теплицаларга профилактика һәм үсемлекләрне саклау өчен чыгарыла.

Шунысы игътибарга лаек: үсемлекләрне серкәләндерү өчен бал кортлары һәм шөпшәләр кулланыла.

«МАЙСКИЙ» КАДРЛАРЫ

«Майский» продукциясе бренды Татарстан һәм Казан сатып алучылары арасында зур популярлык яулап кына калмыйча, Россиянең эре шәһәрләре булган Чиләбе, Киров, Ижевск, Екатеринбург, Мәскәү, Санкт-Петербургта да яхшы сатыла. Бездә үстерелгән яшелчәләр Германия, Франция, Голландия, Италиядәге халыкара күргәзмәләрдә катнашты, һәм анда аларга лаеклы бәя бирелде.

Сүз уңаеннан, барлык төрләр дә балалар туклануы продуктлары буларак тәкъдим ителә. Әмма сыйфат турында кайгырту белән генә «Майский»ның социаль миссиясе төгәлләнми әле. Хәйриячелек ярдәме буларак, комбинат һәр атна саен Осиново, Васильево, Түбән Карамалы бистәләренең 5 мең мәктәп укучысы һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалары өчен кыяр, помидор, салат җибәрә. Ә үсеп килүче буынга авыл хуҗалыгы фәннәренә мәхәббәт тәрбияләү максатыннан «Майский»да укучылар һәм студентлар өчен даими рәвештә экскурсияләр үткәрелә. Алар һәрвакыт күңелле һәм нәтиҗәле уза. Һәм балалар бередән киләчәктә югары класслы хезмәткәрләр булып бирегә әйләнеп кайту теләге белән китәләр.

Комбинат җитәкчелеге эш белән кызыксыну һәм аны сыйфатлы итеп башкару теләге беркайчан да сүнмәсен дигән максат белән үз хезмәткәрләре өчен барлык шартларны да булдырырга омтыла. Предприятие үзенең тулай торагын төзеде, аның беренче катында 40 урынга балалар бакчасы ачылды.

Быел көз көне 40 фатирлы йортка яшәүчеләр күчте. Спорт мәйданчыгы, шугалак һәм ябык спорт комплексы төзелде. Бистәнең үзендә комбинат акчасына биш өйне ремонтларга, Осиново урта мәктәбенә янкорма төзергә планлаштырыла. Бу мәктәптә «Майский»ны «космик» дәрәҗәгә күтәрәчәк булачак белгечләр укып чыгар, мөгаен.

PRESSA.RU

БАКЧАБЫЗДАГЫ ҮЛЕМСЕЗ ТӘЛГӘШЛӘР

Автор:
Олеся Бондаревская

Сентябрьдә республикабызның Авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты (ФТИ) сайтында виноградның берничә сортын сынап карауга керешүләре турында хәбәр бастырылган иде. Әлеге экзотик культураның Татарстан аграрийларында җитди кызыксыну уята алуына хәйран калып, без бу яңалыкның тәлгәшләре кайдан үсүен ачыкларга булдык.

Катя Ихтова, Татарстан Авыл хуҗалыгы ФТИның кече гыйльми хезмәткәре, виноградның Смоленск сортларын сынау буенча институт башкарган эш җимешләрен күрсәтә.

Татарстан Авыл хуҗалыгы ФТИның сынау кишәрлеге оҗмах бакчаларын хәтерләтә: төрледән-төрле ямь-яшел үсемлекләр, салкынча җилдә хуш исләрен аңкытып, диңгез дулкыннарыдай тирбәлә.

Институтның кече гыйльми хезмәткәре Катя Ихтонова миңа кап-кара виноград тәлгәше суза. Җиләкләр боздай салкын булгангамы, тагын да баллырак тоела.

– Бу – Смоленскиның «Северный сладкий» сорты. Август-сентябрьдә җимеш бирә, әмма безнең климатта өлгерү вакыты соңгарак кала – октябрьгә кадәр сузылырга мөмкин, – дип сөйли Катя.

«ТИМУР» ХАТАЛАРНЫ КИЧЕРМИ

Фәнни-тикшеренү институтында виноградны өйрәнү белән инде өченче ел шөгыльләнәләр. Бакчачылар һәм фермерларның әлеге культура белән кызыксынуы гаять зур булганга, тотынырга уйлаганнар бу эшкә. ФТИ белгечләре үсентеләрне Татарстандагы виноград үстерү корифейлары – «Казанская лоза» йөзем игүчеләр клубы рәисе Леонтий Кирягиннан һәм Вера Монахова клубыннан сатып алганнар. Институт «полигонында» хәзер берничә ашый торган («Супер

Фото: Александр Эшкинин

Вера Монахова һәм аның тормыш иптәше үзләре үстергән виноградны күрсәтәләр.

Экстра», «Роза не святая», «Звезда Бояринова», «Аркадия», «Находка», «Краса Севера») һәм техник («Смоленский прорыв», «Вымпел», «Северный сладкий», «Офас», «Тимур», «Память Потапенко», «Саперави Смоленский») сорт бар. Нәтиҗә билгеле булганнан соң, институт үсентеләрне халыкка сата башлаячак.

– Смоленск сортлары – безнең климат шартларына иң яраклаштырылганнары. Алар 40 градуска кадәр салкынга чыдам, – дип сөйли ФТИның гыйльми хезмәткәре Мәрьям Чинаева. – Хәтта безнең шартларда да яхшы, татлы, соң өлгерә торган уңыш бирәләр. Моннан тыш, бу сортлар коньяк сортлар кебек җентекләп тәрбияләүне дә таләп итми.

Виноград үсентесен утырту һәм карау нечкәлекләре турында Мәрьям Салиховна сөйләгәннәрдән шул аңлашыла: Татарстанда виноград үстерү белән шөгыльләнеп була һәм шөгыльләнергә кирәк тә. Әмма эшкә яңа керешүчеләргә баштарак кыен булачак.

– Ышык урында үсә торган сортлар кышны шактый җиңел кичерә ала. Әмма бу кирәкле үләмдә чокыр казып, үсентене утыртасың да, җимеш бирә башлаганчы, ике-өч елга, аны онытасың, дигән сүз түгел, – дип сөйли белгеч. – Виноград ялгышларны кичерми. Баштарак, үз гамәлләрегезне автомат рәвешенә җиткергәнче, тырышырга туры киләчәк. Артык ян сабакларны вакытында кисеп алу, ашламаларны чама белән генә кертү, су сибү, туендыру, ботакларны кисеп сирәкләү зарур. Әмма нәтиҗәсе дә сөендерерлек булачак.

Соравы булганнарга җавап эзләү, тәҗрибә уртаклашу өчен Мәрьям Салиховна инде берничә дистә ел буе уңышлы эшләп килгән «Казанская лоза» клубына мөрәҗәгать итәргә киңәш бирә.

КИЧЕР, «ИЗАБЕЛЛА»!

– Мин виноград турында күбрәк белгән саен, бу уникаль культурага күбрәк гашыйк була барам. Һәм аны күбрәк аңлыйм да: 12 ел эшләү дәверемдә Россия һәм чит ил ампелографлары туплаган мәгълүматның әле бик аз өлешен генә өйрәндем, – дип сөйли «Казанская лоза» клубы әгъзасы, күпьеллык стажы булган бакчачы, республикада гына түгел, бөтен илдә танылган виноград үстерү белгече Вера Монахова.

Аның Казан бистәләренең берсендәге 12 сутыйлы бакча кишәрлегендә урнашкан виноград плантациясендә 150 төп йөзем һәм шулкадәр үк диярлек ашый торган һәм техник сорт исәпләнә.

– Виноградның төп кыйммәте – аның дәвалау үзлекләрендә. Карасу төстәге техник, ягъни шәраб ясый торган сортларның җиләкләрендә һәм алардан ясалган шәрабта ресвератрол бар. Бу феноллы кушылма шешкә, ялкынсынуга каршы тору үзлегенә ия, йөрәк эшчәнлеген яхшырта һәм хәтта гомерне озайта, – дип сөйли Вера Андреевна. – Галим һәм селекционер Александр Потпенко: «Борынгы кешеләрнең даими ризыгы булган виноград безнең каныбызга сеңгән, ихтыяҗыбызга әйләнгән. Димәк, әлеге ихтыяҗны канәгатьләндермәү – организмны аның өчен кирәкле булган нәрсәләрдән мәхрүм итү», – дип саный.

Вера Монахова әйтүенчә, виноград үстерүнең төрле ысулларын үзләштерү омтылышы Татарстанда 1950нче елларда, «2–3 ел эчендә халыкка азык-төлек муллыгы тудырырга тиешле» аграр реформа вакытында ук булган. Яшел Үзәндәге яшь натуралистлар мәктәбе базасында виноградның төрле сортлары сәнәгать масштабларында үстерелгән, шул исәптән Мичурин сортлары да. Селекция уңышлы нәтиҗәләр күрсәткән, биредәге үсентеләр зур йөзем бакчаларына утыртылган.

Соңрак бу хәрәкәт тынган, һәм республика базарларында озак вакытлар буе «Изабелла»дан тыш (тәҗрибәле йөзем үстерүчеләр исә аны чүпкә саный) башка сорт үсентеләрен табу мөмкин булмаган. Вакытлар үткәч, һәвәскәр бакчачылар виноград үстерүне үзләштерә башлаган. «Казанская лоза» клубы оешкан.

МАРИНАДЛАНГАН ВИНОГРАД

Шуңа да карамастан, виноград Татарстан өчен яңа культура булып калуын дәвам итә. Аны үстерү башка җиләк-җимеш культураларыннан тамырдан аерыла торган физиологик һәм агротехник тәҗрибә, шулай ук озак вакытлар буе практик күзәтүне таләп итә. Әгәр кеше плантация утыртырга яки тулы бер фермер хуҗалыгында виноград үстерергә җыена икән, аның мондый күнекмәләре булу

Вера Монахова плантациясендә үсә торган виноградлар.

«Мускат Новошахтинский» сорты.

«Сенсация» сорты.

«Самородок» сорты.

PRESSA.RU

Киләсе елга Айрат Ялалетдинов үз плантациясен киңәйтергә уйлый. Әлегә виноградтан тыш, җиләк үстерү белән дә шөгыльләнә.

зарур, югыйсә акчасын бушка туздыру куркынычы бар.

–Мин коллекцион виноград бакчасы үстерәм, ашый торган яңа сортларны, гибрид сортларны, аларны безнең төбәктә үстерү мөмкинлекләрен сыныйм. Бу – «Байконур», «Эталон», «Анюта», «Кишмиш Юпитер», «Кишмиш Велес», «Заря Несветая», «Мускат Новошахтинский», «Гурман ранний», «Академик», «Гарольд» һ.б. сортлар. Болгария, Япония, Америка селекциясе сортлары бар. Алар барысы да үзенә бертөрле, аларны төрлечә тәрбияләү таләп ителә. Минем яраткан сортларым – «Краса севера», «Тимур», «Ладанный-2», «Блестящий» һәм «Самородок». Виноград үстерә башлаучыларга төрле вакытта өлгерә торган 4-5 төп виноград утыртырга кирәк – бик иртә, иртә, уртача иртә өлгерә торганнарны. Утыртканнан соң, дөрес караган очракта, дүртенче елда һәр куактан унар килограмм уңыш алып булачак, – дип аңлата Вера Андреевна.

Уңышны нишләтергә соң, дигән сорауны биргәч, ул үзенең берничә дистә кайнатма һәм хәтта тозлы ризык рецептын бүлеп сөйли. Соңгы фирма ризыгы – маринадланган виноград. Тагын берсе – томат белән бергә тозланган виноград.

Аның сөйләвенчә, техник сортлардан ясалган шәраб (закон аны шәхси куллану өчен җитештерергә рөхсәт итә) искиткеч яхшы килеп чыга. Әмма шәраб йөземе үстерү – аерым тема.

Мин Вера Андреевнага Кама Тамагындагы фермер турында сөйлим – ул быел җәй берничә йөз төп виноград куагы утырткан.

–Ә ул коньяк тау итәгенә утырткан мы? Сортлары нинди? Тәҗрибәсе бармы соң аның? – дип сораулар белән күмә ул мине. Һәм без җавап эзләп Кама Тамагына юл тотабыз.

Өйдә әзерләнгән тәм-томнар: томат белән бергә тозланган виноград.

КАМА ТАМАГЫНДАГЫ ВИНОГРАД БАКЧАСЫ

Яшь фермер Айрат Ялалетдиновның виноград бакчасы Уразлы авылына илтүче юлдан күренеп тора. Берничә рәт нәфис үсенте читән койма белән әйләндереп алынган.

–Койма буйлап «Изабелла» утыртырга җыенам, тик үссен шунда, бер үк вакытта, ышыклап, җилдән дә саклаячак, – ди Айрат. Чакырылмаган кунаклардан исә плантацияне Панда кушаматлы эт саклый.

Мин Айраттан бу бизнесны башлавының күпмегә төшүен сораштырам.

– Сәламәтлегем, акчам, вакытым һәм ирегем китте моңа, – дип шаярта Айрат. Июньдә ул бертуганы һәм әти-әнисе, шулай ук берничә ялланган эшче белән бергә 78 сутый җирдә 600 төп ашый торган һәм техник виноград куагы утырткан. Үсентеләрне даими карап торырга кирәк.

– Мин үз бизнесымны җирдә ачарга булдым. Ульяновскида виноград

үстерү белән профессиональ шөгыльләнүче танышларыбыз бар. Баштарак мин моны җитди нәрсәгә санамаган идем. Аннары уйлап карадым да, моның бик табышлы эш икәне ачыкланды. Республикада йөзем үстерә торган ферма да юк икән әле. Җир эзли башладым. Нәкъ менә бу районнан аласым килде – ул чагыштырмача коньяктарак та, шәһәрдән дә ерак түгел.

Айрат 10 метрга сузылган һәм коньякка караган тау бите эзләгән. Кама Тамагында шундый 20 метрлы кишәрлек тапкан.

– Без әле мин сатып алган (биредә арендага алуның мәгънәсе юк) җирнең бик аз өлешен генә эшкәрттек. Калган җирне – тагын 1,5 гектарны – сөрәбез. Астарак, виноградтан соң, камылын органик ашлама сыйфатында калдыру өчен, горчица чәчтем. Әгәр бу үсентеләр яхшы гына үсеп китсә, киләсе җәйгә тагын шулкадәр утыртачакбыз, – дип сөйли Айрат, безне киң яфраклы яшел виноград үрентеләре башын сузган сай гына траншеялар арасыннан алып барган арада.

– Туфракны тикшерттем, ул виноград үстерергә яраклы. Кыраулардан саклар өчен, чокырларны тирәнрәк казыдык, аларны җир һәм органик ашлама белән тутырдык. Чокырларны ай буе казыдык, – дип искә ала Айрат. – Биредә эшнең беткәне юк. Бигрәк тә мин берүзем булсам – артык ян сабакларны кисә башласаң, бөтен кырны үтәсең, аннары тагын башларга кирәк. Ләкин миңа кызык, әлегә үкенгәнем юк.

Плантациядәге виноградның барлык сортлары да – ышык урында үсә торганнар һәм иртә өлгерүчеләр, беренче уңыш 2018 елның август-сентябрендә көтелә. Биредә ашый торган сортлар да – «Рада», «Орион», «Преображение», «Забава», «Королева Парижа», «Лора», «Виктор», техник сортлар да – «Спартанец Магарача», «Юкка», «Аметистовый» һ.б. үсәчәк. Ульяновск виноград үстерүчеләре тәҗрибәсенә таянып, соңыннан уңышны урнаштыруда да проблемалар килеп чыгарга тиеш түгел, дип саный Айрат.

– Ә үзегез шәраб ясарга планлаштырмыйсызмы?

– Бу турыда сөйләргә иртәрәк әле. Бер тапкыр булса да уңышны җыеп карарга кирәк. Әлбәттә инде, бу эшне тагын да үстерәсе килә. Керемнең тотылган чыгымнарны каплавына ирешәсе иде. Күргәнегезчә, беренче өч ел – проектларга инвестицияләр кертү генә, мин кредитлар алмадым, әлегә барысын да үз акчама эшләтәм. Хәзер менә электр сузарга һәм биредә бүлгеч ясарга кирәк, гәрчә җир алганда миңа кабель сузу да җитә, дигәннәр иде. Шулай булса да, әлегә планлаштырган чыгымнар бизнес-пландагыдан артмый. Киләсе елга ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына эш башлаучы фермерларга ярдәм программасы буенча грантка гариза бирергә телим, – ди Айрат. – Быел шартларын өйрәндем, программада «виноград игү» пункты булмауга гаҗәпләндем. Югыйсә Татарстанда виноград үстерү белән бик тәҗрибәле кешеләр шөгыльләнгән хуҗалыклар бар бит. Димәк, мин беренче булачакмын. Яңа эшкә керешүчеләргә уңыш юлдаш була, диләр бит!

Леонтий Кирягин, «Казанская лоза» клубы рәисе:

– Татарстанда виноград үстерү белән күптән шөгыльләнәләр. Йорт яны кишәрлекләре хуҗалары һәм бакчачылар – активрак, фермерлар – сүлпәнрәк. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы ярдәмендә һәм Казан дәүләт аграр университеты катнашында сентябрьдә без фәнни-гамәли конференция һәм төньяк винограды төбәкара күргәзмәсен үткәрдек. Төп максат – Идел буеның төньяк районнарында яшәүче халыклар арасында виноград үстерүне популярлаштыру. Бездә бөртекләләр игүгә, ит һәм сөт җитештерүгә күнеккәннәр. Ә зур мәйданнарда виноград үстерү зур белем сорый. Безнең клубта консультатив ярдәм күрсәтергә сәләтле тәҗрибәле йөзем үстерүчеләр бар, әмма республика масштаблары турында сөйләгәндә, мондый кешеләр җитешми. Шунлыктан без яңа кешеләрне җәлеп итәргә тырышабыз, селекция эше белән шөгыльләнәбез, төрле сортларны сыныйбыз. Инде хәзер үк нәкъ менә Татарстанда ышыкта үстерү өчен ашый торган виноградның 100 сортын тәкъдим итә алабыз. Әгәр сәнәгать масштаблары турында сөйләсәк, алар өчен виноградның томаламыйча үстерелә торган сортлары да ярый, әмма хәтта бездә дә аларны үстерү тәҗрибәсе юк. Инвесторлар катнашуы Татарстанда виноград үстерүгә яхшы импульс бирә алыр иде.

Дмитрий Гусев, «Лоза» КФХ, Волгоград шәһәре:

– Мин виноград үстерү белән инде 25 ел шөгыльләнәм. Күп сортлар белән эшләдем, төрле техникаларны үзләштердем. РФ Салым кодексына күптән түгел кертелгән төзәтмәләр буенча, КФХ шәраб ясау, аны саклау һәм сатуга махсус лицензия алачак, шунлыктан шәраб кайнату белән рәсми рәвештә шөгыльләнү – планда. Тулаем алганда, бу – кызыклы бизнес, тик күп хезмәт, көч таләп итә. Аның белән шөгыльләнү өчен, гаять зур тәҗрибә дә кирәк. Мәсәлән, хәтта биредә, шәраб ясау өчен чагыштырмача уңай шартлар булган Волгоград өлкәсендә дә, йөземнең кайбер сортлары фенол өлгерешенә җитә алмый, ә мондый өлгереш сыйфатлы кызыл коры шәраб ясау өчен мөһим шарт булып тора. Шактый четерекле проблемаларның берсе генә әле бу. Әмма даими практика булганда һәм эш белән янып йөргәндә, хәл итеп булмаслык бер генә проблема да юк.

Петр Данилюк, «Виноград» ШЯХ, Ульяновск шәһәре:

– Минем виноград үстерү стажым – 13 елдан артык. Хәзер плантациямдә 2,5 мең төп куак бар, коллекцион виноградның 300 сорты исәпләнә. Киләсе елга тагын ике мең төп куак утыртырга планлаштырабыз. Нәтиҗәдә «күпләп җитештерү» өчен ашый торган кызыл, яшел һәм кара виноградның берәр сортын һәм иң яхшы сыйфатлы шулкадәр үк техник сортны сайлап аласым килә. Перспективада – үз техник виноград эшкәртү линиясен алу. Хәзер без питомнигыбызны теркәү процессында. Минемчә, соңгы елларда виноград үстерүгә кызыксыну шактый артты. Шулай булса да, базар әле тулысынча тутырылмаган, виноградны сатып алырга теләүчеләр бик күп.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАН НЕФТЬ ХИМИЯСЕ ӨЧЕН ЯҢА ЭНЕРГИЯ

Татарстанның Тукай районында ачылган «Бигеш» подстанциясе республика нефть химиясе тармагының төп предприятиеләрен энергия белән ышанычлы рәвештә тәэмин итәчәк.

Татарстанның 2030 елга кадәрге үсеше стратегиясе Кама инновацияле территориаль-җитештерү кластерын якындагы 10 елда республика икътисады үсешенең төп ноктасы итеп билгели. Аның драйверлары – Түбән Кама районы территориясендә урнашкан нефть химиясе сәнәгате предприятиеләре. Үз чиратында аларның нәтиҗәле эшләвенең төп факторы – сыйфатлы, өзеклекләрсез һәм куркынычсыз энергия белән тәэмин ителеш. Бу яктан караганда, 2016 елның 1 сентябрендә ачылыш тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашкан яңа 220 кВ лы «Бигеш» подстанциясенең әһәмиятен бәяләп бетерү мөмкин түгелдер.

ТОК: ДАИМИ ҺӘМ ЫШАНЫЧЛЫ

Тукай районы (Иштирәк авыл җирлеге) территориясендә яңа 220 кВ лы подстанция төзү проекты Татарстан Президенты күрсәтмәсе буенча эшләнгән иде. Объектны салуның максаты – Түбән Кама энергорайонында динамик үсештәге нефть химиясе производстволары һәм заводлары комплексын электр энергиясе белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын арттыру. Генераль подрядчы сыйфатында «КЭР-Холдинг» ИК эшләде. Яңа буын энергетикларына хат салынган истәлек капсуласы белән бергә объектның беренче нигез ташын салу тантанасы 2014 елның көзендә булды. Төзелешкә старт 2015 елның март башында бирелде. Объект республика өчен рекордлы срокларда өлгертелде.

– Бу – Татарстан икътисады өчен зур вакыйга, – дип билгеләп үтте подстанцияне ачу тантанасында Рөстәм Миңнеханов. – Әлеге проектны гамәлгә ашыру турында карар кабул ителгәннән соң, заманча подстанция иң кыска срокларда сафка бастырылды – Россия җиһазлары базасында үзебезнең төзүчеләр тарафыннан. Бу безнең сыйфатлы объектлар төзелешен башкарып чыга алуыбыз турында сөйли.

«Бигеш» подстанциясе Түбән Кама сәнәгать кластерын энергия ресурслары белән тәэмин итүче система барлыкка китерә торган объектларның өченчесе.

– Татарстан Президенты күрсәтмәсен үтәү йөзеннән, 2015 елда без уникаль «Щёлоков 500» подстанциясен төзеп бетереп, кулланышка тапшырдык. Ул Түбән Каманы да, «Алабуга» МИЗны да 1 категория ышанычлылыклы электр энергиясе белән тәэмин итә. Әлеге подстанция шулай ук «Бигеш» подстанциясен Түбән Кама ГЭС белән бәйләү мөмкинлеген дә тудырды, – дип сөйләде ачылыш тантанасында «Челтәр компаниясе» ААҖ генераль директоры **Илшат Фәрдиев.** – Шулай итеп, без үзебезнең кулланучыларны куәте 300 МВт лы махсус төркемдәге 1 категория ышанычлылыклы электр энергиясенең өченче өстәмә чыганагы белән тәэмин итүгә ирештек. Әлеге проектларны тормышка ашыру Татарстанның якындагы 20 елга барлык кирәкле энергия куәтләре белән тәэмин ителгәнлеген аңлата, хәтта Түбән Кама узелы буенча электр энергиясен куллану якындагы өч ел эчендә 200 МВт булыр дип исәпләгәндә дә. Электр көчәнешенең сикерүе нәтиҗәсендә технологик процессларга тукталу куркынычы янавы аркасында сизелерлек финанс авырлыклары кичергән нефть химиясе предприятиеләрендә сыйфатлы электр энергиясенә кытлык әлеге объектны төзүгә этәрде.

– «Бигеш» подстанциясе Түбән Кама ҖЭҮ белән бәйләнмәгән, димәк, аның белән килеп чыккан авырлыклар подстанциягә кагылмаячак. Икенче яктан караганда, хәзер нефть химиясе предприятиеләрендә резервны кушу буенча тиз арада эшләп китә торган автоматлар (АВР) куелган, алар теләсә нинди кыска ялганыш барлыкка килгәндә һәм көчәнеш кимегәндә предприятиене шунда ук резервтагы электр туклану чыганагына тоташтыралар. Шулай итеп, без уртак көч белән республика нефть химиясе комплексы предприятиеләрен техноген куркынычларны җиңәрлек сыйфатлы электр энергиясе белән тәэмин итүгә ирештек, – диде «Челтәр компаниясе» ААҖ техник директоры **Рашат Галимҗанов.**

ГЕНЕРАЦИЯЛӘР ӨЧЕН ПЛАЦДАРМ

Бүген подстанция эксплуатациягә тапшырылды. «Түбән Кама Нефтехим»да аңарга тоташу эшләре бара. ВЛ 220 кВ лы «Щёлоков – Бигеш», ВЛ 220 кВ лы «Бигеш – ТАНЕКО» һәм ВЛ 220 кВ лы «Бигеш – Түбән Кама» яңа югары вольтлы электр тапшыру линияләрен төзү нәтиҗәсендә «ТАНЭКО» ААҖ, «ТАИФ-НК» ААҖ предприятиеләре кебек сәнәгать гигантларын һәм башкаларны ышанычлы электр энергиясе белән тәэмин итү бурычы хәл ителде.

– Әлеге подстанциянең ачылышы – Түбән Кама сәнәгать узелын барлыкка китерүнең, анда сәнәгатьне үстерү өчен сыйфатлы шартлар тудыруның төп этапларының берсе. Биредә электр энергиясе белән тәэмин итүне бер генә мизгелгә дә туктатырга ярамаган шактый күп куркыныч җитештерүләр урнашкан. «Бигеш» әлеге мәсьәләне тулысынча хәл итә, – дип шәрехләде әлеге вакыйганы «ТАИФ» ААҖ генераль директорының энергетика һәм мәгълүмати технологияләр буенча урынбасары **Руслан Гыйззәтуллин.** – Хәзер Түбән Кама сәнәгать узелында урнашкан теләсә кайсы предприятие 1 категория ышанычлылыклы электр энергиясе ала алачак, бу фактта теләсә кайсы катлаулылыктагы һәм теләсә кайсы күләмдәге теләсә кайсы җитештерүне үстерүгә юлның ачыклыгын аңлата. Хәзерге вакытта әлеге подстанциягә «ТАИФ – НК» ААҖнең төзелеп килүче һәм быел куллануга тапшырылырга тиешле авыр калдыкларны эшкәртү блогы комплексын һәм «Түбән Кама Нефтехим»ның яңа этилен комплексын кушу эшләре алып барыла.

Болар барысы да – инвесторлар өчен Түбән Кама кластерының энергетика инфраструктурасы гарантиясенең һәм куәтенең ачык мисаллары.

– «Бигеш» подстанциясе энергия белән тәэмин итү сыйфатын гына түгел, район үсеше перспективасын да тәэмин итә. Ул предприятиеләргә үз генерацияләрен булдырырга («ТАНЕКО»дагы шикелле) һәм челтәргә үз электр энергиясен тапшырырга мөмкинлек тудыра. Бу – Татарстан энергетикасында революцион технологик адым, – дип саный «Бердәм энергетика системасының Системалы операторы» АҖ филиалы Татарстан Төбәк диспетчер идарәсе директорының беренче урынбасары – баш диспетчеры **Валерий Кандалинцев.** – Алга таба планлаштырылган адым – «Щёлоков» подстанциясеннән Казан районына кадәр 220 кВ лы линия төзү. Бу кушылу аның бөтен ихтыяҗларын каплаячак һәм энергетик ышанычлылыкны һәм Түбән Кама һәм Казан районнарының инвестицион җәлеп итүчәнлеген (бу да шактый мөһим!) тәэмин итү буенча Татарстан Хөкүмәтенең гаять зур планының чираттагы этабы булачак.

ПЕРСПЕКТИВА ӨЧЕН ТӘҖРИБӘ

Подстанция ачылышында чыгыш ясаган барлык спикерлар проектның болай уңышлы һәм тиз арада гамәлгә ашырылуы процесста катнашучыларның барысының да, аерым алганда, генераль подрядчының һәм субподряд оешмаларының, һәм шулай ук Түбән Кама энергорайонында төзелүче объектлар дирекциясенең тигәл, профессиональ югарылыкта эшләве нәтиҗәсендә мөмкин булуын билгеләп үттеләр.

– Әлеге подстанцияне төзүгә керешкәндә безнең активта 35 эре объект санала иде. Тупланган тәҗрибәбезне кулланып, без эш графигын вакытыбыз запаска калырлык итеп планлаштырдык. Нәтиҗәдә без графикны үтәп кенә калмадык, объектны вакытыннан алдарак та тапшыра алдык, – дип сөйләде «КЭР-Холдинг» ИК» ҖЧҖнең проект җитәкчесе **Яким Шахбазов.** – Без төзелеш мәйданында барлык субподрядчыларның бер үк вакытта эшләве мөмкинлеген күз уңында тоттык – көн саен биредә 180–200 кеше эшләде. Әлеге стратегик объектны без бары тик 13 ай эчендә сафка бастырдык – бу срокларга сыешачагыбызга нигез ташы салу этабында хәтта федераль сәнәгать министрлыгы вәкилләре дә ышанмаган иде. Шунысы куанычлы: бер генә субподрядчы да безне уңайсыз хәлгә калдырмады. Шуның нәтиҗәсендә «Бигеш» подстанциясе ачылышы кебек тантаналы вакыйганы без бүген – планлаштырылган вакыттан дүрт айга диярлек алдарак билгеләп үтәбез.

«Бигеш» подстанциясе проектын эшләү һәм гамәлгә ашыру вакытында тупланган тәҗрибәне «Челтәр компаниясе» ААҖ белгечләре алга таба да актив кулланачаклар.

– Бу объектны эксплуатацияләүче оешмаларга тапшыру бераз моңсурак та – без үз балабызны үстереп, олы юлга озатабыз шикелле, – дип билгеләп үтте «Челтәр компаниясе» ААҖ филиалы – «Түбән Кама энергорайонында төзелүче объектлар дирекциясе» директоры **Владимир Уржумцев.** – Илшат Шәехович ның җиңел кулыннан без әлеге төзелеш нигезенә беренче ташны салдык һәм шулай ук җиңел итеп, бернинди токкарлыкларсыз аны тәгәлләп тә чыктык. Ләкин моның белән безнең эшебез тәмамланмый әле. Техник прогресс, ә аның белән бергә энергетика объектларының җиһазланышы дәрәҗәсенә һәм аның куркынычсызлыгына карата таләпләр арта бара, димәк, безне алда тагын да кызыклырак, тагын да мөһимрәк яңа проектлар көтә.

PRESSA.RU

СЕНТЯБРЬДӘ ИННОПОЛИСТА БЕРЕНЧЕ INSPIRUSSIA ХАКАТОНЫ: **РОССИЯНЕҢ МАССАКҮЛӘМ БЛОКЧЕЙНЫ ҺӘМ ФИНТЕХ-ХАКАТОНЫ БУЛЫП УЗДЫ**

Сентябрь аенда Иннополис Университетында финанс технологияләре буенча Microsoft[1], IsimpleLab[2] һәм QIWI[3] компанияләре катнашында, InspiRUSSIA[4] финтех-акселератор – уртак проекты кысаларында Life.SPEDA[5] венчур фонды һәм Татфондбанк оештырган ике чара узды.

Воркшоп – динамик төркемнәрдә эшләү процессында катнашучылар яңа белем һәм күнекмәләр ала торган укыту чарасы.

Хакатон – төрле өлкәдәге белгечләрнең (программистлар, дизайнерлар, менеджерлар) нинди дә булса мәсьәләне чишү барышында үзара сөйләшеп эшләү форумы.

Блокчейн – теләгән һәркем нәрсә теләсә, шуны «куя» ала һәм анда нәрсә «ятканын» барлык кешеләр дә күрә, әмма мәгълүматларны бары тик хуҗа гына үзгәртә яисә юкка чыгара ала торган математик яктан мәгълүматларны саклау технологиясе.

2 сентябрьдә проектның кереш чарасы булган воркшопта Россия һәм чит ил экспертлары студентларга, эшмәкәрләргә һәм инвесторларга блокчейн-проектлар һәм Россия финтех-индустриясе үсеше перспективалары турында сөйләде. 17–18 сентябрьдә шул ук тематика буенча Россия һәм тагын биш илдән килгән 300дән артык катнашучы: программистлар һәм эшләүчеләр, дизайнерлар һәм web һәм мобиль кушымталар өлкәсендә проект авторларын җыйган хакатон үткәрелде.

InspiRUSSIA акселераторы – узган ел Life SPEDA фонды оештырган, InspirASIA[6] Сингапур акселераторы эшенең дәвамы. Көньяк-Көнчыгыш Азия стартаплары белән эшләп, команда Россиядә белем бирү программасын төзү өчен иң яхшы кейсларны һәм практиканы сайлап алган. Акселератор Иннополиста да үз филиалын ачарга планлаштыра. Life.SREDA венчурлык фонды җитәкчесе Максим Авдеев сүзләре буенча, компания Россиядә финанс технологияләре максималь дәрәҗәдә аңлаешлы булырлык инфраструктура төзергә җыена.

«Татфондбанк» ГАҖ Идарәсе рәисе Рамил Насыйров банкның перспектив технологияләрне гамәлгә кертүгә аерым игътибар бирүе турында әйтеп үтте:

– Без инновацияле үсешнең төрле вариантларын өйрәндек һәм партнерыбыз Life. SREDA фонды белән InspiRUSSIAда тормышка ашыра торган ачык инновация моделенә тукталырга карар кабул иттек. Тәҗрибә шуны күрсәтә: проектларны нәтиҗәле итеп тормышка ашыру өчен стартапларга көчле инфраструктура партнеры җитми. Татфондбанк InspiRUSSIA кысаларында әлеге рольне үз өстенә алды. Биредә банкның кирәкле эксперт һәм методологик ярдәм күрсәтә торган командасы бар. Без әлеге чараның иң кызыклы һәм иң яхшы идеяләрне тормышка ашыруга башлангыч булып торачагына ышанабыз.

Бәйгедә катнашучылар бер тәүлек дәвамында, чара партнерлары (Татфондбанк, iSimpleLab, Microsoft, QIWI) тәкъдим иткән әзер API* и SDK** нигезендә үзләренең программа кушымталарының прототиплары өстендә эшләп, уйлау режимында булды. Шул исәптән үз командаң белән читтән торып эшләргә яисә кемгәдер кушылырга рөхсәт бирелде. Күпләр хакатонда бер-берсе белән Telegram-чаты буенча танышты һәм командаларга берләште.

Мөрәҗәгать иткән кешеләрнең барысына да финтех-һәм блокчейн – индустриясенең танылган вәкилләре: Майк Голдин (ConsenSys[7]), Астрид Хакенберг һәм Константин Гольдштейн (Microsoft), Саймон Тейлор (Barclays Plc.[8]), Константин Хайсанов («Татфондбанк» ГАҖ), Степан Кашинцев (iSimpleLab), Александр Чепурной (ЮНК[9]), Григорий Петров (Voximplant[10]) һәм башкалар консультация бирде.

Финалда, шул исәптән читтән торып җибәрелгән 29 проект тәкъдир ителде.

InspiRUSSIA хакатонының җиңүчесе WhiteMoney – блокчейн бүленгән челтәре базасында юридик затлар арасында исәп-хисаплар системасы булды. Команда InspiRUSSIA Сингапур акселераторында катнашырга чакыру алды.

Татфондбанктан акчалата бүләкләрне FINFAIR (көндәлек тормышта кулланучыларга микротүләүләрне җиңеләйтә торган геймификация элементлары булган Telegram-бот нигезендә хезмәт күрсәтү), Tip&Go (чәйлекләр түләү өчен мобиль хезмәт) һәм Q Solution (ике продукт: түләү документларында штрих-кодлар һәм QR-кодлар буенча ТКХ хезмәтләрен түләү өчен кушымта һәм Татфондбанк өчен Telegram-бот) алды. Татфондбанк #schoolteam (Татфондбанк клиентлары өчен ташламалар һәм махсус тәкъдимнәр белән интерактив карта) проекты өчен мәктәп укучылары командасын аерым призлы сертификат белән бүләкләде.

Microsoftтан дигән номинациядә Yorso[11] проекты – тиз һәм ышанычлы халыкара документ әйләнеше өчен система җиңүче дип танылды.

– Җиңеп чыктыгызмы сез, әллә җиңелдегезме – бусы мөһим түгел, – без хәзер барыбыз да, ничек кенә булмасын, бер уенда! – дип нәтиҗә чыгарды Максим Авдеев. – Киләчәкне без бергәләп төзиячәкбез!

*API – тышкы программ продуктларында куллану өчен кушымта тарафыннан тәкъдим ителә торган класслар, процедуралар, функцияләр, структуралар һәм константалар җыелмасы. **SDK (software development kit) – аерым программалар пакеты, аппарат платформасы яки ОС өчен кушымталар булдырырга ярдәм итә торган эшләнмә чаралары комплекты.

Реклама. «Татфондбанк» ГАҖ, РФ Үзәк Банкының 2015 елның 7 декабрендәге 3058нче лицензиясе

[1] Microsoft – Майкрософт. [2] ISimpleLab – АйСимплЛаб. [3] QIWI – Киви. [4] InspiRUSSIA – ИнспиРаша. [5] Life.SREDA – Лайф.Среда. [6] InspirASIA – ИнспирАзиа. [7] ConsenSys – КонсенСайс. [8] Barclays Plc. – Барклиз ПиЭлСи. [9] ЮНК – АйОуЭйчКей. [10] Voximplant – Воксимплант. [11] Yorso – Йорсо.

«МАРКУС» МАРКШЕЙДЕРЛЫК КОМПАНИЯСЕ: ПРОФЕССИОНАЛЛАРГА ЫШАНЫГЫЗ

Маркшейдер – җир асты корылмаларын һәм файдалы казылмаларның чыганакларын разведкалаганда һәм аларны эшкәрткәндә пространство-геометрик үлчәмнәр буенча белгеч.

ООО “МАРКУС”
Маркшейдерская компания

Маркшейдер – аерым бер акыл сөрешенә һәм холык-фигыльгә ия кеше. Маркшейдерлык вазыйфасы аннан геодезияне, голографияне, географияне, физика һәм математиканы белүне, файдалы казылма чыганакларын эшкәртү технологиясенә ия булуны, төзелеш эшләренең нигезләренә төшенүне һәм пространстволы фикерләүне таләп итә. Болардан тыш, маркшейдер – үз эшен башкарганда тирән фикерле белә, җыйнак, педант һәм төгәл кеше. Чөнки аның эшендәге ялгышлар коточкыч югалтуларга, күп кешеләрне һәлак итәрлек фаҗигаләргә китерергә мөмкин. Маркшейдер эше зур хәрефтән языла торган профессионал булуны таләп итә. «МАРКУС» маркшейдерлык компаниясе үз эшендә нәкъ менә профессионалларга таяна. Компаниянең штатында Казан инженерлык-төзелеш институтын, Казан (Идел буе) федераль университетын (элекке КДУ), Пермь политехника институтын, Грозный нефть институтын, Идел буе Дәүләт технология университетын (Йошкар-Ола), Бодайбо тау техникумын, Бузулук гидромелиорация техникумын тәмамлаган кешеләр эшли. Икенче югары белем алырга теләүчеләрне компания Урал дәүләт тау университетына (Екатеринбург) юллый. «МАРКУС» мәктәбен үткән белгечләр «Татнефть» ГАҖндә, «Автострада» ААҖндә, «Геомониторинг» ҖЧҖндә эшли. Үзенең ун елга якын эшчәнлеге дәвамында (компания 2007 елның 26 февралендә теркәлгән) компания 250ләп проект башкарган. «МАРКУС» ҖЧҖ маркшейдерлык компаниясе эшләренең географиясе – Татарстан Республикасы, Ульяновск, Киров һәм Оренбург өлкәләре, Ханты-Манси автономияле округы, Саха Республикасы (Якутия), Красноярск крае. Икътисадтагы торгынлыкка карамастан, «МАРКУС» компаниясе үзенең базардагы урынын киңәйтә, күптән түгел Самара өлкәсендә берничә килешү төзеде.

Таш Бөек Болгар һәм Свияжск утрау-шәһәре тарихи объектларын торгызу эшләрендә кулланыла.

Маркшейдерлык хезмәтләреннән тыш, компания шулай ук инженерлык эзләнүләре, чикләрне ызанлау, геологик хезмәтләрне башкару, топографик төшерүләр, җир асты байлыкларын куллану объектларын төшерүләр белән дә шөгыльләнә.

«МАРКУС» ҖЧҖ үз эшенең барлык этапларын Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында, Ростехнадзорда һәм башка ведомстволарда бөтен документлар белән килештерүне үз өстенә ала. Авыл хуҗалыгы яисә урман җирләрен сәнәгать куллануына күчерүдә ярдәм итә.

Киң таралган файдалы казылма урыннарын тәҗрибә-сәнәгать рәвешендә эшкәртү проектларын эшләү – яңа хезмәтләрдән. Мондый проект заказчы компаниягә төп проектны документлаштыру этабында геологик разведка белән бергә файдалы казылманы чыгара башларга мөмкинлек бирә. Мондый мөнәсәбәт файдалы казылмаларны куллану буенча Федераль агентлык тарафыннан хупланган, чөнки табыш алырга, димәк, салым түләргә һәм яңа эш урыннары булдырырга мөмкинлек тудыра.

«МАРКУС» ҖЧҖ маркшейдерлык компаниясе Россия маркшейдерлар берлегендә тора һәм «Маркшейдерлык эшенә керткән өлеше өчен» дипломы белән бүләкләнгән. Бүләк проектларны башкарудагы профессиональлек һәм компания белгечләренең югары квалификациясе өчен алынган.

«МАРКУС» ҖЧҖ
Тел.: (843) 537-91-09,
факс (843) 537-91-09
markus-company@mail.ru,

Маркшейдер: (Mark – билге, чик сүзеннән +Scheider – бүлүче) – тау инженеры яки техник, җир асты яисә шуңа туры килгән җир өслеге мәйданнарында, башкарылырга тиешле тау һәм геология разведка эшләре планнарына, карталарына һәм кисемнәренә кертү өчен, пространство-геометрик үлчәмнәр үткәрү белгече. Маркшейдер шулай ук җир асты корылмалары төзелешенең һәм тауда табылган байлыкларны эшкәртүнең: җир өстендәгеләрен (карьерлар, кисемнәр, канаулар) һәм җир астындагыларын (шахталар, штольнялар, метро һәм скважиналар) барлык этапларын планлаштыруны һәм контрольдә тотуны тәэмин итә.

Маркшейдерлык эше – бу тау фәне һәм техникасы тармагы, аның предметы булып чыганакның структурасын, җир асты файдалы казылмасының формасын һәм күләмен, токым сыйдырган файдалы һәм зарарлы компонентларны, аларның үзлекләрен, чыгарылмаларны урнаштыру урыннарын, токымнарның һәм тау эшләре белән бәйле рәвештә җир өслегенең деформацияләнү процессын натурада үлчәүләр һәм алга таба геометрик сызымнар нигезендә өйрәнү, шулай ук тау предприятиесендә җитештерү процессы чагылышын өйрәнү тора.

Эшләр маркшейдерлык-геодезия приборлары ярдәмендә башкарыла. Мәгълүмат геометрик проекция ысулы белән алынган сызымнардан торган тау эшләре документациясендә синтезлана.



«Маркус» ҖЧҖнең маркшейдер җиһазлары.

ТР Лениногорск районындагы Кәркәле төзелеш ташы табу карьеры.

Реклама

PRESSA.RU

ҮСТЕНЛЕКЛЕ ЮНӘЛЕШ – ЯШЬЛӘР

Агымдагы елның сентябрендә «GMC Consulting» («Джи Эм Си Консалтинг») компаниясе Татарстан оешма һәм предприятиеләре HR-директорлары һәм кадрлар хезмәте җитәкчеләре өчен Кадрлар клубының чираттагы утырышын уздырды. Республика министрлыклары һәм ведомстволары ярдәме белән һәм аларның вәкилләре катнашында узган очрашуның темасы «Татарстан – 2030» стратегиясен тормышка ашыру кысаларында республика предприятиеләрендә яшьләр берләшмәләренең эшен оештыру торды.

GMC consulting

8 (843) 294-17-84,
Чернышевский ур., 39,
офис 5,
www.gmcconsult.ru

– Клуб утырышында безнең эш юнәлеше булган «Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясе» документы үзенең төп максаты итеп икътисадый үсеш, инновацион технологияләрне гамәлгә кертү, социаль яктан мөһим инициативаларны тормышка ашыру процессларына мөмкин кадәр күбрәк яшьләрне җәлеп итүне күздә тота, – дип сөйли «GMC Consulting» директоры Галина Маштакова.– Максатчан, мөстәкыйль уйларга өйрәнгән, инициативалы яшьләр генә бүгенге көндә республика үз алдына куйган гаять зур һәм амбициоз максат һәм бурычларны хәл итү эстафетасын кабул итеп алырга сәләтле.

– Әмма документ, гамәли яктан тормышка ашырылмаса, документ булып кына калачак бит. Бу яктан иң беренче адым – республика предприятиеләрендә актив яшьләрдән торган берләшмәләр оештыру. Клуб утырышында без яшьләр берләшмәләрен оештыру өчен кулланылырга мөмкин булган механизмнар һәм оештыру чаралары турында гына фикер алышмыйча, предприятиеләр әлеге мәсьәләгә җитди караган очракта ихтимал булган куркынычларның кимүе турында да сөйләдек, – ди Галина Маштакова. – Минә, мәсәлән, дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә төп куркыныч итеп яшьләр арасында эшсезлек, яшьләрне экстремистик оешмаларга тарту, креатив яшьләрнең зур шәһәрләргә яисә чит илгә китүе, гаилә кыйммәтләренең үстенлеге кимүе санала. Ике мәйданчыкта (Кама һәм Казан агломерациясе) үткәрелгән утырышларда без предприятиеләрдә яшьләр белән эшләүнең иң яхшы үрнәкләрен тикшердек, булган проблемаларны ачыкладык һәм яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өчен ресурслар базасын карадык. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләре яшьләр белән эшләүгә бәйле дәүләт программалары һәм подпрограммаларында катнашу өчен мөмкинлекләр тәкъдим итте.

Клуб утырышында катнашучыларның уртак эш нәтиҗәләре буенча төзелгән резолюция нигезендә яшьләр сәясәтен нәтиҗәле итеп тормышка ашыруда куллану өчен тәкъдимнәр исемлеге төзелде. Биредә яшьләр оешмаларын яңадан торгызу һәм/яки төзү, Эшләүче яшьләрнең республика оешмасы белән хезмәттәшлекне көйләү, эш бирүчеләр, эшкуарлык вәкилләре, гыйльми берләшмә, дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеге системасын төзү кебек оештыру характерындагы чаралар бар.

Кадрлар сәясәте чаралары арасында предприятиелщрдә өзлексез белем бирү системасын кертү, яшьләрнең кадрлар резервын булдыру, «Предприятие яшьләре» программасын эшләү (яшь хезмәткәрләргә ярдәм күрсәтү механизмын, аларның һөнәри һәм шәхси үсеше өчен шартлар тудыру механизмын кертеп) бар. Белем бирү юнәлеше түгәрәк өстәлләр, профильле учреждениеләр белгечләрен чакырып лекцияләр, һөнәри осталыкны ачыклау буенча бәйгеләр үткәрү рәвешендә тормышка ашырылырга мөмкин. Финанс ягыннан тәэмин итү чаралары яшьләр оешмалары эше өчен хезмәт хакын түләү фондыннан 1%тан да азрак булмаган күләмдә бүлеп бирелергә мөмкин.

– Без әлеге комплекслы документ предприятие җитәкчеләренә яшьләр белән эшләү юнәлешләрен билгеләүдә ярдәм итәр, дип ышанабыз. Ә без, үз чиратыбызда, Клуб утырышларын үткәрүне дәвам итәрбез һәм әлеге күпкырлы хезмәттәшлеккә төрле тармакларның HR өлкәсе вәкилләрен чакыруга бик шатбыз, – дип сүзен йомгаклый Галина Маштакова.

Реклама

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Александр Лаврентьев вертолёт заводын **НИЧЕК** алга җибәргән

«Кече Ватан патриотлары» Саҗидә Сөләйманованың туган көнен **НИЧЕК** үткәрделәр

Үзебезнең Карловы Вары **КАЙДА** урнашкан

Дәүләт серенә тиң рецепт **КЕМДӘ** саклана

PRESSA.RU

ӨСТӘМӘГӘ – ЯРТЫ ДӨНЬЯ

Казан вертолет берләшмәсенә директор булып килгәндә Александр Лаврентьевка нибары 38 яшь була. Катлаулы 90нчы елларда ул предприятиене саклап кала ала гына түгел, аңа яңа тормыш бүләк иткән кебек була. Аның җитәкчелегендә заводта винт канатлы машиналарның модельле киң линейкасы (кечкенә «Актай»дан алып 16 тонналы Ми-38гә кадәр) эшләнә башлый.

ПАРТИЯ ТИКШЕРҮЕ

Директорлык итә башлауның беренче елында гариза язып, моннан тизрәк китү теләге туды. Ул чакта без көненә бер ярым вертолет ясый идек (авиация сәнәгатендә бөтенесеннән дә күбрәк!) Бу – көн саен! Берәр төрле сәбәп белән бүген вертолёт тапшырылмый кала икән, иртәгә өчне тапшырырга кирәк була. Тагын да булмаса – бишне. Бервакыт төн уртасында дежур торучы: «Кабул итү туктатылды!» – дип шалтырата. 60 мең фюзелаж заклепкасының унысы җитми икән. Вертолётның сыйфатына бу йогынты ясамый, шулай да җитештерү процессын туктатырга кирәк. Һәм син мәсьәләне хәл итү өчен тизрәк заводка юл тотасың.

Соңгы көчкә кадәр эшләргә туры килә иде. Хәер, ул чакта бөтенесе дә шулай эшләде. Якшәмбе көнне килсәң, күршедәге дары заводында да эш кайнаганы ишетелә иде.

Ул елларда берәү дә ансат кына җитәкче булып китә алмады – кадрлар сайлау системасында партиянең роле гаять зур булды. Галәмәт зур иләктән илиләр иде! 34 яшемдә мин вертолёт заводының партия комитеты секретаре булдым – анда ике меңнән артык коммунист бар иде, менә шунда сыналдым да инде. Көтмәгәндә директор урыны бушагач, КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Гомәр Усманов минем кандидатураны тәкъдим итте. СССРның Авиация сәнәгате министрлыгының үз вариантлары бар иде, әмма Усманов үзенекен итте. Ул чакларда бөтен ил буенча нормаль хәл иде бу.

АТ БЕЛӘН ЙӨРЕШ

СССР авиация сәнәгате министры Силаев авиация заводына тикшерү белән ай саен килеп торды. Анда Ту-160ны үзләштерү бара иде, шуңа күрә яңарту, капиталь төзелеш өчен каралган акча беренче чиратта шунда җибәрелде. Ә вертолёт заводын калдык суммалар белән генә финансладылар. Предприятиене кичектермичә яңартып корырга кирәк иде. Бер килүендә Силаевны Гомәр Усманов белән икәүләп машинага утырттык та авиация заводы урынына безнекенә алып киттек. Цех ишеген ачты бу, ә анда коточкыч хәл – түбәдән су ага, бөтен нәрсә җимерелергә тора. Усманов аңа: «Әйдәгез, әйдә, анда кешеләр ничектер эшли бит әле», – ди. Силаев керде, карады. «Нигә болай бу синдә?» – ди бу миңа. «Сезнең калдыклык принцибы, Иван Степанович», – дим. Шул чакта яңартып кору һәм производствоны үзләштерү өчен заводка беренче тапкыр акча бирделәр.

АЛГА КАРАП ФИКЕР ЙӨРТҮ

1991 ел, ГКЧП. Мәскәүдән бер-бер артлы телеграммалар килә: беркемне дә чираттагы ялга җибәрмәскә, коралга (бездә ул да бар иде) якын китермәскә, сакны көчәйтергә. Кадрлар мәсьәләсе буенча директор урынбасары яныма килә дә: «Нишлибез?» – ди. «Берни дә эшләмибез», – дим. Кешеләр нормаль режимда, шөбһәләнмичә яшәргә тиеш. Ниһаять, бар да үз хәленә кайткач, безгә Мәскәүдән комиссия килде. ГКЧП чорын ничек уздыруыбызны тикшерделәр: яңасе, җыелышлар ничек оештырылган, нинди боерыклар бирелгән. Ә бездә, республиканың башка эре заводларындагы кебек үк, боларның берсе дә булмаган иде – директорлар корпусы һәрвакыт аек акыллы кешеләрдән торды.

Планлы хуҗалык җимерелгәч, ярты ел дәвамында без, гомумән, берни дә җитештермәдек. Яңа илгә килеп эләккәч, беркемгә дә кирәк түгеллегебезне аңладык. Уйландык. Профилебезне үзгәртергә була иде, билгеле, – хезмәткәрләр санын ике меңгә кадәр кыскартырга, кәстрүлләр җитештерә башларга һәм шул рәвешчә үзебезне хезмәт хакы белән тәэмин итәргә. Казанда андый хәлләр дә булды. Әмма без барыбер вертолет тематикасыннан читкә китмәскә булдык – кадрлар да, киңәйтергә мөмкин булган производство да бар иде бит. Акча гына юк иде. Ул чакта мине берничә тапкыр чакырып сүктеләр: «Ничек оят түгел сиңа? Һәммә җирдә хезмәт хаклары арта, ә синдә һаман түбән», – диделәр. Әмма мине кешеләр яклап килде. Җыелышларда башка нәрсәләр өчен тәнкыйтьләсәләр дә, хезмәт хакы турында сүз чыгармадылар. Аларны иртәгәге көн өчен сакларга тырышуыбызны барысы да аңлый иде.

«АНСАТ»НЫҢ ТУГАН ЧАГЫ

1998 елда авиация предприятиеләре җитәкчеләре Мәскәүгә авиатамаша карарга җыелды. Француз вертолет төзелеше вәкилләре дә килде. Бүгенгедәй хәтеремдә: сөйләшүләр өстәле артына утырганда гына миңа Казаннан җибәрелгән видеокассета суздылар: безнең яңа «Ансат» күккә күтәрелгән. Башкаларга да карарга тәкъдим иттем. Бөтенесе дә экранга текәлде. Соңгы кадрларга җиткәч, французлар торып бастылар да сөйләшүләрне икенче көнгә калдыруны сорадылар. Аларның яңа вертолетлары белән бер үк вакытта Россиянең дә үз вертолеты җитештерелгән – элек булмаган конкурент барлыкка килгән – бу французларны коточкыч аптырашта калдырды. Алар китте, ә мин коллегаларымнан котлаулар кабул итә калдым.

«Ансат» бик авыр, тулысынча акчасыз шартларда туды. Һәм без башкача Ми-8 белән генә чикләнә алмаячагыбызны аңладык. Мин министрлыкка 16 тонналы Ми-38не җитештерә башлау тәкъдиме белән бардым. Анда шундый шарт куйдылар – дәүләтнең бер сумына безнең өч сум туры килергә тиеш. Ә безнең бер сум да акча юк! Димәк, хезмәт хакы тагын да түбәнрәк булачак. Шулай да тырыштык. Башта туендыручыбыз – Ми-8не тулысынча яңартып ясадык. Аны сатканнан кергән барлык акчаны Ми-38не җитештерүгә керттек. Аннары – «Ансат». Акча тапсак, шуңа тоттык, бетсә, эшне туктатып тордык. Кеше ышанмаслык хәл иде бу! Бүген мин кайберәүләрнең еш кына: «Булдыра алмыйбыз – акча юк», – дигәннәрен ишетәм. Ни әйтергә инде моңа? Акча юк һәм беркайчан да булмаячак, ә эшләргә кирәк.

АҢНЫ ҮЗГӘРТҮ

Булышырга, әмма кысылмаска – Татарстан президентларының (беренчесенең дә, икенчесенең дә) бер яхшы сыйфаты бу. 90нчы елларда без Минтимер Шәймиев белән вертолет техникасының бөтен линейкасын бер заводта эшләргә сүз куештык. Беркайда да мондый нәрсә юк иде. «Бу безгә нәрсә бирәчәк?» – дип сорады Шәймиев. Бөтен дөньяда биш кенә ил вертолет техникасы чыгара иде. Ул чакта без Ми-8не, үзенчәлекләренә, тарихи шартларына, сәяси мөнәсәбәтләренә карап, билгеле бер дәүләтләргә генә сата идек (Куба, Кытай, Мисыр, Һиндстан һәм башкалар). Күп еллык хезмәттәшлек итү дәвамында партнерлар безнең вертолётларга яраклаштылар – ремонт базалары төзеделәр, очучылар составын әзерләделәр. «Хәзер ярты дөньяда диярлек безнең үз базарыбыз бар, шуннан файдаланыйк, – дидем. – Әмма бер вертолет белән генә түгел, ә бөтен вертолет продукциясе гаммасы белән». Без үсешебездә менә шуны нигез итеп алдык. «Ансат», «Актай», Ми-17, Ми-38 шушыннан китте дә...

Моның өчен безгә кешеләрнең аңын чын мәгънәсендә кискен рәвештә үзгәртергә туры килде. Заказчы таләпләрен үтәүне кагыйдә итеп алырга булдык. Мәсәлән, ул Израиль җиһазына күнеккән икән, димәк, аның өчен шундыйны җитештерәбез. «Ник кирәк ул?! – диделәр миңа. – Болай да сатып алалар бит аны!» Хаклыгыма ышандырырга туры килде. Башка заводлар шуның аркасында да бездән калышалар иде бит. Безгә аларча эшләргә ярамый иде инде.

Мәскәү, вертолёт тематикасының перспективалы икәнен һәм аның экспорт мөмкинлеген күреп, Татарстан җитәкчелеген завод акцияләрен сатарга үгетли башлады. Бөтен федераль җитәкчелек Казанга йөрергә керешә. Нәтиҗәдә «Россия вертолётлары» вертикаль интегралланган структурасы төзеделәр.

Бүген завод продукциясе тулысынча конкурентлыкка сәләтле. Аннары инде сәяси аспект башлана: кемнән сатып алачаклар – бездәнме, әллә америкалыларданмы? Үз вакытында мондый мәсьәләләрне хәл итү өчен мин бөтен дөньяны йөреп чыктым, күпчелек илләрнең безнең белән эшләгән баш командующийларын якыннан белә идем. Бүген безнең җирле җитәкчеләргә моның белән шөгыльләнергә бирмиләр – барлык әһәмиятле функцияләрне, шул исәптән сату һәм маркетингны да, холдингка тапшырдылар.

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

Ольга Туманская
әзерләде

PRESSA.RU



«САҖИДӘ АПА» ИСЕМЛЕ ТЫЮЛЫК

Автор:
Луиза Янсуар

Минем өчен Әлмәт, беренче чиратта, Сәҗидә Сөләйманова шәһәре. Дөрес, тумышы белән ул – Башкортостанның Яңавыл авылыннан. Яшьлек еллары да шунда узган булачак шагыйрәнең: монда Уфа педагогика университетында укыган ул, авыл мәктәпләрендә укытучы булып эшләгән. Әмма аны Сәҗидә Сөләйманова иткән шәһәр – Әлмәт.

Сәҗидә
Сөләйманова.
1965 ел.

«КЕШЕ БАРЫБЕР КОШЛАР НӘСЕЛЕННӘН...»

Кечкенәдән безнең өйдә бик сак кына, үз итеп искә алына торган бер исем бар иде – «Сәҗидә апаң». Бәләкәйрәк вакытта, әле дөньяны бик үк аңлап бетермәгәндә, Сәҗидә апа дигән еракта яши торган туганыбыз бар икән, шуны искә алалар, дип уйлый идем. Ул апаны китап-журналга мөкиббән булган, өебездән олы бер китапханә ясаган почтальон әбием аеруча үз итә. Кайчак аның шигырьләре басылган газета-журналларны да алып кайта. Андый

көнне Сәҗидә апаның шигырьләре кулдан-кулга йөри, аның турында сөйләшеп сүзләре бетми олыларның.

Һәрчак әдәби дискуссияләрдән кайнап торган өебездә Сәҗидә апа турында беркайчан да кычкырып сөйләшмиләр иде. Тыныч кына, сак кына, бераз моңсулык, сагыш та кушылган була ул саклыкка. Моңарчы аяк атламаган серле, таныш түгел тыюлыкка кергәндәй хис итә идем балачакта үземне. «Сәҗидә апа» дип аталган ул тыюлыкта язылмаган махсус кануннар бар, дип.

Аның шигырьләре кайда барсаң, шунда килеп чыга иде һавадан – Әби урманына менеп җиләк җыябызмы, Олы болында печән күбәлибезме, Түгәрәк чирәмдә көтү көтәбезме, күзләрен, куркуы күзенә чыккан яшь бәрәннәрне акыртып-бакыртып, ихатадагы өстәлгә сузып яткырып кыркыйбызмы...

Сагышлар йөздә чагыла,
әйдә, бер сөйләсеннәр!
Сагына дисә дисеннәр,
ялына димәсеннәр...

Соңыннан белдем: әбиемнең авыз эченнән генә өзлексез көйләп йөргән бу җыруы «Җырланмаган җырлар» поэмасыннан икән. Ә көтүдәге сарык-сыерларны төшке челләдә Мишәгә алып төшеп, хәл алырга туктагач, канатлары белән җилне сөзеп уйнаклаган карлыгачларны, йә булмаса карчыга очышын күзәтеп ятканда, менә бу юлларны бабам кабатларга ярата иде:

Кеше барыбер кошлар нәселеннән!
Төшләремдә очам кош булып.
Ничә очып, ничә мәтәлсә дә,
Кеше барыбер сайлый кош юлын...

Әлмәт язучылары һәм театр әһелләре.

«Бигрәк тормышчан итеп яза шул Сәҗидә апаң, – ди иде өлкәннәр. – Аның шигырьләрендә без барыбыз да бар...» Җырга һәвәс әбием аның «Туй җырын» туйларда аргыш булып йөргәндә, кияү белән кәләшкә атап, махсус җырлый иде. Ә сагышлырак чакларында Гүзәлия җырын, «Ах, җаныем Бибисара», «Урсал тауда»ны көйли. Мәктәптәге бер генә чыгарылыш бәйрәме дә Сәҗидә апаның сүзләренә Мәсгут Имашев язган «Саубуллашу вальсы»ннан башка узмый. Кыскасы, гаиләбезнең генә түгел, авылыбызның да күзгә күренмәгән почетлы гражданины иде Сәҗидә апа.

КИЛЕН – КАЙНАНА ТУФРАГЫННАН

Боларны Әлмәткә барганда Сәҗидә Сөләйманованың килене Асия апага сөйләп барам. Ул исә үз тәэсирләре белән уртаклаша:

– Миңа бит аны исән чагында күрү насыйп булмады. Без Әнвәр (Сәҗидә Сөләйманова белән Әдип Маликовның улы. – Авт.) белән әнинең үлеменнән соң шактый вакыт узгач таныштык. Әмма бу очрашу очраклы булмагандыр, дип уйлыйм. Сәҗидә Сөләймановны үсмер елларымнан ук укып туялмый идем. Кулыма аның «Кызыл каурыйлар» җыентыгы кергән чакны хәтерлим. Чыгарылыш сыйныф, беренче гашыйк булу, мавыгулар чоры, романтика... Һәр шигыре гел минем хакта кебек тоела иде!

– Ә Әнвәр абыйның Сәҗидә Сөләймановның улы икәнен белми идегезме? – дип сорыйм.

– Аннары белдем инде, – дип елмая Асия апа. – Язмыш миңа Сәҗидә Сөләймановны икенче тапкыр бүләк иткәндәй булды. Моңарчы мин аның язмышының тышкы катлавын гына белә идем бит – шигъриятен, аның турындагы истәлекләрне. Ә монда ул шигъриятне тудырган яшәеше,

Сәҗидә Сөләйманова белән Әдип Маликовның киленнәре Асия апа.

Фотолар: Луиза Янсуар

PRESSA.RU

Мәскәүдә Татар әдәбияты көннәре. 1964 ел.

тормышы эченә, син әйтмешли, «Сәҗидә Сөләйманова тыюлыгына» тирәнгәрәк үтеп керү насыйп булды. Чынлап та, тыюлык ул, чөнки әни тормышта бик тәрбияле, тыйнак кеше булган. Гади дә, бер үк вакытта бик мәгънәле дә яшәгәннәр алар. Менә шуннан соң мин аның иҗатын икеләтә хөрмәт итә башладым. Әнинең: «Тормыш, исәнме!» – дигән сүзе минем өчен бөтенләй башкача яңгырый башлады. Иҗатчы буларак, нинди нык, көчле рухлы, шул ук вакытта, нәфис-нечкә булса, хатын-кыз буларак та, шундый ук була алган бит ул.

Безне Казанда озатып калганда, Әнвәр абый, әнисенең юбилена «Рухият» фонды ярдәме белән нәшер ителгән «Сәҗидә Сөләйманова – шигърияттнең кукчәчәге» дип аталган бик затлы, саллы китапны тапшырып, болай дигән иде:

– Асия әни турында миннән дә күбрәк белә хәтта, ул бит аның иҗатына чын-чынлап гашыйк кеше. Ул сезнең өчен миңа караганда да яхшырак гид булачак.

Ул хаклы булып чыкты. Юлда китапны актара-актара, истәлекләргә күмелә-күмелә барганда, шуңа шаккаттым: Асия апа белән Әнвәр абый әниләре белән әтиләренең тормышына кагылышлы һәр фактны, һәр детальне җентекләп энә күзеннән үткәргәннәр, истәлекләр, хатлар, багышлаулар – китапта алар барысы да, хәстәрләп тупланып, тиешле урынына урнаштырылган.

Әлмәткә без 3 октябрьдә, Сәҗидә апаның туган көнендә түгел, ә бераз соңарып, 4се килеп төштек. Зиратка кердек. Монда Сәҗидә Сөләймановаының шигырьләрендә тәлгәш-тәлгәш булып янып торган балан-миләшләр сыгылып утыра. Сәҗидә Сөләйманова белән Әдип Маликовның янәшә торган каберләрен ачык китап рәвешендә эшләнгән таш тоташтыра – аның һәр ике битендә икесенең дә шигырьләре уеп язылган. Алар һаман да шигырь аша аралашадыр шикелле.

Сүз уңаеннан: Әдип абый Маликовка бу елның августында 95 яшь тулган булыр иде. Менә шундый парлы юбилей...

Мин туганчук яңа йолдыз туган,
Женьшень үскән, көмеш табылган.
Миннән башка көзге бер яфракка
Ятим булыр иде табигать...

– Әнинең шигъриятендә нәкъ менә шушындый көз яшь – кып-кызыл сусыл миләшләре, баланнары белән, – дип әйтеп куйды кинәт Асия апа, караташ китапны өстенә сибелгән яфраклардан чистарта-чистарта. Һәм шул вакытта мин аның үзенең дә Сәҗидә Сөләймановага охшаган булуын абайлап алдым. Үзенә дә әйттем.

– Миңа еш әйтәләр бу хакта, – дип елмайды ул. – Әнвәр дә башта ук әйтте...

– Күрәсең, халыкта «Килен–кайнана туфрагыннан» дип юкка әйтмиләрдер, – дип елмаям җавап итеп.

«ИСӘНМЕ, ӘЛМӘТ, ИСӘНМЕ!»

«Кече Ватан патриотлары» проекты кысаларында без, гадәттә, иҗатчының якташлары, туганнары белән очрашабыз. Сәҗидә апа шәһәренә кайткач, билгеле инде, язучылар һәм мондагы сәнгать әһелләре белән дә очрашмый китеп булмый иде. Шуңа киләсе маршрутыбыз – ТР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге булды. Ә ул Әлмәт дәүләт драма театры бинасында урнашкан. Дөресен генә әйткәндә, Әлмәттә язучылар белән театр әһелләре үзара бик якын аралашып, дус-тату булып яшиләр, дип беләбез. Бинадары да – уртак, күңелләре дә бер-берсе белән бәйләнгән. Ә бит бу күркәм традициягә дә заманында Сәҗидә апа, Әдип абыйлар урнаштырган икән.

Ул заманда нефть һәм яңа төзелешләр үзәге булган Әлмәттә талантлы, затлы язучылар плеядасы яши һәм иҗат итә. «Әлмәттә иҗади элита барлыкка килгән чор», – дип атыйлар аны әдәбият белгечләре. Язучы Шамил Маннапов сүзләренә колак салыйк:

– Әдип Маликов нефть төбәгендәге яшь талантларны барлап, аларны берләшмәгә оештырган, соңыннан ТР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеген ачуда башлап йөргән. Бу оешма белән шактый вакыт җитәкчелек тә итте ул. Республикабыздагы әдәби хәрәкәтнең үзәгендә кайнады бу гаилә. Аларның киң күңелле булуы, риясыз ярдәме белән әлеге төбәктән Шамил Бикчурин, Җәмит Рәхимов, Клара Булатова, Энҗе Мөэминова, Гәрәй Рәхим, Альберт Хәсәнов, Нур Әхмәдиев, Газиз Кашапов, Рәшит Әхмәтҗанов, Җәүдәт Дәрзаман һ.б. язучылар, шагыйрьләр, драматурглар, журналистлар үсеп чыкты. 1957 елда, Әдип абыйның «кодалавы» буенча, Әлмәткә гаиләсе белән Казаннан Гариф Ахунов күченеп килгәч, иҗади рух тагын да көчәя.

Әнвәр абый белән Асия апа туплаган истәлекләрнең кайберләренә дә күз төшерик:

– Әдип белән Сәҗидәнең кунакчыл йорты бөтен Әлмәт зыялыларын җәлеп итүче үзәккә әверелә. Аларда Казаннан килгән язучылар, композиторлар да, якын-тирәдәге башлап язучылар да куна кала. Мөстәкыйль рәвештә пианинода уйнарга өйрәнгән Сәҗидәгә кушылып, татар җырларын җырлый алар. Дәртләнеп биегәннән агач идән сайгакларында үкчәле туфли эзләре уелып-уелып кала.

– Сәҗидә – бер дигән аш-су остасы. Ул татар кухнясының пәрәмәчтән башлап чәкчәккә кадәр, мөгаен, бөтен ассортиментын теләгәнә йотардай итеп әзерли беләдер. Өйдә ясалган соклар, компотлар янына кышка әзерләнгән кетердәп торган кыярларны, тозлы помидорларны да кушсаң... Ә һәр табынның түрендә патша булып бәлеш утыра. Бәлеш пешерү буенча «мастер-класска» иптәш хатыннары да килгәли, тик «барыбер синекедәй үк тәмле чыкмый» дип зарланалар.

Сәҗидә Сөләйманова иҗатының иң дөрләп, күкрәп киткән еллары бу. Укытучы, лектор, радиода тапшырулар алып баручы, шагыйрә. Әни һәм Әдип Маликовка тормышта да, иҗатта да нык лы терәк булган хатын. Командировкалар, алсыз-ялсыз, кайнап торган тынгысыз хезмәт атналары. Иҗатка төннәр кала...

Исәнме, Әлмәт, исәнме!
Җан атып кайтып киләм.
Ни гомер тәбрикләмәдем
Хәерле иртәң белән.

Инанган һөнәрем синдә,
Уяу уткән төннәрем,
Һәр өйдә миңа сүз биргән
Радио дулкыннарым...

Тормыш иптәше Әдип Маликов белән.

Татар шигъриятендә нигездә ир-ат шагыйрьләр тәхет тоткан чакта килә дә шигърияткә Саҗидә апа, берни дәгъвагамый, дауламый гына, тыныч-тыйнак рәвештә алар янәшәсендә урнаша. Халык күңеленә үтеп керә. Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмнең фикере бик хак тоела бу җәһәттән – ул Саҗидә Сөләйманова биеклеген ир-ат шагыйрьләр дә әйтергә курыккан чынлыкны әйтә белүдә күрде:

– Саҗидә апа шигърияткә соң килде, олыгаеп, эченнән әрнеп, янып... Өлгергән, шигъри образлар белән тәмам тулышкан иде инде ул. Җиде-сигез ел эчендә шуңарчы исеме дә билгесез шагыйрә баш әйләндерерлек биеклеккә күтәрелде, ир-ат шагыйрьләр өйрәнерлек, Туфаннар хөрмәт итәрлек Шагыйрь булып җитеште.

БӨТЕН СОЮЗГА ТАНЫЛГАН ШАГЫЙРӘ

Әлмәттәге язучылар бүлегендә безне шагыйрә Миңзифа Әхмәтшина каршы алды. Чәй табыны корылган, абзыйлар җыелган иде. Иң беренче булып **язучы Әсгать абый Сәлахов** сүз алды. Ул әле Саҗидә апаны «Знамя труда» газетасында һәм радиода эшләгән чакларыннан ук хәтерли.

– Саҗидә апа белән беренче тапкыр 1965 елда «Знамя труда» газетасында эшли башлагач очраштым. Аңарчы Әдип абыйны белә идем, Саҗидә апа турында әле – ишетеп, шигырьләрен укып кына. Әдип абый белән бергә күреп аны. Саҗидә апа бик ачык, аралашучан кеше иде. Безнең редакциядә эшләүче Иван Винокуров белән Клара Васюхинаны һәм мине үз итте ул, дуслашып беттек. Винокуров Саҗидә апаның шигырьләрен русчага тәрҗемә итә иде. Мине татар малае булганга үз иттеме икән инде Саҗидә апа, белмим. Кешеләргә карата бик сизгер, сак иде ул.

Ул инде каты авырый башлагач, берсендә хәл белергә килдек. Кердек, утырдык. Саҗидә апаны танымадык. Озакламый ул китеп тә барды. Халык бик күп җыелган иде – озатырга килүчеләр. Аны бик хөрмәт итәләр иде әлмәтлеләр.

Бөтен Советлар Союзы яратып укый иде Саҗидә апаны. Аны нәкъ менә рус шагыйрьләре, язучылары күтәреп алды бит, тәрҗемә иттеләр, ул алар белән хатлар алышып яшәде. Әлмәттә торып, тугандаш республикалардагы тәрҗемәчеләре белән аралашып иҗат итте.

Хезмәт геройлары турында очерклар эшләде ул газета өчен. Ә хезмәт батырлары Саҗидә апаның кешелеклелегенә сокланып, аңа рәхмәтле булып яшәделәр – ул чакта иҗатчылар әле җирдән, туфрактан, кешеләрдән, халыктан аерылмаган иде.

«РАСХУТ МИННӘН», ЯКИ НОБЕЛЬ ПРЕМИЯСЕНӘ КЕМ ЛАЕК?

Әлмәттә яшәүче тагын бер язучы, табигать турындагы 50дән артык китап авторы **Альберт абый Хәсәнов** чәй мәҗлесебезне үзенең юморы белән ямьләп утырды. Заманында ул «Татарстан» журналының корреспонденты булып та эшләгән икән.

– Саҗидә апа бик ярата иде мине. Чөнки мин яратмаслык кеше дә түгел – партия взносын гел вакытында түләп бардым, 50 ел дәвамында бер хатын белән яшәдем, – дип шаяртуын дәвам итте ул. – Әдип абый белән Саҗидә апаларга мин бик яшьли барып эләктем. Әдип абый мине кунарга алып кайта иде өйләренә.

Казанда һәр елны әдәби ел йомгаклары уза иде – ду килә идек җыеннарда. Ул чыгышлар, ул бер-беребезне тәнкыйтьләү, фикер алышу... Саҗидә апа белән Әдип абый да киләләр, әлбәттә. Без, бер төркем язучылар – Рәшит Әхмәтҗанов, Әхмәт Рәшит, Разил Вәлиевләр... – җыеннардан соң, мәҗлес оештыру ягын карыйбыз. Саҗидә апа мине яшертен генә чакырып ала да, учыма акча йома: «Альберт, – ди, – бүген дә яшьләрнең мәҗлесен оештыр, менә, расхут миннән...» Мин инде очам, хәстәрлим берәр бүлмәдә.

Әдип абый бит дәрәҗәле, өлкәнрәк кеше, ул, билгеле инде, олпатрак язучылар белән утыра. Саҗидә апаның исә яшьләрне күрәсе, аларны тыңлыйсы килә. Күңеле безгә тарта... Ул, җай гына тегеләр яныннан чыгып китеп, яшьләр янына кереп утырырга ярата иде. «Бәхәсләшегез, диспутлар оештырыгыз, шигырь укыгыз... тыңлавы рәхәт», – дия иде. Аңа тусовка кирәк иде.

– Ә үзе катнаша идеме соң бәхәсләргә? – дип төпченәм Альберт абыйдан.

– Катнашмый ди! Әлбәттә, катнаша! Анда бит, күз алдыңа китер, сеңлем, һәммәсе Нобель премиясен алырга бер мин лаеклы, дип янып торган 10–15ләп җегет. Хатын-кызлардан – бер Саҗидә апа. Ул бик хөр фикерле иде, шуңа да аңа яшьләр белән кызык булгандыр... Әле бит аның артыннан гына китте гадәт – хатын-кыз язучыларның әдәбиятка килүе, аңа кадәр юк иде.

...Җирләгәндә, муенбызга ак сөлгеләр асып, Рәзим Вәлиуллин белән аны зиратка кадәр күтәреп бардык. Бик матур кояшлы, якты көн иде ул. Саҗидә апаның үзе кебек, – дип җөпләде сүзен Альберт абый.

«ХӘЕРЛЕ ЮЛ, ЛУИЗА!»

– Әни бит ул театрны искиткеч яраткан, премьераларны калдырмаган, актерлар турында язган, чын мәгънәсендә театралка булган, – дигән иде Асия апа, театрга кергәч үк. Аның сүзен **Татарстанның халык артисткасы Луиза Солтанова** эләктереп алды:

– Әле нинди генә!.. Мин Саҗидә апаны беренче тапкыр 1964 елда күрдем. Безнең театрда спектакль премьерасы иде. Икенче көнне репетициягә җыелдык, шунда миңа әйтәләр: «Сине шагыйрә-ханымның күреп-сөйләшәсе килә», – диләр. Мин инде каушап калдым. Саҗидә апа күз явын алырдай ап-ак костюмнан иде. Дулкынлануымны сизеп, күрәсең: «Мин гап-гади сораулар бирәчәкмен», – диде. Җавапларымны кассетага яздырып алды да, радиодан тапшырачакмын, диде. Ә аннары Әлмәт газетасында минем хактагы мәкаләсе басылып чыкты, «Хәерле юл, Луиза!» дип атала иде ул.

Ул чакта язучылар театр белән кайнашып яшиләр иде – уртак кичәләр уздыру, дисеңме, кунакка йөрешүләр, спектакльне кабул итү вакытындагы бәхәсләр, фикер алышулар. Премьераны бер язучы да калдырмый иде. Үтә бер-ике көн, газетада аларның тәнкыйть мәкаләләре дөнья күрә.

Ул чакта бездә Гамил Афзал, Гариф Ахунов, Рафаил Төхвәтуллиннар яшь иде. Гариф абыйның «Утлар яна учакта» пьесасын куйган чагыбызны һич онытмыйм. Мин анда Гүзәлияне уйнадым. Спектакль өчен Саҗидә апа махсус «Гүзәлия җыры»н

Саҗидә Сөләйманова премиясе лауреатлары һәм стипендиатлары шагыйрә бюстына чәчәкләр сала.

Фотолар: Әнвәр Маликов, «Рухият» фонды архивыннан

Әлмәт шәһәрендә Сажидә Сөләймановага куелган бюст.

язды, Мәсгут абый көен иҗат итте. Ул җырның халыкта ничек популяр булып китүен белсәгез!

Сажидә апа мине өйләренә чакыра иде дә: «Яз син, Луиза, театр турында яз», – дип өнди. Мин куркам, кая инде! Шулай кыстый торгач, язып карадым. Сажидә апа мине баштарак төзәтте, аннары мактады. Үтте микән атна-ун көн, «Социалистик Татарстан» газетасында минем мәкаләм чыккан!

Хәзер уйлап карыйм да гаҗәпләнәм: өй, гаилә, балалар, шигърият, укыту эше, радио, командировкалар... Ничек аның безнең белән утырырга вакыты калган да, күңеле җиткән?!

Әдип абый белән Сажидә апа безнең туебызда да булдылар. Сажидә апаның бүләген һаман да кадерләп саклыйм. Ул миңа бик матур сылу кыз сынын бүләк итте: «Луиза, бу статуэтка сиңа, дөресрәге, син уйнаган Баянсылуга охшаган, ул сезгә бәхет китерсен», – дигән иде.

Җирләр алдыннан бер үзәк өзгеч мизгел хәтеремә уелып калды: Сажидә апаның күз кабаклары өстенә, ачылып китмәсен, дип, биш тиенлек акчалар куйганнар иде. Әдип абый шуларны күреп алды да, ачыргаланып: «Алыгыз, өч тиенлеккә алыштырыгыз, биш тиенлекләр аның күзләре өчен артык авыр», – диде. Шул сүзләр һаман колагымда яңгырап тора...

«Ә МИН САЖИДӘ БУЛАМ...»

Эстафета Луиза ханымнан **Әлмәт дәүләт драма театры директоры Фәридә Исмәгыйловага** күчә. Фәридә апа балачагына сәфәргә кузгала:

– Миңа 8–9 яшьләр чамасы булгандыр. Әлмәткә Фатыйма апабызга кунакка килгән чагым. Менә ул мине Белоглазов урамындагы дус кызларына ияртеп алып китте. Кечкенә генә «хрущевка» иде ул, анда берничә ханым бар. Алар барысы ничектер бик якты, ягымлы, нурлы иделәр. Соңыннан гына белдем: берсе Сажидә Сөләйманова булган икән.

Сажидә апаны икенче тапкыр 1979 елда, яшьнәп торган май аенда, «Татарстан» кунакханәсендә очраттым. Миңа ул чакта 19 яшь, университетка укырга керергә килгән вакытым. Карыйм: күрше бүлмәдә бик тыйнак, сабыр гына апа яши. Гаҗәеп матур үзе... Ыспай итеп тарап, җыеп куелган алтынсу чәчләрен, зәңгәр күзләрен хәтерлим. Моңсулык бар иде ул күзләрдә... Болардан да бигрәк, аңардагы затлылык җәлеп итте – үзен тотышында да, сөйләшүендә дә. Хәтта гәүдәсен төз, туры итеп йөртә белүендә үк.

Без сәлам бирештек, бер-ике җөмлә алыштык. «Мин дә Әлмәттән, Сажидә буламын», – дигән иде ул ханым. Мин әле ул чакта әдәбияттан шулкадәр ерак кеше...

Ул һәр иртәдә иртүк торып каядыр чыгып китә иде, кичләрен соң гына кайтып керә. Ишектә очрашабыз да, сәлам бирешәбез, хәл-әхвәл белешәбез. Аның янына үзе кебек үк сөйкемле, аңа бик тә охшаган егет ки-

ИСЕМЕ – МӘҢГЕЛЕК

Сажидә Сөләйманованың 80 яшьлек юбилее уңае белән «Татнефть», шагыйрәнең исемен мәңгеләштерү, хәзерге әдипләрнең талантын билгеләп үтү, әдәбиятка яңа аяк баскан иҗатчыларны үстерү, аларга матди ярдәм күрсәтү максаты белән, әдәби премия булдырды. Премия поэзия, проза һәм драматургия төренә караган һәм соңгы ике ел эчендә дөнья күргән әсәрләр өчен бирелә. Номинантлар ТРның Язучылар берлеге тарафыннан тәкъдим ителә. Һәр елның октябрь аенда Әлмәт шәһәре бәйрәм кабул итә – С. Сөләйманова премиясен тапшыру тантанасы Казанда узган Тукай бәйрәменә тиң төсмер ала бирелә.

Бәйрәм С. Сөләйманова бюстына чәчәкләр куюдан һәм шигъри митингтан башлана. Аның исемендәге премияне алган һәм булачак лауреатлар, стипендиатлар чыгыш ясый. Бәйрәм Әлмәт дәүләт драма театры коллективы белән берлектә оештырыла – кичен театр сәхнәсендә инде чып-чын театральләштерелгән тантана башлана. Бу церемониядә Әлмәт муниципаль районы хакимияте дә, «Татнефть» ГАҖнең җитәкчелеге дә, Казаннан килгән бер төркем кунаклар, иҗат әһелләре дә катнаша. Артистлар С. Сөләйманова иҗатын һәр елны кабатланмас, яңача итеп, сәхнәдән тәкъдим итә. Тантанага шагыйрәнең якташлары да чакырыла – Башкортостанның Яңавыл, Тәтешле районнары вәкилләре бәйрәмнең дәрәҗәле кунаклары исәпләнә.

«Татнефть» компаниясенең генераль директоры урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев әйтүе буенча, премияне алырга теләүчеләрнең саны елдан-ел арта бара, бу, әлбәттә, аның абруе үсүе турында сөйли. С. Сөләйманова премиясенең беренче карлыгачлары булган стипендиатлар инде югары уку йортларын тәмамлап, Татарстанда гына түгел, ә Россиядә, хәтта чит илләрдә дә иҗаты белән танылып өлгерде. «Аларны зур әдәбият мәйданына озатканда, өметләребез зурдан иде. Хәзер уңышларын ишетеп куанабыз», – дип, шатлыгы белән уртаклашты «Рухият» фондының директоры Флюра Шәйхетдинова.

Бүгенге көнгә С. Сөләйманова премиясенә ТР Язучылар берлеге әгъзасы булган, татар һәм рус телләрендә иҗат итүче 65 язучы лаек булды. «Премиянең географиясе елдан-ел киңәя, – ди Флюра Шәйхетдинова. – Татарстанда яшәп иҗат итүче каләм әһелләренә генә бирелми ул, безнең лауреатлар арасында Башкортостанда, Ульяновскида, Ижауда, хәтта Төркиядә яшәүче язучылар да бар». Стипендиатларга килсәк, Татарстанның 85 гуманитар һәм техник вузлары, техникум һәм колледжларында белем алучы студентлар бу.

2015 елда, премияне гамәлгә куюга 10 ел тулу уңае белән, премия күләме арттырылды.

леп йөри иде, соңыннан мин аның улы Әнвәр булуын белдем. Без янәшә биш көнләп яшәгәнбездер. Күп еллар узгач кына мин аның халыкның яраткан шагыйрәсе Саҗидә Сөләйманова булуын белдем.

– Әнинең бик нык чирләгән вакыты булган инде ул, – дип уфтанып куйды, тыңлап бетергәч, Асия апа. – Гомеренең һәр көне санаулы чагы…

Йөгерә-атлый килэм җәйләүләргә таба,
җәяүләргә кала, җәяүләргә кала,
сыгылмагыз әле, сабыр канатларым,
бер йотымга сусап, көтәдер атларым.

«ИМЗА КУЕЛМАГАН БЕРКЕТМӘ»

Саҗидә апа, операцияне Казанда ясатырга киңәш итсәләр дә, Әлмәттәге хирургны – Виктор Поляковны сайлый. Беренче операцияне аңа 1975 елның 11 мартында ясыйлар. Шуннан соң, ул тернәкләнеп китә, аңа иҗат дәрте кайта. 1976 елда Саҗидә Сөләйманова табиблар тормышы турында чәчмә әсәр язарга ниятли. Поляковка үтенеч белән мөрәҗәгать итә: ул ясаган операцияләргә кереп утырырга таләвен белдерә.

Әдип Маликов истәлекләреннән:

– Менә ишеттегезме? – ди Поляков, янында торган табибка карап, – гаҗәеп хәл. Мондый пациент минем өчен яңалык.

Поляков уйга кала. Саҗидәгә ак халат бүләк итә, үтенечен уңай җавап бирә.

Саҗидә Сөләймановaның Виктор Поляковның шулай ук яман шеш авыруыннан вафат булган әнисенә атап язылган «Хирургның әнисенә хат»ы да, «Гөлбадран» повесте дә татар укучысына яхшы таныш. Әсәр «Казан утлары»нда басылып чыкканнан соң, редакциягә хатлар агыла. Менә шундый хатларның берсе:

– «Гөлбадран» повестен язуыгыз өчен Сезгә нинди генә теләкләр теләргә соң?! Ничек сез шулай врачлар эшен тирәнтен белә алдыгыз, әллә үзегез врач булып эшлисезме? Кешеләргә үлмәс әсәр бүләк иткән кешенең бәхетле булмаска хакы юк, – дип яза Казаннан Гөлгенә Булатова.

1978 елның көзендә авыру үзен кабат сиздерә башлый. Саҗидә апаның хәле аеруча авырайган көннәрнең берсендә Виктор Поляков Казанга, Татарстанның баш хирургы Михаил Розенгартенга шалтырата. Хәлне аңлап, Розенгартен кичекмәстән самолетка утырып Әлмәткә оча. Ул шагыйрә белән беренче очрашуын болай искә ала:

– На больничной койке, одиноко стоявшей в неуютном кабинете Полякова, лежала моложавая женщина с нежной, почти прозрачной бледной кожей. На ее лице не было ни тени страдания, ни тревоги… Только огромные голубовато-карие глаза (да, у нее был такой редкий цвет) вопросительно и печально смотрели на меня…

Сознавая фатальность исхода, помню, не то мне, не то себе она тихо сказала почти в стихах:

– Жаль!.. Как много хочется в стихах мне изложить, сказать и долюбить.

Сажида понимала, что живет на одолженное время…

Гомеренең соңгы елында янәшәсендә булган һәркем – туганнары да, дуслары да, каләмдәшләре дә – аның рухы белән көчле, сабыр булып калуы турында сокланып сөйлиләр.

– Хәлләнә башлагач, Саҗидә миннән кәгазь-каләм сорап алды. «Шигырь туарга азаплана бит әле», – дип язган Әдип Маликов.

– Кайчак уйлавы да куркыныч: кешегә шушындый язмыш дөньяны дәвалый алырдай шигърият калсын өчен биреләме икән әллә… – дигән иде бер туганыбыз Саҗидә Сөләйманова турында, үзенең хәле инде кыл өстендә булганда.

Фәлән вакыт гомерең калган, диеп,
Син куркытма, доктор, өркетмә,-
Күреп торам: язмыш өстәлендә
Имза куелмаган беркетмә.

Мендәр астында Саҗидә апаның китабы булды. Ахыргача.

ВӨҖДАН СЫНАВЫ, ЯКИ ДӘВАМ

Ике операция арасында Саҗидә Сөләйманованың поэзиясе ике тапкыр Тукай бүләгенә тәкъдим ителә һәм шушы хәллөрдән соң бер шагыйрь Саҗидәгә сорау бирә:

– Дошманнарың бармыни соң? Без бит синең поэзияңә гашыйк…

– Лаеклы дошманнарым юк, – дип җавап бирә моңа Саҗидә, – ә астыртын аяк чалучы кара көнчеләр бар, – дип искә ала «Гомер мизгелләре» китабында Тукай премиясе тирәсендә барган матавыкларны Әдип Маликов.

– Китапны әзерләгәндә, бу «искергән» теманы кузгатмаска тырышып карасак та, барып чыкмады, – ди Асия апа. – Әмма ул китапның укучысы бу хакта бар дөреслекне белсен, кешеләрнең позициясеннән хәбәрдар булсын өчен генә эшләнде.

Саҗидә апаны мәртәбәле бүләккә үзе исәндә – ике тапкыр, үлеменнән соң янә бер тапкыр тәкъдим итәләр. Үзе исәндә дә, үлеменнән соң да – барып чыкмый. Минем үзем өчен бу сорау озак еллар буена ачык булып калганга, Асия ападан төпченүемне дәвам иттем. Әмма ул, ягымлы гына, сабыр гына, ләкин артык сорауларга урын калмаслык итеп кистереп куйды:

– Мин бу мәсьәләне бүген кайтарып сөйләшеп утыруны кирәк тапмыйм. Әни бик тыйнак, булганына шөкер итә белә торган кеше булган. Аның өчен шигъриятенең, шәхесенең халык тарафыннан ничек яратып, ихтирам күрсәтеп, югары кабул ителүен белү премияләрдән югарырак бәя булыр иде. «Татнефть»нең «Рухият» фонды Саҗидә Сөләйманова исемен мәңгеләштерүдә никадәр көч куя – юбилеена менә дигән китабын чыгардык, Әлмәттә аның бюсты тора, аның исемендәге урам бар, Саҗидә Сөләйманова исемендәге премия булдырылды, аның стипендиясе бар… Бу соң шатлык түгелмени?! Әни, исән булса, бик бәхетле һәм рәхмәтле булыр иде, миңа калса…

Бу хакта язучы Госман Садә болай дип язып чыккан иде:

– Тукай бүләгенә тәкъдим ителеп тә, шушы олы бүләккә ия була алмыйча, бу дөнья белән бәхилләшкән Саҗидә апа! Менә гаҗәп! – бүген исә ул үзе каләмдәшләренә, әдәбиятка юл яручы яшь буынга үз исемендәге бүләкләрен өләшә.

Һәм бу чынлап та дөрестер: ике язучы яшәгән кечкенә генә фатирга Әлмәтнең иҗат дәрте белән типкән бөтен йөрәге, кулына каләм алган яшьләре сыя, шунда үзенә канатлар алып, ныгып чыга алган икән, димәк, бу матур традиция һаман да дәвам итә. Саҗидә апаның йөрәгенә сыя алар – аның дәвамчылары.

Саҗидә Сөләйманова премиясе стипендиатлары Әнвәр Маликов белән.

Фотолар: Әнвәр Маликов, «Рухият» фонды архивыннан

PRESSA.RU

Реклама

ШИФАХАНӘЛӘРГӘ **СӘЯХӘТ**

Белмибез генә без. Шуңа сәламәтлегебезне ныгытабыз, дип, әллә кайдагы Карловы Варыга, яисә тагын да ераккарак – Баден-Баденга ук чыгып китәбез. Борын төбебездә генә алардан һич ким булмаган үзебезнең «Карловы Вары» барлыгын әллә, әйткәнемчә, белмибез, әллә ышанырга теләмибез – янәсе, кая инде ул безнекеләргә бөтен дөньяга танылган шифаханәләргә җитү! Ә бит якын тирәбездә генә алардан яхшырак та, сыйфатлырак та итеп ял итәргә һәм дәваланырга мөмкин, өстәвенә, юлга да күп вакыт сарыф ителми.

«Татарстан» республика шифаханәләренә сәяхәт итеп кайтты һәм аларда күргәннәрен кәгазьгә төшереп барды.

ӨЧ ЙОЛДЫЗ

БЕРВАКЫТ, 1914 елда, Казанның хөрмәтле гражданины, сәүдәгәр Михаил Оконишников хатыны белән елга буйлап сәяхәт иткәндә, шәһәрдән егерме чакрымлап ераклыкта әкияти матур урынга игътибар итә һәм шунда үзләренә дача салырга ниятли. Шул елның августында Беренче бөтендөнья сугышы башлана, шулай да миллионер Оконишников дачасын төзеп бетерергә өлгерә. Ул хәйран нык килеп чыга (цементны тавык күкәйләрендә болгатып эшлиләр бит), янәшәдә хуҗалык корылмалары да торгызалар: аерым аш өе, кареталар өчен гараж, хезмәтчеләр яши торган йортлар, ат сарае, мунча, кымыз эчү йорты, чатыр, басма, шулай ук кечкенә генә электростанция (1915 елда аннан барлык биналарга электр уты үткәрелгән). Окошниковлар утары янында Идел ярлары аеруча текә булганга, дачаны «Крутушка» дип атаганнар.

Революциядән соң төрле елларда Крутушка территориясендә тәрбияләргә авыр булган һәм ятим үсмерләр өчен мәктәп-коммуна, фронтовиклар өчен эвакогоспиталь, туберкулез белән авыручылар өчен шифаханә, «Крутушка» ял йорты, соңыннан, 1968 елда, шул исемдәге шифаханә оештырыла.

БҮГЕН «Крутушка» турында кешеләр яхшы белә, әмма ни өчендер алар хәтерендә ул авыр 90нчы еллардагы халәтендә саклана; ул чакта бирегә сәламәтлекләрен ныгытырга килүчеләрне кыршылган стеналар, күгәреп беткән дәвалану ванналары каршы ала торган булган. «Крутушка»га килеп төшкәч, без ул вакытларның инде күптән онытылуын, хәерчелекнең һәм хуҗасызлыкның эзе дә калмавын аңладык. Хәзер биредә җиһазлар – өр-яңа, дәвалау – заманча, яшәү – өч йолдызлы.

«Крутушка»ның өстенлеге – бирегә һәркемнең килә алу мөмкинлеге (ул шәһәрдән 6 км гына ераклыкта урнашкан) һәм уникальлеге (табигый минераль су һәм ләм белән дәвалау ысуллары). Шифаханәгә иң беренче булып ял итәргә килгән кешеләр су эчкән каланча да исән.

Дәвалау эшчәнлегенең төп юнәлешләре:
- йөрәк-кан тамырлары;
- терәк-хәрәкәт аппараты;
- неврология авырулары.

Биредә бальнеология, физиотерапия һәм башка савыктыру процедураларын үз эченә алган комплекслы дәвалау тәкъдим ителә.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

ГӘРӘБӘЛЕ ДӨНЬЯ МОГҖИЗАСЫ

БЕРВАКЫТ, Икенче бөтендөнья сугышы вакытында, Ленинградтан бөтендөнья зәркән сәнгате шедевры – аталы Гәрәбә бүлмә югала.

Бу могҗизаны Пруссия монархы Вильгельм I дән буйлары ике метрдан арткан 55 рус солдатына алыштырып алган булалар. Гәрәбә бүлмә рус патшасы Петр I казнасында әнә шулай пәйда була һәм 200 ел дәвамында бик күпләрнең күзләрен иркәләп тора. Әмма Бөек Ватан сугышы вакытында Гәрәбә бүлмә юкка чыга – гитлерчылар аны Кенигсбергка алып китә һәм анда аның эзе югала.

Гәрәбә бүлмәне Сталин кушуы буенча 1949 елда гына актив рәвештә эзли башлыйлар, әмма файдасы булмый.

1979 елда Петербургта мәшһүр Гәрәбә бүлмәне торгызу эшенә керешәләр, моның өчен 6 тоннадан артык гәрәбә сарыф ителә.

Бүген бу бүлмәне Царскосельск музеенда күрергә була. Ул дөнья могҗизаларының берсе булып исәпләнә. Әмма бу могҗизаны күрер өчен шулай ерак бару мәҗбүри микән?

– Һич юк, – ди «Газовик» шифаханәсе баш табибы Рәшит Абашев. – Бездә дә бар ул. – Һәм «Газовик» могҗизасын күрсәтергә үзләренең гәрәбә бүлмәләренә алып керә. – Бу бүлмә чын гәрәбә кыйпылчыкларыннан эшләнгән, тулаем алганда, ул организмга уңай тәэсир итә һәм иммунитетны ныгыта, – ди әңгәмәдәшебез, табигый гәрәбә өстеннән атлый-атлый...

БҮГЕН Гәрәбә бүлмәгә һәм «Газовик» шифаханәсенең үзенә газ тармагында эшләүчеләр югары бәя бирә, анда гаиләләре белән бик яратып йөриләр. Аларның әйтүенә караганда, бу шифаханәне башкага алыштыра алмыйлар, чөнки мондагы матурлык бүтән беркайда да юк. Ул матурлык уңга карасаң да күренә, сулга карасаң да, алда да шул ук матурлык, ә какшаган сәламәтлек исә артта кала, биредән кайтып киткәндә һәркем үзен яңа туган бала кебек хис итә.

Дәвалау эшчәнлегенең төп юнәлешләре:
– йөрәк-кан тамырлары һәм нерв авырулары;
– сулыш һәм ашкайнату органнары проблемалары;
– тире һәм терәк-хәрәкәт аппараты авырулары;

Ләм белән дәвалану өчен биредә «Ундоры» дәвалау балчыгын кулланалар. Ул буын авырулары, гинекология һәм урология проблемалары, шулай ук тире авырулары белән көрәшергә ярдәм итә.
Биредә ял итүчеләр организмнарын «Нафтуся» минераль суы ярдәмендә ныгыталар.

ИЖЁВКА ЧЫГАНАГЫ

БЕРВАКЫТ, 1907 елда, Малмыж мещаны Д. Ф. Спиридонов дәвалау үзлегенә ия булган җирле Ижёвка минераль суын бөтен Россиягә танытырга тели. Башта ул Казан университетының химия лабораториясендә суның составын тикшерүне оештыра. Анализ Ижёвка чыганагы суының минеральләшү дәрәҗәсе шактый зур икәнен, шулай ук ионнарның үзара шактый сирәк бәйләнеше барлыгын күрсәтә – бу суны бальнеологиядә дә, терапия өлкәсендә дә кулланырга мөмкин икәнен аңлата.

1908 елдан Спиридонов Ижёвка минераль суын халыкка таныту буенча чып-чын кампания җәелдереп җибәрә, Газеталарга белдерүләр бирә, аның тырышлыгы белән Ижёвка суы күргәзмәләрдә катнаша һәм үзенчәлекле составы өчен югары бүләкләр һәм медальләр ала.

Спиридонов зур бөтенроссия курорты төзү хыялы белән яши башлый.

Һәм 1923 елда бу хыял «Ижёвка чыганагы» дигән исем һәм эшә торган курорт дигән статус ала. Беренче чорда мөмкинлекләр әллә ни зур булмый – бүрәнәдән эшләнгән биналарга нибары 25 карават сыйдырыла.

«Ижёвка минераль сулары» курортының төп корпусын төзүчеләр 1984 елда файдалануга тапшыралар. Бу вакыйга җирле һәм республика матбугатында киң яктыртыла: «ТАССРда 500 урынлы ел әйләнәсе эшли торган яңа курорт ачылды!»

БҮГЕН «Шифалы су-Ижминводы» шифаханәсе – халыкка заманча югары дәвалау технологиясе кулланып хезмәт күрсәтүнең ачык мисалы. Ул Чулман елгасының биек ярында, искиткеч матур болыннар һәм урманнар кочагында урнашкан. Курорт территориясендәге һава ионнарга гаять бай, бу сулыш органнары, йөрәк-кан тамырлары, нерв авыруларын дәваларга мөмкинлек бирә.

Дәвалау эшчәнлегенең төп юнәлешләре:
– ашказаны-эчәк тракты;
– терәк-хәрәкәт аппараты;
– нерв системасы;
– матдәләр алмашы бозылу һ.б. авырулар.

«Шифалы су» минераль суы – шифаханәнең төп, уникаль дәвалау факторы. Ә йод-бром тозлыгы белән ясалган ванналар кешенең физиологик системасына уңай тәэсир итә. Тәбәрле торфының дәвалау ләме регенерация процессларын тизләтә һәм организмның ялкынсынуга каршы көрәшенә ярдәм итә.



ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

PRESSA.RU

ҖӘННӘТ ПОЧМАГЫ

БЕРВАКЫТ, 1938 елда, Казанга кунакка килгән бер грек кешесе Казансуның сул ярындагы искиткеч матур урманга барып чыга. Табигатькә соклануын белдереп: «Ливадия!» – дип тел шартлата. Бу – «җәннәт почмагы» дигән сүз икән. Безнекеләргә әлеге матур сүз ошап китә, һәм озакламый биредә шул исемдәге дәвахәнә барлыкка килә.

1962 елда ул шифаханә статусы ала һәм үзенчәлекле дәвалау традицияләре һәм кунакчыллыгы белән дан казана.

БҮГЕНГЕ «Ливадия» – шәһәр уртасындагы уңайлы кунакханә, анда сыйфатлы дәвалау процедураларыннан файдаланып кына калмыйсың, мең еллык шәһәрнең истәлекле урыннарында йөреп, искиткеч матур тәэсирләр алып та кайтып китәсең.

Биредә инфаркттан соң дәваланырга килүчеләрне аякка бастыралар, йөрәкләренә операция кичергәннәрне тернәкләндерәләр, йөкле хатыннарга, шикәр чире белән авыручыларга ярдәм күрсәтәләр...

Дәвалау эшчәнлегенең төп юнәлешләре:
– кан әйләнеше системасы:
– сулыш органнары:
– офтальмология;
– эндокрин һәм нерв системасы;
– ашкайнату органнары һ.б. авырулар.

Биредә сульфат-магний-кальций составлы минераль су һәм Кырымдагы Саки күленең дәвалау үзлегенә ия булган ләм балчыгы ярдәмендә дәваланалар. Йод-бромлы, хлорид-магнийлы, күкертле водороды да булган минераль су йөрәк-кан тамырлары һәм нерв системалары, ашказаны-эчәк тракты авырулары вакытында организмга уңай тәэсир итә. Дәва ләме ялкынсынуга каршы көрәшү, авыртуны басу һәм җәрәхәтне төзәтү сәләтенә ия.

САВЫГУ ҺӘМ ИЛҺАМЛАНУ

БЕРВАКЫТ, йөз еллап чамасы элек, бу урынга кешеләр сәламәтлекләрен ныгыту – территориянең төрле почмакларында җир астыннан бәреп чыккан табигый чыганакларның шифалы суын эчү өчен килә торган булганнар. Аккош күле һәм Раифа тыюлыгының Васильево бистәсенә барып тоташучы, корабль төзү өчен файдаланыла торган урманнары биредә шифалы климат барлыкка китергән. Һәм ике йөз яшьлек наратлар арасына кешеләр дәвахәнә төзәргә карар кылган.

Бөек Ватан сугышы елларында биредә хәрби госпиталь урнаштырыла.

Төрле елларда шифаханәдә Муса Җәлил, Әхмәт Исхак, Сибгат Хәким, Әхмәт Фәйзи, Хәсән Туфан ял итә. Табигатьнең нәкъ менә шушы почмагы шагыйрьләрдә илһам уята да.

БҮГЕН шифаханәнең үзенең ике минераль чыганагы аның төп өстенлекләренең берсе булып тора. Химик составы буенча скважина суы мәшһүр Карловы-Вары һәм «Усть-Качка» курортларының йод-бромлы тозлыкларына нык охшаган.

Шифаханә территориясендә шулай ук эчә торган югары минеральләшкән сульфатлы-хлоридлы-натрийлы минераль дәвалау суы чыгарыла, аны иң әүвәл ашказаны-эчәк тракты авырулары вакытында кулланырга киңәш итәләр… кирәклеге мәгълүм.



Реклама

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ, НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

НАРАТЛЫ МИКРОКЛИМАТ

БЕРВАКЫТ, тарих күзлегеннән караганда күптән түгел – 1984 елда, наратлык эчендә бер пионер лагере ачыла, һәм ул соңыннан җыйнак кына дәваханә итеп үзгәртелә; анда ике йокы корпусы, кечкенә генә ашханә һәм дәвалау бүлеге була. Ылыс исе аңкыган һава ял итүчеләрнең организмына һәрвакыт уңай тәэсир итә. Сулыш аппараты авыруларыннан интеккән кешеләр өчен ул аеруча файдалы. 2000 елда дәвалау-савыктыру комплексына шифаханә статусы бирелә. Ул актив рәвештә үсә һәм ял итүчеләрне үзенә торган саен күбрәк җәлеп итә бара.

БҮГЕН бирегә махсус уникаль дәвалау базасы төзелде. Ул заманча Европа уңайлыклары һәм дөрес оештырылган дәвалау-сәламәтләндерү программалары белән аерылып тора.

Шифаханәнең ылыслы агачлар тудырган үзенчәлекле микроклиматы дәвалау факторларының берсе булып исәпләнә. «Нарат урманы» хезмәткәрләре клиентларның сәламәтлекләрен генә ныгытып калмыйлар, «планетабызның үпкәсе» турында да кайгырталар – ел саен дәваханә территориясендә чыршы, нарат, кедр агачлары утырталар.

Еллар дәвамында яуланган шифаханә статусы халыкара дәрәҗәгә чыгарга ярдәм итте. Ул инде республикабызның брендына әверелде. Бүген «Нарат урманы»н Татарстан һәм Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә беләләр.

Дәвалау эшчәнлегенең төп юнәлешләре:
- нерв һәм йөрәк-кан тамырлары системалары;
- аш эшкәртү тракты эшчәнлеге бозылуы;
- сулыш органнары;
- терәк-хәрәкәт аппараты авырулары.

Васильевога дәваланырга һәм сәламәтлекләрен ныгытырга килүчеләргә «Нарат урманы» медицина өлкәсендәге соңгы казанышлар ярдәмендә хезмәт күрсәтә.



ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ, НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

PRESSA.RU

ГАП-ГАДИ МОГҖИЗА

Әйтергә кирәк, РКХ перинаталь үзәгенең яңа бинасы интерьеры бөтенләй хастаханәне хәтерләтми: биек түбәләр, йомшак диваннар, зәвыклы панно... Әлегә биредә тып-тыныч, әмма бик тиздән бина күңелле шау-шуга, ыгы-зыгыга күмелер, шатлыклы авазлар яңгырар. Кыска гына итеп әйткәндә, җанлы тормыш башланыр.

КЫСКА ВАКЫТ ЭЧЕНДӘ

Әңгәмәбезне телефон тавышы өзә.

– Түбән Камадан санитар авиациясе белән бер пациентканы китерәләр, – дип соңгы яңалыкны җиткерә Олег Евграфов. – Йөклелегенә егерме алты атна, яралгы тирәсендәге суы китеп бара. Баланың авырлыгы әле бу срокта бары тик 700 грамм гына.

Биредә мондый балаларны исән-сау саклап калырга өйрәнгәннәр, ләкин, акушер-обсервация бүлеге мөдире Олег Евграфов сүзләренә караганда, табиблар алдында торган иң беренче бурыч – йөклелекне мөмкин кадәр озаккарак сузу. Кайвакыт дүрт атналап вакытны «яулауга» ирешәләр, һәм бу, чыннан да, зур җиңү, чөнки баланың ана карынындагы бер көне, үсеш күзлегеннән караганда, җитлекми туунын бер атнасына тиң.

Казан перинаталь үзәге – үзәк район хастаханәләреннән һәм районара үзәкләрдән кала өченче дәрәҗәдәге дәвалау оешмасы. Бирегә эләккән хатын-кызларның 97 проценты төрле патологияләргә ия һәм йөклелекне күтәрүнең иң катлаулы төркеменә кергәннәр. Монда авыр юл фаҗигаләренә эләккән, бөерләре күчереп утыртылган, тумыштан килгән йөрәк авыруына коррекция ясалган хатын-кызлар бәби таба. Алай гына да түгел әле. Биредә авырлыклары бик кечкенә булган сабыйларга туарга булышып, вакытыннан алда бала табучы әниләргә ярдәм күрсәтәләр. Моның өчен үзәктә барлык шартлар да тудырылган.

– Перинаталь үзәкнең күппрофильле клиник хастаханә составында эшләү факты аны чыннан да уникаль итә, – дип сөйли Олег Юрьевич. – Табиблар РКХнең көчле диагностик һәм дәвалау базасына таянып эшлиләр, барлык төрдәге белгечләрне тиз арада ярдәмгә чакыру мөмкинлеге бар, бу теләсә кайсы кризислы вазгыятьтә дә бик зур өстенлек тудыра.

2015 елда Татарстанда 57 меңгә якын бала дөньяга килгән. Шуларның 5 меңгә якыны диярлек – һәр унберенчесе дияргә була – Казан перинаталь үзәгендә туган.

ӨЗЛЕГҮЛӘРСЕЗ БАЛА ТУДЫРУ

Татарстанда перинаталь үзәкнең икенче корпусын төзү турында сүзләр 2011 елда – РКХ модернизацияләү вакытында ук йөри башлаган иде. Проекты да шул вакытларда ук эшләнде. Ләкин уйланылганнарга ирешү өчен вакыт таләп ителде. «Без күпмедер дәрәҗәдә имин төбәк саналабыз, шуңа күрә мондый объектлар безгә сирәк эләгә», – дип билгеләп үтте үзәкне ачу тантанасы вакытында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов.

100 койкага исәпләнгән яңа корпус федераль акчалар ярдәмендә пәйда була. Яңа бинага берьюлы берничә бүлек урнаша: акушерлык-физиология, йөклелек патологиясе, яңа туган балалар патологиясе. Соңгысы – үзәк тарихында өр-яңа мөһим чорның башы. Аның барлыкка килүе яңа туган балаларны карау, тәрбияләүнең икенче этабы башлануын аңлата, моңа кадәр сабыйларны РБКХнә яисә 1нче балалар хастаханәсенә озатканнар. Шулай итеп, РКХнең перинаталь үзәге тулы канлы тормыш белән яши башлады һәм үз-үзен тәэмин итә ала торганга әверелде, моңа охшаш теләсә кайсы медучреждениенең төп бурычы – аналар үлемен генә түгел, балалар үлемен дә киметү бит.

Иң баштан ук үзәкне куллануга тапшыру декабрь аена билгеләнгән иде, шулай да төзүчеләр һәм клиника администрациясенең тырышлыгы нәтиҗәсендә бурыч күпкә тизрәк үтәлә – инде 14 сентябрьдә медицина үзәге ачыла. Бу көнне бирегә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, РФ Хөкүмәте рәисе урынбасары Ольга Голодец (сүз уңаеннан, күп очракларда уйланылганнарга аның ярдәме белән ирешү мөмкин булды) һәм башка мәртәбәле кунаклар килә. Ә инде беренче пациентларны яңа корпуста шушы көннәрдә көтәләр. Яңа комплекс тулысынча беренчесе, 2001 елдан бирле эшли торган акушерлык корпусы, белән синхронлаштырылган. Шуңа да аның эше буш урында, чип-чиста биттән башланмый, ә бәлки гаять бай тәҗрибәгә таяна.

ФАНТАСТИКА ӨЛКӘСЕННӘН

Кайчандыр дөньяны шаулаткан фотографияне хәтерлисезме:

Реклама

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

әле туып җитмәгән баланың нәни куллары хирургның бармагын кыса? Әлеге бармак иясе Самуэльгә инде 16 яшь. Ул Америка табибы Джозеф Брюнерның осталыгы нәтиҗәсендә сәламәт туа: хирург ана карынындагы ул вакытта әле 21 атналык яралгының арка миенә операция ясый, әйтергә кирәк, бик уңышлы итеп.

Бүген феталь (ана карыны эчендә үтә торган) хирургия, медицинаның иң катлаулы һәм технологик юнәлешләренең берсе булып кала бирә һәм безне гаҗәпләндерүдән туктамый. Хәер, Казан перинаталь үзәге табиблары тарафыннан әлеге хирургия «фантастикасы» уңышлы гына тормышка ашырыла.

– РКХндә ультратавыш контроле астында яралгыга генетик тикшеренүләр уздыру максаты белән дә, аның кайбер патологияләрен оператив дәвалау өчен дә ана карынында операцияләр үткәрү методикасы эшләнгән, – дип сөйли РКХндә клиник диагностика буенча баш белгеч Мөнир Төхбәтуллин. – Мондый операцияләрдән соң сабыйлар сәламәт булып туалар.

Бүген РКХндә иң алдынгы медицина техникасы тупланган, әмма, аңлашыла ки, җиһазлар үзләре генә берни дә эшләми.

– Мондый операцияләр безнең перинаталь үзәктә генә үткәрелә, гәрчә республикада җиһазланышы буенча бездән калышмый торган клиникалар булса да, – дип сөйли Мөнир Габделфәтович. – Бу барысын да кадрлар хәл итә дигән очракка туры килә. Мондый операцияләрне үткәрү өчен, берничә оста белгеч таләп ителә: ультратавыш диагностикасы һәм УЗИ контроле астында инвазив операцияләр ясый белүче. Аларны әзерләү өчен, ким дигәндә, 5–6 ел китә, һәм бу яктан РКХ алдынгылыкны били. Бүген Казан перинаталь үзәгендә кирәк булганда яралгының канын алыштыра яисә аңа кан өсти, киста һәм башка төр шешләрне ана карынында вакытта кисә алалар, шешенү синдромы вакытында операция ясау мөмкинлеге дә бар… Шуның өстенә феталь операцияләр спектры киңәюгә бара.

Клиника составында медицина-генетика лабораториясе эшли, анда тикшеренүләрнең төгәллеге молекуляр дәрәҗәдә башкарыла. Яралгының ана карыны эчендәге үсешенең тумыштан килгән тайпылышлары хатын-кыз йөклелегенең иртә срокларында ачыклана. Сүз уңаеннан, монда консультатив-диагностика үзәге дә эшли, көн саен район хастаханәләрендәге коллегалары белән видеоэлемтә сеанслары оештырыла. Таләп ителгәндә анда катнашу өчен РКХнең башка бүлекләрендә эшләүче белгечләр дә чакырыла. Шулай итеп, табиблар дәвалауны төгәлләштерү яисә пациентканы перинаталь үзәккә китерү сорауларын оператив хәл итәләр. Система җайга салынган, һәм ул сәгать кебек төгәл эшли.

ӨЙГӘ ОЗЫН-ОЗАК ЮЛ

Яңа туган сабыйлар бүлеге мөдире Альбина Идиятуллина безне яңа бина буйлап экскурсиягә чакырды.

Ун бала табу залында иң алдынгы техника урнаштырылган. Монда барысы да дөньяга җитлекми туган балаларны саклап калуга юнәлдерелгән, һәм шуңа күрә дә иң югары дәрәҗәдәге реанимация ярдәмен күрсәтү өчен табибларның барлык җиһаз-җайланмалары бар биредә.

Сүз уңаеннан, Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы критерийларына ярашлы, егерме ике атналык йөклелектән туганнар тере туган балалар санала. Ләкин, аңлашыла ки, мондый срокларда бик нәни балалар туа – авырлыклары биш йөз граммнан бераз гына артып китәргә мөмкин. Шуннан соң инде могҗиза башлана.

Яңа туган балалар реанимациясе бүлегендә җитлекми туганнарның сулыш алуына ярдәм итү аппаратуралары куелган, аларны карау өчен барлык мөмкинлекләр тудырылган инкубаторлар да бар. Алар арасында бассейнга охшаган бер нәрсә дә күренә, суы гына юк. Реабилитация караваты икән.

– Тотып карагыз! – дип, якынгарак чакыра безне Альбина Ревовна. – Сизәсезме? Тышлыгы астында махсус катнашма. Кислородка кушабыз, һәм бала «йөзә», бушлыктагы кебек! Нәтиҗәдә кан әйләнеше, мускул тонусы яхшыра…

Бала тапкан аналар бүлеге ике катны били, әлеге барлык уңайлылыклары булган бүлек 70 урынга исәпләнеп эшләнгән. Әгәр баланың хәле тотрыклы икән, ул гомеренең беренче минутларыннан ук әнисе һәм… әтисе белән бергә бер палатада яши башлый. Әйе, биредә әтиләр турында да уйлаганнар – теләге булганда, әти кеше баласы дөньяга килгән вакытта хатыны белән бергә була ала. Сүз уңаеннан, «ана һәм бала» бүлмәләре комфорт буенча кунакханә номерларыннан бер дә ким түгел – якты, иркен, барлык уңайлылыклар бар үзендә. Ләкин үзенчәлекләре дә күзгә ташлана – һәр бүлмәдә терелекне тәэмин итү панеле, бала өчен кирәкле барлык нәрсәләр дә урнаштырылган.

– Бала табасы килгән хатынны тыеп булмый, – дип елмая саубуллашканда Альбина Ревовна. – Әлбәттә, проблемалар да булып тора. Күпме күз яше, хис-кичерешләрне күрергә туры килә! Әмма вакыт туктап тормый, туганда авырлыгы бер кило да булмаган сабыйның үз яшьтәшләре белән бергә беренче сыйныфка йөгергәнен ишетеп, зур дулкынлану кичерәсең…

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН»
МАХСУС
журналы өчен
Журнал
ТАТАРСТАН
Обращение

ДӘҮЛӘТ СЕРЕНӘ ТИҢ РЕЦЕПТ

Казан... Новосибирск... Калуга... Арча... «Шәһәрләр» уенын белмәгән кеше юктыр. Шул рәвешле башка берәр милләт вәкиле белән «Ашлар» уенын да уйнап карарга була. Бәлеш... Штрудель... Лагман... Нут... Талкыш кәләвә. Соңгысы тәмле дә, баллы да, шул ук вакытта бәясе дә бар. Җитмәсә әзерләү дә шактый мәшәкатьле... Шуңа да талкыш кәләвәне әзерләүчеләр – бармак белән генә санарлык!

Автор:
Айсылу Хаҗиева

КҮЛӘГӘДӘГЕ СЫЙ-НИГЪМӘТ

Татар халык ашларының популярлык рейтингын төзесәк, билгеле, беренче урынга бәлеш, өчпочмак һәм чәкчәк чыгар иде. Ә менә талкыш кәләвә нигәдер нахакка үпкәләтелгән булып, гел күләгәдә кала бирә. Шунысы да бар: әлеге татлы ризыкны татар халык ашлары рәтенә кертеп без дөрес эшлибезме соң?

Әйе, Юныс Әхмәтҗанов аны «Татар халык ашлары» китабында искә алган һәм, шул басмага нигезләнеп, «талкыш кәләвә безнеке» дип күкрәк кагарга була да бит. Ләкин... балдан, майдан ясалган кәләвә тумышы белән Төркиядән икән. Безнең җирләргә кунак булып нибары XVIII гасырда гына килгән. Рус-төрек сугышы вакытында исән калып, туган җирләренә кайткан бабаларыбызга «ияргән» талкыш кәләвә. Әмма төрекләр пешерә торган кәләвә татарлар пешерә торганыннан аерыла. Мөмкинлекләр, кирәкле ингредиентлар, зәвык төрле булганга, рецептларга да үзгәреш кергән. Һәм бүгенге көндә әлеге талкыш кәләвәләр бер гаиләгә карасада да, охшашлыклары әллә ни зур, димәс идем.

Интернет киңлекләрен гизеп чыккач, талкыш кәләвә бары тик Казанда, Татарстанда гына пешерелә дигән фикергә килергә мөмкин. Чөнки чит төбәкләр, хәтта ки Башкортостан яклары да, чәй янына әлеге затлы десертны алыр өчен мәркәзебезгә юл тота икән. Бу факт, һичшиксез, татар ашлары белән янә бер кат горурланыр өчен сәбәп!

Талкыш кәләвәне Юныс Әхмәтҗановның атаклы китабындагы рецепт буенча пешереп караучылар да, үзлегеннән өйрәнүчеләр дә бар. Без шулай ук Интернет заманы җиткәнен дә истән чыгармыйк. Виртуаль дөньяда «иң төгәл, дөрес» рецептлар байтак. YoeTube каналларында видео-дәресләр дә җитәрлек. Ләкин без Интернет галиҗанәпләре белән генә чикләнмәдек, ә талкыш кәләвә пешерү хыялы белән яшәгән һәм бу хыялны тормышка ашыра алган ханым белән очраштык.

ӘЛЛӘ ӘКИЯТ, ӘЛЛӘ ЧЫН...

Разия Хөсәенова тумышы белән Балтач районының Арбор авылыннан. Ачык күңелле, кәләч йөзле бу ханымны башкалардан аның хыялы аерып торадыр. Аш бүлмәсенә керүгә, шул хакта сөйли дә башлады:

– Талкыш кәләвәне 2004 елда гына пешерергә өйрәндем. Мине өйрәтүче апага шактый вакыт ялынырга туры килде.

Шушы мизгелдә, аны бүлеп: «Ничек инде ялынырга? Китаплар күп бит. Шуннан гына өйрәнеп булмыймыни?» – дип, гаҗәпләнүемне белдердем. Разия ханым елмайды гына: «Ул рецептлар буенча хәйран пешердем инде. Сарыф ителгән май, он, балны саный китсәң, бер дәфтәр дә җитмәс!» Баксаң, талкыш кәләвәнең рецепты җиде кат йозак астында саклана икән. Алай гына да түгел, СССР чорына әйләнеп кайтсак, талкыш кәләвә пешерү рецепты дәүләт серенә тиң булган!

Әлеге татлы ризыкны нибары ир-атлар гына пешергән, әзер продукцияне сатучы кибетләр исә гомумән бармак белән генә санарлык булган. Бу катлаулы һәм затлы ризыкны әзерли белүчеләргә ул заманда шактый зур акчалар да түләнгән, ди. Әллә әкият, әллә чын...

Мине тагын шунысы гаҗәпләндерде: пешекчебезнең телефоны туктаусыз шалтырый, фотограф плитә янында сурәткә төшереп тора, мин өзлексез сораулар яудырам, Разия апа бал, су, шикәр эретә һәм шундый тыгыз вакытта да тып-тыныч булып кала бирә.

– Талкыш кәләвә сабырлык һәм тыныч эш йөрткәнне ярата, – ди ул. – Кабалана, дулкынлана башлыйсың икән, бернәрсә дә барып чыкмый.

ХЫЯЛ ЙӨРТӘ...

Мин, ниһаять, остадан бу рецептны ничек кулга төшерүе турында сораша башлыйм.

– Мәскәү базары тирәсендәге кибеттә эшли идем, бер көнне безгә талкыш кәләвә салынган пакет тотып Фаимә апа килеп керде. Үзе пешергәнен белгәч: «Мине дә өйрәтегез», – дип үтендем. «Юк!» – дип кырт кисте ул. Кәләвә пешерү хыялымда инде озак йөргән иде, үз дигәнемә ирешә торган кеше булганга, мин тиз генә бирешмәдем. Озак ялынырга туры килде. Өйрәтергә теләмәвенең сәбәбе дә бар. «Кул китә аннары», – ди иде Фаимә апа.

– Оста пешекчеләрнең үзләренә күрә ырымнары да бар икән, моңарчы белми идем, – дип дәвам итә Разия ханым. – Ләкин мин, ырым дип кенә, күңелемне төшермәдем. Йөри торгач, ризалашты бу. Беренче «дәрестә» бер почмакта посып кына утырдым, плитә янына да, өстәл янына да килү катгый тыелган иде. Сорау бирү, эшен бүлдереп, сөйләшеп алулар турында әйткән дә юк.

Фотолар: Ната Смирнова

PRESSA.RU

РАЗИЯ ХӨСӘЕНОВА РЕЦЕПТЫ БУЕНЧА:

1. Он – 300 г
2. Май – 150 г
3. Бал – 150 г
4. Су – 0,5 стакан
5. Шикәр комы – 500 г

ЮНЫС ӘХМӘТҖАНОВ РЕЦЕПТЫ БУЕНЧА:

Әлбә пешерү өчен:
1. Атланмай – 250 г
2. Он – 300 г

Татлы масса ясар өчен:
1. Шакмаклы шикәр –450 г
2. Су – 250 г
3. Бал – 150 г

Шулай үрелеп-сузылып Фаимә апаның кул хәрәкәтләрен, эш барышын күзәткәннән соң, өйгә кайтып киттем. Шул көнне үк пешереп карарга булдым, ләкин барып чыкмады. Фаимә апа: «Хатаң – әлбәдә», – дип, җитешсез якларымны күрсәтте. Ләкин хатаның әлбәдә булмавын мин соңрак аңладым. Икенче дәрестә әзер баллы «җепләрне» савытларга тутырырга рөхсәт бирелде, ә инде өченче дәрестә якын ук килеп күзәтеп торырга һәм рецептын язып алырга да ярый иде.

САБЫРЛЫК НӘСЕЛДӘН КИЛӘ

Разия апаны беренче күргәч үк, бу ханым башлангыч сыйныф балаларын укытадыр, дип уйлап куйдым, чөнки сабырлыгы йөзенә чыккан иде. Җайлап кына, матур, тыныч итеп сөйләшә, адымнарында да, хәрәкәтләрендә дә тыйнаклык сизелә. Ләкин ялгышканмын. Разия апабыз күп еллар авыл почта бүлекчәсендә эшләгән, соңрак, икътисадчы белемен үзләштереп, Казанга юл тоткан. Монда сатучы булып эшкә урнашкан. Кечкенәдән сатучы булырга теләгән. Бала чакта «кибетле» уйнаганда да ул «касса» артында булган.

– Без кечкенә вакытта әле калькуляторлар юк иде. Счетта саный торган идек. Санарга үзлегемнән өйрәндем. Ә инде тапкырлау, бүлүләрне әтием аңлатты. Хәтта Казанга күчеп, эшкә кергәч тә, яңа җайланмаларга тиз генә өйрәнеп китә алмадым, үзем белән эшкә агач счет йөртә идем. Иң элек калькуляторда саныйм да, аннары дөреслеген счетта тикшерәм, – дип көлә Разия ханым.

«Эшегездә дә тынычмы сез? Шундый ыгы-зыгылы җирдә ничек тыныч кала аласыз?» – дип чираттагы соравымны бирәм. Разия апа исә бал, шикәр, су салынган кайнатмасын болгата-болгата, тыныч кына җаваплый: «Ә минем ачуым бөтенләй дә чыкмый. Мине чыгырдан чыгарыр өчен бик тырышырга кирәк!»

Моның чынлап та шулай булуына мин дә ышана башладым. Менә бит төпченәм дә төпченәм, ә ул елмаеп кына тора.

– Талкыш кәләвә пешерергә өйрәнгәнсез, ә хәзер нинди хыялыгыз бар? – дип аптыратам.

– Бәлки, пәхләвә пешерергә өйрәнермен, – ди Разия апа.

– Анысын безнең журналдан өйрәнә аласыз! – дим. – Миңа калса, сез чәй ризыкларын үз итәсез? – дип, теңкәсенә тиюемне дәвам итәм.

– Күрәсең, монысы да, сабырлыгым да нәселдән килә торгандыр, – диде Разия апа, уйчанлана төшеп. – Әбием туйларга ризык хәстәрли торган булган. Бәлешләр, чәкчәкләр, тортлар пешергән. Хәзер инде әнием шулар белән мәшгуль. Үзем дә элегрәк чәкчәкләр пешереп сата идем…

БАЛТАЧТАГЫ НАПОЛЕОН ЭШЛӘПӘСЕ

«Әби» сүзен ишетүгә, балачак хатирәләрен барларга керештем.

– Гадәттә, әби белән үскән кыз балаларны ризык пешерү серләренә нәкъ менә алар төшендерә, сезнең очракта да шулай булдымы?»

– Әйе, әби элек-электән бик таләпчән булды. 10 яшемдә камыр басып токмач кисәргә өйрәндем. Әти-әниләрнең эштән кайтышына ашлар әзерләп куя идем. Әби кәстрүлгә нәрсә артыннан нәрсә саласын язып китә, мин шул исемлек буенча эш йөртәм. Эшләгәнең минем өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен булыр, дип кабатларга ярата иде. Әле бүген дә рәхәтләнеп туйлар өчен әзерләвен дәвам итәр иде дә, җитәр инде, дип, без тыеп торабыз, – шулай дип күңелен ачып салды Разия ханым.

«КАРДИНАЛ» ФАИМӘ АПА РЕЦЕПТЫ

Әйткәнемчә, талкыш кәләвә рецептлары шактый күп, ләкин әлеге ризыкны китап буенча гына пешерергә өйрәнеп була дисәң, ялгышасың! Разия апа да күп китаплар актарган, әмма 1956 елгы китаптагы рецепт кына дөреслеккә якын булган. Безнең очракта китаплар да, хәтта ки осталарның остасы Юныс Әхмәтҗанов та ярдәмгә килә алмады. Безнең «соры кардиналыбыз» – Фаимә апа.

I этап. Иң элек әлбә әзерләргә кирәк. Сыер маена он кушып, табада 1 сәгать чамасы эретәбез. Ул саргылт төстә булырга тиеш. Беренче серебез шушы әлбәдә яшеренгән. Төгәлрәге, майда. Майда бер генә грамм да су булмаска тиеш. Кибеттә эретеп катырылган май аласызмы, әллә инде үзегез эретеп, суын җыясызмы, анысы мөһим түгел. Өй шартларында түбәндәгечә эш итәбез: сыер маен эретәбез, салкын җиргә куеп катырабыз. Суы аста калып, мае өскә чыгачак. Шунысын гына җыеп алырга кирәк. Җыелган майны табада кабат эретеп, он өстибез. Катнашманы сүрән утта 1 сәгать эретәбез. Майның да, онның да сыйфаты бик мөһим. Он югары сортлы булырга тиеш.

II этап. Икенче бер кәстрүлдә шикәр, су кушып, 40 минутлап бал эретергә кирәк. Балны сатып алган чакта ук игътибарлы булыгыз. Ереткән вакытта да ул дөрес куелыкта булырга тиеш. Утны шулай ук кысып куябыз. Баллы катнашмабызның әзерлеген аның шырпыга юка җеп булып тартылып чыгуы күрсәтәчәк. Бал җепселләнми икән, димәк, катнашма әзер түгел. Бал җепләрен бармакка салып та тикшереп карарга кирәк. Алар төерләнеп җыелырга тиеш. Соңрак, баллы кайнатмабыз әзер булгач, аны җылымса табага салабыз, ә табаны салкын су салынган тазга утыртабыз. Бал шунда ук ката башлаячак. Аны төрле яклардан җеп белән күтәреп, бертигез дәрәҗәдә суытырга кирәк. Балга су тамчылары эләгә икән, талкыш кәләвәбез уңмаячак. Бик четерекле момент бу.

III этап. Балыбыз кулга алырлык булып суынгач, куна янына күчәбез. Кунаның бер башына әзер әлбәне тигезләп салабыз, ул да җылы булырга тиеш. Шуннан соң балны ике якка тарта башлыйбыз. Җитәрлек сузылганнан соң, боҗра ясап, шул боҗра буенча тартып сузабыз. Бал агара башлагач, әлбәне кушарга керешәбез. Баллы бауны әлбәгә тидереп алабыз һәм тартуны дәвам итәбез. Әлбә тулысынча балга сеңеп бетәргә тиеш, шул очракта гына баллы бау җепселләргә тарала башлаячак. Җепселләнмәгән өлешләренә күбрәк көч куеп сузабыз. Бал өзелеп китәргә тиеш түгел, юкса аннан җепләр ясап булмаячак.

IV этап. Бал ап-ак җепләргә таралганнан соң гына, формаларга салып, әзер кәләвә рәвешенә кертәбез. Әзер ризыкны суыткычта сакларга кирәк.

1. Эретәбез!

2. Сузабыз!

3. Болгатабыз!

4. Катнаштырабыз!

5. Таратабыз!

6. Ваклыйбыз!

7. Форма бирәбез!

8. Тезәбез!

PRESSA.RU

ХРАМГА ЮЛ

Кеше өчен үзенең рухи тамырлары белән яшәү, Аллаһ белән бәйле булу бик мөһим. Әлеге бәйләнеш булмаган очракта ул, үз тормышын җимереп, бозылган, ялган инануларга кереп чума. Шуңа күрә үз тормышын әле төзи генә башлаган яшь кешеләргә гыйбадәтханәгә юл һәрвакыт ачык булырга тиеш. Чистай епархиясендә храмнарга шундый юлны булдырырга җирле яшьләр православие общинасына килеп йөрүчеләр ярдәм итә.

– Чистай епархиясендә яшьләр бүлеге 2012 елда Казан һәм Татарстан метрополиты Анастасий хәер-фатихасы буенча төзелде, – дип сөйли протоиерий Павел Чурашов. – Барлык благочиниеләрдә дә яшьләренең храмга килергә һәм үзләрен борчый торган сорауларга җавап табарга, үз яшьтәшләре, башка ир һәм кыз туганнары белән бергә аралашып, православие динендә ныгырга, файдалы гамәлләр кылып, үзләренең изге теләкләрен күрсәтергә мөмкинлекләре булсын өчен бүлекләр төзелде.

Чистай епархиясенең яшьләр общинасында епархиянең булган 10 благочиниесенең һәркайсында да 15 яшьтән алып 35 яшькәчә якынча 20–25 актив катнашучы кыз һәм егет санала. Алар барлык әһәмиятле бәйрәмнәрне – диниләрне дә, дөньявиларны да – әзерләү һәм үткәрүдә катнаша. Моңардан тыш, община мәдәният-спорт чараларында, мәсәлән, шигырь укучыларның епархия бәйгесендә яисә епархия благочиниеләренең 12 командасы арасында волейбол буенча мөстәкыйль оештырылган турнирында катнаша. Озакламый Көзге бал – кунакларга XIX гасыр даирәсенә чумарга ярдәм итәчәк костюмлаштырылган зур тамаша булачак. Һәм, әлбәттә, община даими рәвештә яшьләр өчен Аллаһ кануннарын өйрәнү, Инҗил укуга багышланган очрашулар уздыра.

– Яшьләр оешмасында кызыклы һәм талантлы яшьләр күп. Аларны православие белән кызыксыну, дингә таянып, үзләренең эчке хисләрен белдерергә омтылыш, тәүбә һәм гөнаһлардан арынуның серлелеген сизү берләштерә, – дип сөйли Павел атакай. – Алар арасында авыр тормыш хәлендә калучылар, ярдәм һәм киңәшкә мохтаҗлар да бар. Кеше һәрвакыт эчке сиземләве белән яхшылыкны яманлыктан аера, әмма һәрвакытта да дөрес гамәлләр кылырга үзендә көч тапмый.

Сүз уңаеннан, община вәкилләре, мөселман яшьләренең Чистай бүлеге белән берлектә, экстремизм, терроризм, секталар эшчәнлегенә каршы юнәлдерелгән күп кенә чараларда катнаша.

– Узган ел православие һәм мөселман яшьләренең берләштерелгән тырышлыгы белән чистайлылар сектага эләккән яшь кеше язмышы турында кыска метражлы фильм төшерде. Бик тормышчан килеп чыкты. Ел саен сентябрь аенда экстремизм һәм терроризмны кисәтү айлыгы кысаларында берләштерелгән лекцияләр уздырабыз, – дип сөйли Павел атакай. – Урта һәм югары уку йортларына барабыз һәм яшьләр белән секталардан нинди куркыныч янавын, аларның яшьләрне нинди максат белән үзләренә җәлеп итүе һәм башка күп нәрсәләр турында аңгәмәләр алып барабыз.

Һәм, билгеле инде, яшьләр общинасы Чистай епархиясенең иң мөһим проектында – Кече Талкыш авылында хатын-кызлар монастырен төзү эшендә актив катнаша. Татарстан митрополиясе оешканнан һәм өч епархия төзелгәннән соң барлык монастырьләр дә Казан епархиясе территориясендә булып чыкты. Шуңа Чистай благочиниесендә монастырь төзү турында карар чыгарылды да инде. Изге Троица приходы хатын-кызлар монастыре төзелеше быел Чистай һәм Түбән Кама епискобы Пармен хәер-фатихасы белән башланып китте.

Хәзер Кече Талкыш авылында Изге Троица храмыннан ерак түгел урнашкан мәктәп бинасын реконструкцияләү алып барыла. Бу монастырьнең беренче корпусы булачак. Инде хәзер үк послушница булырга һәм киләчәктә гомерләрен дингә хезмәт итүгә багышларга теләк белдергән приход хатыннары бар. Киләчәктә, мөгаен, епархиядә ирләр монастыре дә барлыкка килер.

ТР ЧИСТАЙ ЕПАРХИЯСЕ КЕЧЕ ТАЛКЫШ АВЫЛЫНДА (ИЗГЕ ТРОИЦА ПРИХОДЫ) МОНАСТЫРЬ ТӨЗЕЛЕШЕНӘ ИГАНӘ ҖЫЮ

Түләүне кабул итеп алучы: Рус православие чиркәвенең Чистай епархиясе (Мәскәү патриархаты) каршындагы ТР Чистай районы Кече Талкыш авылында урнашкан Изге Троица приходы җирле православие дини оешмасы
ИНН 7707083893, КПП 165202001,
ОГРН 1027700132195, И/С 40703810062000000882,
Кабул итеп алучының К/С: 30101810600000000603 БАНК:
Россия Саклык банкының Казан шәһәрендәге 8610 номерлы бүлекчәсе.
БИК 049205603

Картага сумнарда акча күчерүләр өчен счет реквизитлары:
Акча кабул итеп алучы: Бакалдин Виктор Александрович. Акча алучының счеты: 40817810662001347733, Акча кабул итеп алучының банкы: «Саклык банкы» ААҖнең 8610 номерлы ТАТАРСТАН Банкы» бүлеге, Казан ш., акча кабул итеп алучының ИНН (СТШН): 7707083893, кабул итеп алучы банкының БИК номеры: 049205603, акча кабул итеп алучының К/С: 30101810600000000603, карта счетын кертү урыны буенча банк бүлекчәсе коды (Саклык банкы системасы буенча эчке акча күчерүләр өчен): 4286100840, карта счетын кертү урыны буенча банк бүлекчәсе адресы: Чистай ш., К.Маркс ур., 30.

Тел.: 8 (927) 672-74-79, 8 (927) 405-43-58 Факс: 8 (84342) 3-37-85

Реклама

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

«Хәтәр» картлар **КАЙДА** яши

Ата-ананы **НИГӘ** кичерергә кирәк

Зирәклек **КАЙДАН** килә

Ирек Вилданов самолетын **НИЧЕК** төзегән

Казансу **КАЙДАН** башлана

Татар фольклоры Кырымга **НИГӘ** кирәк

«Шайтан каласы» элек **НӘРСӘ** булган

PRESSA.RU

КӨЗНЕҢ ҖӘЙГЕ ИЛАҺЛАРЫ

Фотограф Солтан Исхаков күптән түгел «Россиянең милли бәйрәмнәре» Бөтенроссия фотобәйгесендә җиңеп чыкты («Иң яхшы сурәт» номинациясендә 1нче урынга лаек булды). Аның гап-гади фотоаппарат тоткан бабае жюрины беренче караштан ук әсир итте. Ә безне – икенче караштан, чөнки «Татарстан» журналы бу фоторәсемне һәм гомумән җиңүченең бөтен фотоархивын жюридан соң икенче булып эләктерде.

Кадрларны сайлаган вакытта шундый кызыклы нәрсәне ачыкладык: «көзге чор»га кереп барган кешеләр артистлыклары белән аерылып тора икән. Алар җырларга һәм биергә ярата. Алар теләсә кайсы бәйрәмнең үзәгендә кайный. Алар – көзнең Илаһлары, тик бу көз аларның паспортларындагы аерым графаларда гына чагыла. Солтан исә бу көзге кешеләрнең күзләрендә чын җәй яктысын эләктереп кала алган – бөтен төсмерләре, яшьлеге һәм дәрте белән бергә. Әйтегез әле, шушы сөйкемле һәм күтәренке рухлы әби-бабайларыбыздан башка без нишләр идек?!

PRESSA.RU

Менә ул «Россиянең милли бәйрәмнәре» фотобәйгесендә җиңгән фото.

PRESSA.RU

КАРТЛЫК СИНЕ КАЙДА КӨТӘ?

– Әйе, алар үзенчәлекле кешеләр. Монда эшли башлавымның беренче мәлләрендә аларны карашларыннан, киемнәреннән, сөйләшү рәвешләреннән таный идем... – Рузилә Бәширова Аксубай районы Федоровское авылындагы Картлар һәм инвалидлар интернат-йорты җитәкчесе. Мондагы халыкның 30%ы төрмәдә утырып чыккан.

ТӨРМӘДӘН – ПЕНСИЯГӘ

Бу интернат-йортка 19 ел. 2003 елда ул, махус статуска ия булып, Россиянең төрле төбәкләреннән гадәти булмаган картларны кабул итә башлый. Хәзерге вакытта аларның саны 30га якын. Калганнарын – иң хәтәрләрен – Мамадыштагы махсус интернатка күчерәләр, Федоровскоеда төрмә белән таныш булмаган, әмма һәркайсы авыр язмышка дучар булган инвалидлар һәм пенсионерлар урнаша башлый. Иң яшенә – 31, иң олысына 91 яшь.

– Рузилә Равилевна, төрмәдә утырган картлар нindирәк?

– Еш кына аларның картлыклары язмышка рәнҗеш нәтиҗәсендә кискенләшә. Әмма мин һәрчак язмышыбызны үзебез төзибез, дип әйтәм. Аларның һәрберсенең үз төрмә срогы булган – кемгәдер гамәлләрен аңлап туктар өчен 1 ел да җиткән, ә кемдер 10, 20 ел утыруына да карамастан, әле һаман да «бирешми». Әмма бу картларны бер нәрсә берләштерә – алар үзләренең психологик ресурсларын сарыф итеп бетергәннәр дияргә була. Күбесенең язмышында төрмә кылган гамәле өчен җавап тоту урыны гына түгел, ә гаиләләре һәм балаларына алардан баш тарту өчен сәбәп тә булып тора. Туганнарын бик тә сагыналар, без исә әкрен генә туганлык мөнәсәбәтләрен җайларга тырышабыз: картларны кунакларга йөртәбез, туган-тумачаларын үзебезгә чәйгә чакырабыз.

Рузилә Бәшированың интернат белән җитәкчелек итә башлавына бер ел да юк әле, әмма инде бүген үк гадәти булмаган картлар белән мөнәсәбәтләренең көйләнә баруын билгеләп үтә. Эшенең беренче көннәрендә аңа үз-үзенә бикләнгән, йомыкыйрак кешеләр белән очрашырга туры килгән, монда яшәүчеләрнең болай да җиңел булмаган холкына картлык деменциясе дә өстәлә бит. Аларның кайберләре хәтта җәй көне дә, бина эчендә була торып та, өске киемнәрен салмый. Монда эшләүче персоналга психологик тренинглар, мәдәни чаралар, дәвалау физкультурасы, норвегия йөреше һ.б. лар ярдәмгә килә.

–Беренче айларда бик авыр кешеләр дип уйласам да, бүген мин аларда «элеккегеләр»не күрмим, – дип сөйли Рузилә Бәширова. – Уртак тел табарга, әрнү-сызлануларын тоярга тырышам, һәм әкренләп алар да «эри», миңа йөз белән борыла. Киртәләр юкка чыккач, ышаныч барлыкка килә, ә бу иң мөһиме.

Автор:
Катерина Котова

ДЕМЕНЦИЯ АВЫРЛЫКЛАРЫ

ТУГАННАР ӨЧЕН ЛАЙФХАКЛАР *

Картлыгыбызда нинди булачагыбызны белмибез. Бүген үк яшәешегезнең сыйфаты турында уйланыгыз.

Бу кешегә үпкә сакласагыз да, яшен хөрмәт итегез. Аның урынында үзегезне күз алдына китереп, мәрхәмәтле булырга тырышыгыз.

Еш кына картларның үз-үзләрен бәяләү дәрәҗәләре түбән була, ә мондыйларның – бигрәк тә. Туганыгызга энергиягез һәм оптимизмыгыз белән көч-дәрт өстәгез, аны тормышыгыздагы әһәмиятле кеше булуына инандырыгыз. Иртәме-соңмы моның нәтиҗәсе булачак.

Өлкән яшьтәге кешенең кәефе синусоида кебек: иртән – күтәренке күңел белән йөрергә, ә көндез төшенкелеккә бирелгән булырга мөмкин. Моңа алдан ук әзер булып, тынычлыгыгызны югалтмагыз.

Әйе, сезнең вакытыгыз аз, әмма бер генә минутка булса да якын кешегезгә игътибар итегез, әйткән сүзләрен тыңлагыз, көне буена аның кәефен күтәрергә сәләтле ягымлы сүз әйтегез.

* Лайфхаклар – тормыш киңәшләре

PRESSA.RU

– Коридорда эленеп торган сәгатьне күрдегезме? – дип кызыксына Саша абый. – Йөрми иде. Шулай бервакыт: «Ник йөрми?» – дип сорадым. «Төзәтүче юк, ал да, төзәт», – диделәр. Төзәттем бит.

ХЫЯЛНЫ ЧЫНГА АШЫРЫРГА ОМТЫЛЫГЫЗ

Саша абый – җирле староста – елый. Үзем дә яшьләремне чак кына тыеп торам. Каршымда, хәзерге заман күзлегеннән карaганда, көч-куәте ташып торган яшьтәге ир-ат. 60 яшь бүгенге көндә күпме инде ул? Әлеге картлар йортында Саша абый инде 9 ел яши, моңарчы, 3 ел буена, башкасында торган. Тик анысында янәшәсендәгеләр белән тынышып яши алмаган, ә биредә аңа рәхәт. Әлбәттә, мондый учреждениеләрдә кешегә туганнары, балалары, йорт-җиреннән мәхрүм калган хәлдә татып була торган рәхәтне күздә тотам.

– Коридорда эленеп торган сәгатьне күрдегезме? – дип кызыксына Саша абый. – Йөрми иде. Шулай бервакыт: «Ник йөрми?» – дип сорадым. «Төзәтүче юк, ал да, төзәт», – диделәр. Төзәттем бит. Минем монда кадеремне беләләр. Кайчак кызлар да: «Саша абый, ясап бирәсеңме?» – дип ватык-җимерек әйберләрен китерәләр. Әлбәттә! Мин бит механик, шөгылем үземә бик ошый. Эш җитми миңа. Беркөн якындагы кырга тракторы белән иптәшем килгән иде. «Бар, ял итеп ал, үзем эшләп алам», – дим. Эх, куллар эш сорый бит! Моннан 16 км ераклыктагы предприятиегә дә чакырганнар иде мине, әмма бездән транспорт йөрми. Җәй көнне барып йөрергә була да, кышын нишлисең? Фатирга түләп торыргамы? Куркам мин. Берәр нәрсә була калса, кемгә кирәк булачакмын?

Саша абый балалар йортында үскән, дәү әнисе булган, әмма аңа, кызганыч, озак яшәргә насыйп булмаган. Үзе дә ныклы гаилә кору бәхетенә ирешә алмаган.

– Армиядән соң, өйләнеп, хатынымның авылына күченеп кайттым, – дип сөйли ул. – Әйбәт яшәдек – балалар үстердек. Ә минә эшемдә бармакларым киселгәч, гаилә тормышыбызга нокта куелды. «Миңа гарип нәрсәгә кирәк», – диде ул чакта хатыным. Шуннан соң өйдән чыгып киттем. Вокзалларда кундым, аннары интернатка эләктем.

Күп еллар узгач, Саша абый, үткән көннәргә анализ ясый-ясый, шундый нәтиҗәгә килә: аның Пандора тартмасы күпкә иртәрәк ачылган икән.

Заманында ул Бөтенроссия комсомол төзелеше – КАМАЗны салуда катнашкан. Армиядә хезмәт иткән, ике техникум тәмамлаган. Менә бит – тормыш үзе кебек тоелган аңа! Әмма барысы да күз ачып йомганчы үзгәргән.

– Шофер идем мин. Яшем егермедән бераз гына арткан, акча эшлисе килә, шуңа күрә машинада узыштым. Ул һәлакәттә кешеләр зыян күрде. Мин ай ярым СИЗОда утырдым. Ә анда – караклар, сугышу. Иптәшләрем үз җаваплылыкларына алып чыгардылар. Әмма бер тайпылсаң, тормыш башка юлдан китә икән шул.

– Әгәр дә мондый мөмкинлек булса, язмышыгызны үзгәртер идегезме? – дип сорадым мин Саша абыйдан.

– Эх, күп нәрсәне үзгәртер идем! ди ул, җанланып китеп. – Беләсезме, иң мөһиме – үзеңнең хыялларыңнан курыкмау. Мин бит армиядә калырга теләгән идем. Югары хәрби уку йортына комиссияне дә узган идем... Бардым – Кытай чигендә хезмәт иттем, ә бу, белсәгез, – шундый киеренкелек. Дәү әнием янына кайтып, ай ярым торганнан соң, армиягә китәсе килә башлады! Кайчандыр әтием һәм бабам киткән кебек. Әмма булдыра алмадым... Хәзер – менә монда. Ә еллар уза бит, яшисе дә килә. Гаилә тормышында бик тә яшисем килә.

БӘХЕТ ЯНӘШӘДӘ ГЕНӘ БУЛЫРГА МӨМКИН

– Исәнмесез! Без спорт белән шөгыльләнүче гаилә, – дип хор белән диярлек исәнләшәләр алар.

Юра абый һәм Гөлсинә апа – гел бергә. Юра абый кебекләрне гадәттә «живчик» дип атыйлар. Ул уртача буйлы, үзе бик тере. Гөлсинә апа исә аның капма-каршысы – тыныч һәм йомшак.

– Без, кызым, һәрвакыт бергә, – ди Юра абый. – Тезләр авыртса да, тренажерны әйләндерәбез. Кышын таяклар белән йөрибез, норвегия йөреше дип атала ул. Без монда таныштык. 10 ел элек! Әйбәт яшибез, аерым булмә бирделәр. Җиһазларыбыз да әйбәт, кер юу машинасы алдык, ә тегү машинасын монда бүләк иттеләр – хатыным тегүче минем.



Гөлсинә апа – балалар йортында тәрбияләнгән. Туганнарыннан кызы гына бар. Картлар йортына үз теләге белән килгән дияргә була, кияве белән уртак тел тапмаган. Аның каравы, монда, интернатта, үзенең соңарган бәхетен очраткан.

– Беләсезме, мин бит элек, Юрага кадәр, гел үзем генә идем – янәшәмдә иңемне терәрлек ир-ат юк иде, – ди ул. – Тормыш шундый инде: кайда югалтып, кайдан табасыңны белмисең.

Кызы белән Гөлсинә апа күрешеп тора, ире белән аңа кунакка йөри. «Әйбәт кабул итәләр», – дип, үзенә хас өлгерлек белән «отчет бирә» Юра абый. Шул вакытта ук җитдиләнә дә – үзенең туганнары белән күптән аралашмый икән. Гөлсинә апа булмаса, хәзер шушылай елмая алыр идеме икән?

– Яшермим, зонада булырга туры килде. 10 ел утырдым. Ләкин бу вакытны искә төшерәсем килми. Аннан туры интернатка эләктем, чөнки беркемем дә калмаган иде. Монда үз бәхетемне таптым, сәламәт яшәү рәвеше алып барам. Аракы эчмим, тәмәке тартмыйм. Ахырда барысы да шулай җайланганына мин бик шат, кызым...

– Кочаклап төшсәм ярыймы? – дип сорап куя Гөлсинә апа, үзләрен фотога төшергәнне күргәч.

– Кирәк хәтта! – дип хор белән җавап кайтарабыз без.

АЛДАН САНА

Фәрит абый. Аңа монда шулай өйдәгечә эндәшәләр. Һәм бу эндәшүдә чак кына сизелерлек бер диссонанс бар. Әкрен генә, әле дә төз гәүдәсен бераз иеп, таякка таянган бер кеше атлый. Бар тормышы йөзендә чагыла дигән гыйбәрә аның турында. Җыерчыклар һәм җөйләр белән сырланган йөз – үткән еллар чагылышы.

– Тормышымда барысы да шома бармады минем. Кемнеке шома гына бара соң ул? – дип, моңсу гына елмая ул. – Һәрвакыт әйбәт була алмый. Озак утырдыммы? Болай дип җавап бирәм: җитәрлек!

Фәрит абый Казанда туып-үскән. Монда мәктәпне тәмамлаган, хәрби училищега укырга кергән. Әмма укымаган – «сәбәпләре булды», ди. Диңгез буена хәрби хезмәткә китеп, шунда өйләнгән һәм шунда ялгышлык та кылган.

> **– 90нчы еллар нинди булганын, үзегез беләсез. Исән калырга тырышырга туры килде. Ни дисәң дә, акча җиңел килгән чаклар булды. Бер тапкыр, ике тапкыр, аннан соң киртәләр юкка чыга – барысы да нормага әйләнә.**

– Төрмә – тәҗрибә һәм нәрсәгәдер өйрәнү, дигән фикер яши. Яхшы кешеләрне анда очратсам да, мин болай дим: ул – әшәкелек. Төрмә үзеннән җибәрми, үз ихтыярыңнан башка сине эзәрлекли. Беркем дә аңардан саклану чарасын алдан күреп куя алмый. Мин гел кабатлыйм: анда әләгүгә китерә торган адымнар ясарга ярамый. Юкса бөтен тормышың упкынга тәгәрәячәк. Бер ялгыш адым атласаң, калганнары үзеннән-үзе дәвам итә. Әмма син үзең моны сизмисең икән.

Иреккә чыккач ук мин Казанга, әни янына кайттым. Хатыныма төрмәдә чакта: «Мине озак көтәргә туры киләчәк. Яхшы кеше очратсаң – кияүгә чык», – дип хәбәр салган идем. Икенче тапкыр гаилә корырга насыйп булмады.

– Тиңнәр бар иде! – ди ул. – Юлымда яхшы хатыннарны очраттым. Мөгаен, үзем юньсездер инде.

– Төрмә ялгызлыкка илтәме? –дип сорыйм мин Фәрит абыйдан.

– Минем яшьтә әйе, ялгызлыкка, – дип, моңсу гына елмая ул. – Дусларымның күбесе инде вафат. 90нчы еллар нинди булганын, үзегез беләсез. Исән калырга тырышырга туры килде. Ни дисәң дә, акча җиңел килгән чаклар булды. Бер тапкыр, ике тапкыр, аннан соң киртәләр юкка чыга – барысы да нормага әйләнә. Мин болай уйлыйм: «җиде кат үлчә – бер кат кис» – тормышның үзе турында. Нинди гамәлләр кылырга, нинди сүзләр әйтергә кирәген уйларга кирәк. Бер адым булса да, алдан уйлап куярга. Менә шул.

– Фәрит абый, сезне чын мәгънәсендә бәхетле итә алырдай нәрсә бармы ул? – дип кызыксынам мин әңгәмәбез ахырында.

– Барыннан да бигрәкме? – ди ул кинәт җанланып. – Кызларымны күреп, гафу үтенү. Күрергә генә – башка берни дә кирәкми! Аларның исән булуын, мединститут бетергәннәрен, берсенең, кияүгә чыгып, чит илгә киткәнен беләм мин – кызыксынам бит. Әмма шалтыратышмыйбыз. Ул вакытта яннарында булмагач, хәзер нәрсә бирә алам инде мин аларга? Әлбәттә, тормышның дәвам иткәнен мин аңлыйм, шатланырга кирәк. Һәрбер яңа көнгә. Шундый хәлләр менә...

PRESSA.RU

ӘТИ-ӘНИЛӘРЕГЕЗГӘ ШАЛТЫРАТЫГЫЗ. ҺӘМ АЛАРНЫ ГАФУ ИТЕГЕЗ

Ольга Шмелёва, гаилә психологы, йөрәктәге хәсрәттән һәм күңелгә җыелган ташлардан арыну ысуллары турында.

Әти-әнине ничек гафу итәргә? Беренче карашка, сәер сорау. Сине бу якты дөньяга тудырган кешеләр ник гаепле булырга тиеш? Сезне кайгырткан, яратканнары өченме? Әмма мин үз өлкәмдә эшләү вакытында күңелләрендә әти-әниләренә карата рәнҗеш йөрткән 30, 40, 50 яшьтәге кешеләрне бик еш очрата башладым. Кичерергә теләмиләр дә. Бәлки, алар хаклыдыр? Балачакта әти-әниләре аларга карата нинди мөгамәлә күрсәткәнен кем белә? Кайчак миңа әңгәмәләр вакытында исерек әтинең гаилә әгъзаларына балта күтәрүе, ә әни кешенең каеш белән генә «тәрбияли» белүе кебек коточкыч вакыйгалар турында ишетергә туры килә. Моны гафу итү түгел, оныту да авыр.

Ләкин бөтендөнья психотерапиясе, үз-үзеңә аңлауның, танып-белү һәм рухи үсешнең төп шарты – әти-әниләрне кабул итә һәм гафу итә алуга корылган. Чөнки, телибезме моны, теләмибезме, әти-әниләрдән «торабыз», генетиканы беркемнең дә кире кага алганы юк. Әгәр мин әтине (әнине) кабул итмәсәм, үз-үземне дә беркайчан кабул итә алмаячакмын.

Бала аңсыз рәвештә әти-әнисен кабатлый. Ягъни малай кеше ир-атның үз-үзен тотышын әтисеннән карап өйрәнә, кыз-бала әнисеннән үрнәк ала. Әгәр үрнәк камиллектән ерак торса (мәсәлән, эчкече ата), ир балага мондый хәлгә төшмәс өчен, бик нык тырышырга туры киләчәк, чөнки ул балачактан ук әтисенең гадәтләрен губка сыман сеңдереп үсә. Барлык балалар да, атага каршы чыгып, башка төрле булып үсәргә сәләтле түгел. Әмма һәммәбездә дә моны булдыра алырлык ресурслар бар. Мәсәлән, әти кешене гафу итеп, ачу сакламас өчен. Атасыз үсәргә туры килсә – яхшымы ул начармы – ул да булмас иде бит.

Мәсәлән, олыгайган кыз әнисенә балачактагы үпкәләрен тотуны дәвам итеп, туры килгән саен аларны исенә төшереп тора икән, димәк, аңа игътибар һәм ярату җитмәгән... Нәфис, ягымлы, яратыла алырдай булырмы ул? Әни кешегә үпкә саклаганда, хатын-кыз табигатенә, дөньяга һәм мәхәббәткә ничек ачылырга мөмкин? Күңелне рәнҗеш ташлары белән уратып алып, хатын-кыз бәхете булмаганга зарлану сыман бу.

Нәтиҗә нинди? Әти-әниләрне гафу итү, беренче чиратта, үз-үзең, сәламәтлегең һәм бәхетең өчен кирәк.

Әти-әнине гафу иткәннән соң, барысы да яхшы якка үзгәрәчәк. Балачакта әти-әнидән бирелеп бетмәгән наз һәм игътибарны хәзер көтү файдасыз. Аларны кичермәсәгез, үзегезне кайгыртырга юл ача алмассыз. Көйсез бала кебек булсагыз, барысы да аз булып тоелыр. Бу – корбан позициясе. Ә корбанга, билгеле булганча, ярдәм итәргә мөмкин түгел.

Әти-әниләргә карата булган балачак үпкәләреннән арынырга теләгәннәргә минем киңәшләрем.

Ничек гафу итәргә? Нәрсәдән башларга? Иң элек әниегезгә һәм әтиегезгә түбәндәге схема буенча аерым терапия хатлары языгыз:

– Нәрсә өчен рәхмәт белдерәм.
– Нәрсә өчен гафу үтенәм.
– Нәрсә өчен кичерәм.
– Нәрсә өчен рәхмәт белдерәм.

Бу хатларны язу шактый авыр. Аларны, күңел биреп, балачактагы барлык тискәре һәм уңай детальләрне искә төшереп язарга кирәк. Хис-кичерешләр кәгазь битендә калсын. Хатларны, билгеле, беркемгә дә күрсәтергә кирәкми. Хәтта ягарга да мөмкин.

Аннан соң әнидә – кечкенә кыз, ә әтидә – кечкенә малайны күрергә киңәш итәр идем мин. Алар балачакта үз-үзләрен ничек хис иткәннәр? Ничек яшәгәннәр? Әти-әниләренең игътибары һәм мәхәббәте аларга җиткәнме? Әти-әниегез сезне булдыра алганча яраткан, шуны аңлар өчен, аларның балачагына анализ ясагыз. Бирә алганның барысын да биргән алар. Бу, алар яшьлектә, сезне тәрбияләгән вакытта булдыра алган, МАКСИМУМ. **Аларга көйсез бала күзләре белән түгел, ә ОЛЫ кешенең аңлаучы, мәрхәмәтле һәм РӘХМӘТЛЕ карашы белән карагыз.**

Шуннан соң үзегезнең кечкенә чактагы фотосурәтегезне алып:

– Үзеңне ничек хис итәсең?
– Нәрсә турында уйлыйсың?
– Нәрсәдән куркасың? Ни телисең? – дип сорагыз.

Сорауларны – уң кул, җавапларны сул кул белән языгыз. (Сулагайлар киресенчә).

Бу бирем күңелдәге кечкенә балага ни кирәклеген аңларга ярдәм итәчәк. «Кечкенә үзегез» белән иң яраткан әти-әни буларак сөйләшеп карагыз. Аны тынычландырыгыз, теләкләрен үтәгез. 21 яшьтән өлкәнрәк булсагыз, «күңелдәге бала»гызның рухи тотрыклылыгын кайгырту өчен барлык мөмкинчелекләрегез дә бар дигән сүз. ҮЗЕГЕЗГӘ ҮЗЕГЕЗ ИДЕАЛЬ ӘТИ-ӘНИ БУЛЫР ӨЧЕН ДӘ. Бу олы, тәҗрибәле кеше позициясе. Бу тормышыгыз, бәхетегез өчен җаваплы, әти-әниегезгә иң зур БҮЛӘК – ЯШӘҮ бүләк иткән өчен (һәм менә шуның өчен генә дә чиксез рәхмәтле булырга мөмкин) рәхмәтле булу дигән сүз.

Әти-әнисе белән мөнәсәбәтләрдә «уңыш елмаймаган» бер клиенткамны хәтерлим мин. Икесе дә эчкече, әтисе әнисенә кул күтәрә торган булган. Олыгайгач, туташның аларга карата нәфрәте уяна. Шәхси тормышы да җайлана алмый. Ирләргә ул, әтисенә охшатып, җирәнеп карый. Минем белән танышкан вакытта аңа 33 яшь иде. Әти-әнисен гафу иткәч, үзгәргәнен күрсәгез! 3 нче консультациядә үк инде әтисен якларга, ә әнисен акларга тырышты. Хәзерге вакытта беренче тапкыр ир-ат белән мөнәсәбәтләр корырга тырыша һәм... эшендә дә зур уңышларга ирешә! Ул бәхетле.

Гафу итү – үпкәләрне оныту дигән сүз түгел... чөнки, җае чыккан саен, алар барыбер искә төшәчәкләр. Гафу итү – сезгә карата булган мөнәсәбәтне кабул итү дә түгел. **Гафу итү – МӘҢГЕЛЕККӘ газаплардан арынып, күңелдәге ташларны юып, савыктыручы мәхәббәт һәм зирәклек энергиясен кабул итү ул. Мин сезгә чын күңелемнән шуны телим.**

«Зацвёл багульник». Рассам: Александр Шилов.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАН АКСАКАЛЛАРЫ:

ТУГАН ҖИРДӘН КИТҮ ЮК!

Автор:
Ксения Сёмина

Сугыш кичеп, фашизмны җиңгән ветераннарыбызга без һәрчак олы хөрмәт белән карыйбыз. Вакыт бара. Бүген инде аларның балалары өлкәнәйде – үзләре әби-бабай булдылар. Язмышлары әти-әниләренеке кебек фаҗигале булмаса да, зирәклекне, олпатлыкны туплап өлгергән инде алар. Әлеге буын вәкилләренең берсе турында «Татарстан» бүген бик рәхәтләнеп яза.

...Чистай районының Татар Гаделшасы авылындагы берсеннән-берсе бизәкле йортлар безне – ачык йөз, ә алар каршында чемченеп йөргән казлар тәкәббер кыяфәт белән каршы алды. Гаделша клубы директоры Гүзәлия Мусина белән көзгә пычракка баткан сукмаклар буйлап авылның атаклы урыны – «Хисмәтуллиннар йорты»на юнәлдек.

ГЕННАРНЫҢ ЙОГЫНТЫСЫ БАР УЛ!

– Күптән түгел бу йортның бенефисын үткәрдек, – дип сөйли Гүзәлия. – Бик зур бәйрәм булды – кунаклар күп килде, иҗат кешеләре дә бар иде, үз әсәрләрен башкардылар. Гомумән, йорт хуҗасы Мансур абый янына кинәшкә бөтен авыл халкы йөри. Аның әтисе бик зирәк кеше булган, ул да шундый. Мин аны «универсал» дип атыйм. Кирәксә, ярдәм дә итә, җырлый да, бии дә. Уллары да бик әйбәт. Берсе, Марс исемлесе, фәннәр докторы, «Татмелиоводхоз»ны җитәкли; икенчесе – икътисад фәннәре кандидаты, Казан мәдәният университетында кафедра мөдире, Казан аграр университетында укыта. Икесе дә Россия агросәнәгать комплексының мактаулы хезмәткәрләре. Геннарның йогынтысы бар ул!

– Гаделша өчен Хисмәтуллиннар төп меценатлар булып исәпләнә, бер генә бәйрәм дә аларның ярдәменнән башка узмый, – дип дәвам итә сүзен Гүзәлия. – Еш кына бөтен гаиләләре белән кайталар, ата-аналарына хуҗалык эшләрендә булышалар. Хуҗалыклары зур бит – сарыклар да, кәҗәләр дә, тавыклар да, умарта да асрыйлар. Пенсиядә булса да, Мансур абый бер дә тик тормый – фермер ул. 100 гектардан артык җир эшкәртә, ашлык, бал бирүче үсемлекләр һәм башка культуралар үстерә. Ә Зөлфирә апа умарта карый, бакчасында искиткеч матур чәчәкләр үсә.

ЗИРӘКЛЕК ЧЫГАНАГЫ

Менә без ачык яшел төскә буялган, агачтан уеп ясалган бизәкләр белән сырланган йорт янына килеп җитәбез. Каршы алырга хуҗа үзе чыга – зәңгәр күзле, нык гәүдәле, кояшта янган йөзле, башында – түбәтәй. Сөйләшкәндә ул аңа кагылып-кагылып ала, әйтерсең, кирәкле сүзләрен шуннан ала, безгә инде түбәтәй зирәклек чыганагы булып тоела башлый.

Сырлап ясалган йорт бизәкләре белән таныштырганда, Мансур абыйның горурлыгы йөзенә чыга. Тәрәзә йөзлекләрен, сыерчык ояларын Марсның улы – өлкән оныгы Марат уззган җәйдә ясап киткән икән, ә сеңелләре Азалия белән Камилә аңа булышып торган. Зөлфирә апаны менә өйдә тота алмадык – аны оныкларын карашырга чакырып алганнар. Йортның һәр тәрәзә төбеннән безне ул үстергән гаҗәеп матур гөлләр генә сәламләде.

«ГОРУРЛАНЫРЛЫГЫБЫЗ БАР»

Кунак бүлмәсенең ике дивары да грамоталар һәм рәхмәт хатлары белән тулган. Берсендә – улларыныкы, икенчесендә – оныкларыныкы.

– Балаларыгызны ничек шулай әйбәт итеп үстерә алдыгыз? Сере нидә?

– Бернинди дә сер юк. Мин тәрбияләмәдем аларны, шул гына!

– Кем соң?

– Әниләре. Мин өстән күзәтеп кенә тордым. Кирәксә, катнашырмын, дип уйлый идем. Туры килмәде. Бер тапкыр әниләре берсенә яхшы гына эләктерде – кесәсеннән тәмәке тапкан булган. Ул аларны кирәк чакта гына тирги иде, гадел итеп тәрбияләде. Хезмәткә, матурлыкка һәм дингә мәхәббәт белән үстерде. Колхоз вакытында мин хуҗалыкның баш агрономы идем, ел әйләнәсе командировкалардан кайтып кермәдем, чәчү орлыгы, ашлама эзләп чабарга туры килде. Шуңа күрә балаларымның тәрбияле булулары – минем хезмәт түгел, алар әниләренә һәм геннарга рәхмәтле булырга тиешләр, дияр идем.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР ЭШЛӘРГӘ КИРӘК

Саубуллашканда бизәкле капкаларга тагын бер кат сокланып карадым.

– Хатыным шәһәргә күчеп китик дип әйтеп караган иде, туган җирдән китү юк, дидем, – ди Мансур абый.

– Балаларыгызны җибәргәнсез бит...

– Монда фәннәр докторы булып булмый бит. Алар еш кайта, булышалар, телефон аша сөйләшеп торабыз, кайсыбызга нәрсә кирәк, табып бирәләр.

– Гаиләдән килгән сыйфат инде бу сезнең, димәк...

– Коръәннең һәр сүрәсе дөрес яшәргә өйрәткән. Әмма үгет-нәсыйхәт артыннан фанатларча ияреге кирәк түгел, тирә-юньдәге кешеләргә дә, үзеңә дә яхшы булсын өчен, игелекле гамәлләр кылырга кирәк. Шулай итсән, тормышың җиңел, якты булачак.



Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU

ИРЕК – ИРЕКЛЕ ОЧЫШТА

Автор:
Әскәр Сабиров

Адәм баласын матур итеп яшәүдән тыеп булмый. Ирек Вилданов матур яши. Буш вакытында күктә оча. Очарлыгы да бар – самолет үзенеке, һәм ул һәрвакыт һавага күтәрелергә әзер. Бу инде ниндидер «Сессна» түгел – легендар У-2 (По-2)! Раритет, андыйлар бөтен илдә – бармак белән генә санарлык.

Фото: Ната Смирнова

Койрыгында кызыл йолдызлар балкый, канатлары тукымадан, фюзеляжы фанерадан, штурвал урынына гади генә тоткыч һәм пилот кабинасында иң кирәкле приборлар гына… Утызынчы елларны хәтерләткән бу могҗизага карата Балтач аэродромында – ә Вилданов бу гаҗәеп очкычын шунда тота – мөнәсәбәт гаять сакчыл, ләкин фанатларча түгел. Ни дисәң дә, ул бит әле музей экспонаты түгел, ә бүген дә күккә күтәрелергә сәләтле чын очкыч!

Дәлилләр кирәкме? Ирек очучы кәнәфиенә утыруга, ярдәмче техник самолетның калагын борып җибәрә… «От винта!» дигән команда яңгырый – һәм моторның йомшак кына гөрелтесе астында биплан үләндә сикергән чикерткәдәй «уйнап» ала да, җирдән аерылып, күккә күтәрелә. Очучы һәр ягыннан җилләр уйнап торган ачык кабинасыннан, Политбюро әгъзасыдай, вәкарь белән генә җирдә калган бездәй гади кешеләргә кул изи.

Вилдановның У-2се өчен Көнбатышның берәр коллекционеры, ике дә уйламыйча, бернича мең доллар чыгарып салыр иде. Көнбатышта гына түгел. Бөтен кешегә дә самолетлы булу бәхете тәтеми. Мондый самолетлы булу – бигрәк тә. Дөрес, Ирекнең Швейцария банкында миллионнары юк, каттә бизнесмен да түгел үзе. Элек авиация техникы булып эшләгән, хәзерге вакытта гади пенсионер, һәвәскәр очучы. Легендар У-2нең төгәл күчермәсен ул үз куллары белән төзегән, әйе, әйе, бөтенләе белән: фюзеляждагы заклёпкаларга кадәр.

НИГӘ МАШИНАНЫ ЮККА СЕЛКЕТЕРГӘ?

Май ае җиткәч, алты елга сузылган татлы газаптан соң (һәр кичне, ял һәм бәйрәм көннәрендә дә эшне туктатмыйча төзи ул аны), У-2 машинасын дөньяга күрсәтергә була диярлек. Ирек үзешчән авторлар төзегән машиналарга сынау үткәрә торган таныш очучысы белән бәйләнешкә керә. Авиациядә бу җаваплылыкны үз өстенә алган һәм һөнәри фатиха биргән өчен, әлбәттә, түләргә кирәк. Ә Вилдановның кесә ягы югарак чак.

– Нинди акча? – ди, үз чиратында, сынаучы. – Минем өчен чын У-2 штурвалы артына утыру – үзе гонорар ул!

Бипланны сүтелгән хәлдә ике «Газель»гә төяп, Сарман аэродромына алып киләләр. Биредә самолетны яңадан җыялар һәм очышка әзерлиләр. Конструктор белән очучы бергәләшеп сынау планы турында сөйләшәләр. Барысын да фән кушканча эшләргә ниятлиләр: башта полоса буйлап кына йөрергә, аннан соң җиңелчә генә сикертеп алырга, аннан соң тагын… Һавага дүртенче тапкырдан соң гына күтәрелергә планлаштыралар.

– Очучы – пилот кәнәфиенә, мин аның артында урнаштым. Самолет чаба башлауга, ул тоткычны үзенә таба тартты – самолет күтәрелде, без очып киттек! – дип искә ала Ирек. – Ниләр кичергәнемне тел белән генә аңлатып булмый. Җиргә утыруга, мин аңа графикны бозуы турында әйтәм, ә ул болай дип җавап кайтарды: «Машинаны полоса буйлап тиккә селкетеп йөрт-

кәнче, күтәрелик, дип уйладым, барысы да яхшы бит...»

Вилданов машинасын төгәл сызымнар буенча төзи. Аларны эзләп табар өчен генә дә бер ел вакыт таләп ителә. Бөтен документлар Казан вертолет заводының (сугыш вакытында 387нче завод) архивында саклангандыр, дигән өмет белән шунда бара. Үз заманында биредә 11 мең төнге бомбардировщик төзелгән бит. Ләкин анда җилкә генә сикертәләр. Янәсе, бөтен булган сызымнар янгын вакытында янып әрәм булган... Шуннан соң Казан музееның запаслары арасында У-2 нең уникаль нөсхәсе саклануын исенә төшерә. Биредә дә аны колач җәеп каршыламыйлар, машинаны якыннан күрү өчен хәтта күпмедер түләргә дә туры килә. Аның каравы, Ирек әлеге машинаның конструкциясен үз куллары белән тотып карап, өйрәнеп чыккан. Ә сызымнарны исә соңрак китапханәләрдән һәм интернеттан эзләп тапкан...

Булачак вакыйгаларны исәптә тотып фикер йөрткәндә, сызымнар да, җыю сыйфаты да тел-теш тидерерлек түгел, тик берсендә двигатель генә «киреләнеп ала».

ЙОЛДЫЗЛАР ТЕЛӘКТӘШ БУЛМАСА ДА...

Августта Ирек Вилдановны У-2се белән Коркачыкка авиация бәйрәменә чакыралар. Мажараларсыз гына барып җитә. Кайтканда исә күңелсез хәл килеп чыга. Машинаның җирдән аерылып китүе була, мотор тынсыз калып сүнә. Ярый әле полоса озын булып чыга – күңелсез хәлне читләтеп узу насыйп була...

Вилдановның яңа У-2 сенең двигателе шактый күпне күргән «аксакал» икән инде. Сугышка кадәрге М-11 серияләп чыгарылган гадәти машинада торган. Россиянең ерак бер почмагыннан эзләп табып, Вилданов, бурычка керә-керә, аны хуҗасыннан 350 мең сумга сатып ала. Барысы да яхшы кебек, ләкин моторга яраклы авиация бензинын хәзер чыгармыйлар икән. Башка бензин салсаң, эссе һавада двигатель чыгымчылый башларга мөмкин. Коркачыкта ул көнне утыз градустан да югарырак эсселек була шул.

Бервакыт җирдә вакытта двигатель бушка эшләп утырганда ниндидер бер ят тавыш ишетелә. Подшипнигы таралган булып чыга. Аны алыштыралар. Ә менә улын Вилданов үзе белән очышларга алмый. Кабинада утырырга, винт калагын борырга – рәхим ит! Ә күккә күтәрелергә рөхсәт юк.

– Яңарак двигатель кирәк, – дип фикер йөртә Ирек. – Интернетта берне таптым инде. Күз алдына китерәсезме – өр-яңа, мае да кипмәгән әле! Тик биш йөз мең сум! Андый акчаны каян алырга?

Хыялындагы самолетны төзегән вакыттагы эзләнүләре һәм табышлары турында сөйләгәндә, Вилдановның күзләре яна башлый. СССРда У-2 соңгы тапкыр алтмыш ел элек чыгарылган булган. Шуңа да һәрбер табыш – лотереядә отуга тиң! Әйтик, У-2нең үз тәгәрмәчләрен табып булыр дип кем уйлаган? Аларны аэродромнарның берсендә күреп ала ул – самолетларга аккумулятор ташу өчен кулдан эшләнгән арбага киертелгән була алар.

Двигатель һәм тәгәрмәчләр – безнең каһарманыбыз У-2нең «үзенеке» булган элементлар шушылар гынадыр, мөгаен. Приборлар тактасындагы датчиклар, канатларын нығытыр өчен кулланылган корыч арканнар – У-2нең ерак булмаган «туганы» Ан-2 дән. Калганнарын үзенә кулдан эшләргә туры килә Ирекнең – элеккеге технология буенча.

– Перкальне, канатларга һәм У-2 фюзеляжының бер өлешенә тарттырылган тукыманы безнең сәнәгать әле дә чыгара икән – бу яктан шәп булды, – дип сөйли Ирек. – Ә менә ике миллиметр калынлыктагы сыйфатлы фанераны утызынчы елларда гына эшләгәннәр, хәзер андый итеп эшли белмиләр. Финнарныкын алырга туры килде, ул да әле совет чорындагыдан калыша, җитмәсә кыйммәткә дә төште – җитмеш биш меңләп киткәндер...

Балачакта үз куллары белән самолет җыю турында кайсы гына малай хыялланмыйдыр? Күрәсең, әлеге матур хыялның чыңга ашмавына акча да, вакыт җитмәве дә гаепле түгел. Йолдызнамә яисә уңышның арты белән борылуы – бигрәк тә. Һәрхәлдә, Ирек Вилдановка йолдызлар бөтенләй теләктәш булмаган. Киресенчә булмаса әле.

КАНАТ КУЯ, КӨЧ ӨСТИ

Туксанынчы еллар башында һәвәскәр очучы Ирек Вилданов фаҗигагә юлыга. Штурвал артында үзе була, җиргә утырырга барганда, двигатель сүнә. Машинаны утыртмакчы була, әмма җирдә курс буенча туп-турыдан металл торба тырпаеп тора...

Ирек хастаханәдә бер ай дәвалана, соңыннан да бик озак терәкләнә. Табиблар аңлаталар: бер-ике сантиметрга сулгарак бәрелгән булса, «ашыгыч ярдәм»нең кирәге дә калмаган булыр иде. Ә болай – вакыйга маңгайда җәй булып сузылып калган. Кабат күккә күтәрелү теләгеп аз гына да киметмәгән ләкин. Гәрчә шушындый ун очракның тугызында очу теләге бөтенләй юкка чыгадыр, мөгаен.

Ул самолетны да Ирек үз куллары белән төзегән булган. Беренче машинасы. Двигателе – мотоцикл элементлары белән өстәп көйләнгән «Привет» дигән моторлы көймәдән...

– Һәвәскәр авиация өчен двигательләрне бездә беркайчан да чыгармадылар бит, нишләмәк кирәк? – ул вакыттагы сәер ноу-хауның

Фото: Александр Эшкинин

тамырлары кая тоташуын шулай аңлата Ирек. – Хәзер дә чыгармыйлар. Ә Австриядә эшләнгән гади генәсе дә – миллион ярым! Әллә нәрсә дә түгел үзе, ярый инде.

Вилданов белеп сөйли. Беренче машинасыннан соң, У-2 гә тотынганчы, тагын ике җиңелчә самолет төзи әле ул. Канада сызымнары буенча. Дөрес, үзе өчен түгел – аңа акча кирәк бит. Аның каравы, куллары остарган.

Ул, гомумән, гаепне читтән эзләргә күнекмәгән. Ни булса да, димәк, шулай булырга тиеш. Хәтта үз вакытында аның күкләр турындагы хыялына аяк чала язган хәрби комиссарны да якты хатирәләр белән искә ала ул.

Армия хезмәтенә барыр яшькә җиткәндә, ул инде җитди авиациягә әзер була. Активында – берничә тапкыр парашюттан сикерү, берничә ел дәвамында авиамодельләштерү түгәрәгендә шөгыльләнү, Бигеш аэропортында авиация техникгы булып эшләү. Билгеле, һава десанты гаскәрләренә җибәрүләрен сорый ул.

– Буең бәләкәй, – дип кырт кисә хәрби комиссар.

– Алайса – авиациягә!

– Ә авиациягә набор бетте инде, мин сиңа кызыклырак урын табам, – дип, серле генә елмая хәрби кеше. Һәм таба да – стройбатка, Тбилисида.

Грузиядә Ирекккә барыбер аэродромны күрергә насыйп була – Вазианидагы хәрби базага ангар төзиләр. Шулай бервакыт очучылар белән сөйләшеп киткәч, тегеләр авызларын ачып гаҗәпкә калалар: төзелеш батальоны солдаты авиация турында каян шулкадәр күп белә? Аңлата Ирек: гражданкада авиация техникгы булып эшләгән идем, ди.

– Кирәк бит ә! – дип тел шартлата офицерлар, өчесе бергә фуражкаларын бетонга бәреп. – Безгә аэродромга белер-белмәс кешеләрне җибәрәләр, әзер техникларны – стройбатка?!

Аның каравы, армиядән соң авиация белән аралар якыная. Ирек, яңадан Бигешенә кайтып, авиациятехника училищесын тәмамлый. Әлбәттә, техникка очарга рөхсәт юк, ләкин үҗәт Вилдановны бу гына туктатамы соң? Сменасын тәмамлый да «Як-40»ка утыра – һәм кырык минуттан соң ул Казанда. Ике сәгать дигәндә, Балтачта – һәм ул самолет яки планер штурвалы артында. Һәркем шуны булдыра аламы? Ләкин хыял канат куя, көч өсти!

ХЫЯЛЫ – ЛА-МАНШНЫ КИЧҮ

Ни өчен ул нәкъ менә У-2не төзергә уйлаган соң? Билгеле, шулай туры килгәнгә генә түгел. Ирек сугыш елларында Татарстанда, Казан заводында чыгарылган легендар самолетны янә күккә кайтаруны изге бурыч, дип саный. Үзенең У-2сен үзенә күрә бер музейга әйләндерергә хыяллана: бер торак пункттан икенчесенә очарга. Туп-туры берәр ялан кырга төшеп утыра да сугыш елларында немецлар «Рус фанера» дип йөрткән әлеге очкычларда якташыбыз Мәгубә Сыртланова һәм ул хезмәт иткән данлыклы төнге хатын-кызлар полкының башка кызлары шушы гади генә самолетларда ничек итеп немец гаскәрләренә зыян китерүләре, бу самолетларның разведкада да, санитар авиациядә дә алыштыргысыз булулары турында сөйли…

Гомумән, Вилданов шундый бай авиация тарихы булган Казанда авиация музее булырга тиеш, дип саный. Экспонатлар сыйфатында төп нөсхәләреннән ерак торган макет-муляжлар түгел, ә алга киткән авиация музейларындагы кебек очарга сәләтле чын самолетлар булырга тиеш. Мәҗбүри рәвештә экспонатларның берсе, Вилданов сүзләренә караганда, французларның «Блерио 11» самолеты булырга тиеш – узган гасырның башында бу самолетта Луи Блерио беренче булып Ла-Манш аша очкан.

– Казанның ни катнашы бар монда, диярсез. Бар шул. «Блерио 11»дә Казан император университетын тәмамлаган данлыклы рус очучысы Александр Васильев очкан. Ул 1911 елда тарихта беренче тапкыр үткәрелгән Петербург – Мәскәү авиаярышында җиңүче булган, – дип аңлата Вилданов.

«Блерио 11»нең төгәл күчермәсен төзеп, аның белән Ла-Маншны кичү – Ирек Вилдановның бүгенге хыялы бу. Килеп чыгармы?

PRESSA.RU

ТАТАРСТАН

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә

Индекс **П 2381** – татар телендә: алты айга язылу бәясе **864 сум 24 тиен**
Индекс **П 2378** – рус телендә: алты айга язылу бәясе **864 сум 24 тиен**



Ф.СП-1

Почта России

АБОНЕМЕНТ на ~~газету~~ журнал П 2381 (индекс издания)

Татарстан (наименование издания) количество комплектов:

на 2017 год по месяцам:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12
✓	✓	✓	✓	✓	✓						

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (фамилия, имя, отчество)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ | место | литер

на ~~газету~~ журнал П 2381 (индекс издания)

Татарстан (наименование издания)

Стоимость: подписки 864 руб. 24 коп.; переадресовки ___ руб. ___ коп. количество комплектов:

на 2017 год по месяцам:

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12
✓	✓	✓	✓	✓	✓						

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (фамилия, имя, отчество)

Шулай ук электрон почта аша да язылырга мөмкин:
milyaushanb@tatmedia.com
Дистрибуция бүлеге хезмәткәрләре, шалтыратып, кызыксындырган сорауларыгызга җавап бирерләр.

Яки түбәндәге телефон буенча тарату бүлеге җитәкчесе Миләүшә Байрашевага үзегез шалтырата аласыз: **тел. +7 (843) 222 09 79**

‹ КАЗАНБАШ АКБҮРЕ ›

«Татарстан» журналы, кызыклы атамалы татар авылларын, аларның тарихын һәм бүгенге яшәешен яктырту максаты белән, яңа сәхифә башлый. Сез дә безгә үз авылларыгызның хикмәтле яклары, гыйбрәтле хәлләре, уңган-булган кешеләре турында яза аласыз.

Яшел Үзән районы Олы Күлбаш авылы

КАЗАНСУ ЕЛГАСЫ ШУШЫННАН БАШЛАНА

Арча районы Казанбаш авылында яшәүче мулла – Корбангали хәзрәткә биш вакыт намазга басарга, берничә мәртәбә төшенә кереп, колхоз рәисенең рухы ярдәм иткән. Авылның моннан кала да хикмәтле яклары байтак: шушы тирәдә Казансу елгасы башлана, узган гасырның 30нчы елларында драматург Кәрим Тинчурин, шушында кайтып яшьләр белән аралашканнан соң, «Кандыр буе» пьесасын иҗат итә.

Автор:
Линар Закиров

КАЗАНСУ ЕЛГАСЫНЫҢ БАШЫ

Казанбашка килеп кергәч, мәдәният йортына таба юл тоттык. Зур бинаның тышына «мәдәни-көнкүреш үзәк» дип язып куйганнар. Мондый үтә дә милли эчтәлектәге язулы бинаны беренче күрүем иде. Машина белән килеп туктаганыбызны бер әби дикъкать белән күзәтеп торган икән. Янында оныгы да бар.

– Апа, ни өчен авылыгыз Казанбаш дип атала? – дип сорадым мин аңардан.

– Казансу елгасы шушы тирәдән – урман эченнән башлана. Җир астыннан бәреп чыга, дип сөйлиләр иде без мәктәптә укыган чакта. Ул урынны үземнең барып күрә алганым юк. Бездән өстәрәк Казанка дигән авыл бар, елга нәкъ менә шуннан башлана да инде. Мин олы кеше, бездән анда кадәр ничә чакрым икәнлеген белмим дә инде, – диде ул.

Шулчак әби кеше:

– Менә бу абзыйны ычкындырма, мулла кеше ул. Бар, сөйләштер, ул монда гомер иткән кеше, бик күп әйберне белә... – дип, мәдәният йорты каршында урнашкан йорттан таякка таянып чыккан бер ир-атка ымлады.

Фото: Линар Закиров, Акбүре авылының музей архивыннан





РӘИС НАМАЗГА БАСТЫРГАН

Аның исеме – Корбангали. Фамилиясен әйтмәде. Сәбәбен болай дип аңлатты:

– Энем, мин сәясәтне күп күрдем... Ул үзгәрмәде. Компартиянең эзе бүген дә килеп чыга... Мин 1944 елда Корбан гаетенә берничә көн кала туганмын. Шуңа да Корбангали дип исем кушканнар. Элек халык хәзергегә караганда динлерәк булган бит, – диде.

Корбангали абый, фермада эшләп, бөтен гомерен туган авылына багышлаган.

– Колхоз шундый җир: аның кешегә һәм икмәккә кадере булмады. Ә ул ике нәрсә булмаса, җәмгыять таркала. Менә колхозлар да таркалды, – дип, фәлсәфи карашын белдерде ул.

Авыл мулласы заманында күрше-тирәдәге 7–8 авылдагы малның хәл-әхвәлен көн дә белешеп торган. Ул чакта Казанбаш белән Төрнәле авылларында – икешәр мең баш мөгезле эре терлек, Кәтектә – ике мең дуңгыз, тагын шулкадәр сарык, Кече Төрнәледә – 150 баш хайван, Көек, Тылангыр авылларында да терлек саны җитәрлек булган. Корбангали абый авылдан-авылга язын-көзен, атка атланып – арба белән, кышын чанада йөргән.

– Ел әйләнәсе резин итек киеп йөрдек, фермада баткак, юл юк. Ә кеше бит резин итектән күп йөри алмый. Ул шахта киеме, аның белән аяк кибеп чыга. Колхозда ял да, отпуск та юк иде. Ә кешенең гаиләсе дә бар, өендә хайванын да асрарга кирәк. Бүгенге көндә, син уйлап кара, 40ар ел сыер савучыларның бөтенесе дә өйдә. Урамга чыга алмыйлар. Аяклары йөрми. Кайчандыр сыер сауган 15–20 кешенең берсен генә урамда очратып була. Мин дә көч-хәл белән атлыйм, табиблар протез куярга куша, – диде ул.

Корбангали абыйның пенсиягә чыкканына 13 ел булган. Казан ветеринария институтын тәмамлап, авыл фермасында 1969 елдан 2004 елга кадәр зоотехник булып эшләгәне өчен аңа бүген нибары 12 мең сум пенсия түләнә. Югыйсә ТАССРның атказанган зоотехнигы исеменә, «Почет билгесе» орденына ия Корбангали абый. Әңгәмәдәшем әйтүенчә, совет чорында бирелгән бүләкләр бүгенге көндә гамәлдән чыгарылган, ә ТАССРның атказанган зоотехнигын хезмәт ветераны исеменә тиңләштереп, пенсиягә ай саен 500 сум өстиләр.

– Лаеклы ялга чыккач, аяк сызлаудан интегеп, хастаханәгә йөри башладым. Тикшеренә торгач, аяк кына түгел, йөрәкнең дә тузганы ачыкланды. Ни өчен икәнлеге аңлашыла: иртәнге биштә торып, правлениегә барасың, кичке унга кадәр аяк өстендә. Еллар буе заводной механизм шикелле йөрисең. Правлениедә заводкаңны әйбәтләп борып чыгарганнан соң, ул беткәнче йөрисең дә өеңә кайтып егыласың. Партия режимы бик көчле иде ул заманнарда. Сөт күләме 100 граммга кимесә, правлениегә алып менәләр дә: «Оятсыз! Нәрсә эшләп ятасың?! Бомба төштеме сиңа? Ник киметтең?» – дип тиргиләр, – дип, колхозда эшләгән елларның ачысын искә алды Корбангали абый.

Бервакыт ул Арча мәчетенә баргач, шундагы имам: «Дәвалау артыннан йөрмә, барыбер файдасы тимәячәк. Әйдә, мәчеткә кил, биш вакыт намазга бас. Сихәтләнеп китәрсең», – дип әйткән.

– Сез шул сүзләргә ышандыгызмы? – дим.

– Бүтән чара калмагач, ышандым. Мин пенсиягә чыккан елны колхоз рәисе үлеп китте. 70 яшьләр тирәсендә иде ул. Бер әйбергә игътибар иткәнем бар: фермадагы эшчеләрнең күбесе пенсиягә җитә алмыйча үлеп китә. Инженер, агроном пенсиягә чыга алмады. Бригадирлар да эштән китүгә бакыйлыкка күчтеләр. Берзаман мәрхүм рәис төшкә керә башлады. «Нишләп син сыер савучыларга аңлатмыйсың?» – ди. «Мин бит намаз укыйм, әмма бишесен дә булдырып булмый, аны бит әле өйрәнеп бетерергә кирәк», – дим. Шуннан соң Арчага барып, мәдрәсәдә дүрт ел гыйлем алдым, гарәпчә язарга, Коръән укырга өйрәндем. Берничә елдан соң рәис яңадан төшкә керде. «Син барыбер эшләп бетермисең», – диде. Догалар укыганда, алар рәис рухына да барып ирешсен, дип тели башладым. Аннары ул кабат төшемә керде: «Эшне эшлисең, әмма ахырына кадәр башкарып чыкмыйсың». Авылыбыз мәчетенә көн дә йөри башлагач, ул соңгы мәртәбә төшемә кереп, болай диде: «Менә эшеңнең нәтиҗәсе күренә», – дип менә шундый сәер вакыйга белән бүлеште әңгәмәдәшем.

НАМАЗ УКУ – ФИЗЗАРЯДКА

Корбангали абый әйтүенчә, мәчеткә көн дә йөри башлагач, аның аяк авыртуы да җиңеләйгән, башы да чатнамый башлаган, йөрәге дә рәтләнгән.

– Намаз укыганда, сәҗдә кылганда, торасың, басасың – бу бит үзенә күрә физзарядка. Аллаһтан ышанып сорарга кирәк. Бу үз-үзеңне ышандыру кебек тә килеп чыга. Шуннан соң мәчеттән чыкмас булдым, хәзер биш вакыт намаз укыйм, азан әйтәм, – диде ул.

Кешене мәчеткә тарту бик авыр, һәр нәрсәнең сәбәбе булырга тиеш, ди авыл мулласы. Үз башына төшмәсә, кеше бер вакытта да теге яки бу мәсьәлә турында уйланмый.

– Яшьләргә авылда эш юк, иртәнге өчтә чыгып китәләр дә кичке унда кайталар. Аларның мәчеткә килергә вакыты калмый. Олыларның күбесе аяксыз. Ирләрне тарту кыен, күбрәк хатын-кызлар килә. Икенче яктан карасаң, безнең халыкны заманында диннән ваз кичтергәннәр. Чечен, таҗик, төрекмән, үзбәк кебек халыклар динне яхшы тота. Алар авылыбызга эшкә килеп, мәчеткә йөрергә дә вакыт таба. Кайберләре биш вакыт намазның барысын укымаса да, икесен, өчесен үтәргә тырыша.

ТУКАЙ ӨЧИЛЕСЕ, АХУНОВ ӨЧИЛЕСЕ

Авыл тарихы белән рәсми күзлектән танышу өчен, мәктәпкә юл тоттык. 60нчы елларда төзелгән бинаны быелтыр тулысынча төзекләндергәннәр, сүтеп-җыйганнар, дисәк тә була. Безгә музейда экскурсияне татар теле һәм әдәбияты укытучысы Луиза Габдрахманова үткәрде.

Өлкәннәр сөйләвенә караганда, Казанбаш 700–800 ел элек барлыкка килгән. Башта бу урынга удмуртлар, ә аннары ике мөселман кешесе килеп утырган. Авыл элек-электән хәзерге сыман зур булган. Төрнәле ягында Әби патша юлы бар. Аны патшабикә Екатерина II Казанга сәяхәт кылган вакытта шул урыннан үтә алсын өчен салганнар. Күпер бүген дә үз урынында.

– Элек авылыбыз Кармыш дип аталган. Безнең якларда Кармыш исемле данлыклы кеше яшәгән. Ул йомышлы татар булган – патшага хезмәт иткән. Авылны башта аның исеме белән атаганнар, соңыннан Казанбашка үзгәрткәннәр. Чөнки данлыклы Казансу елгасы безнең яклардан башлана. Хәзер инде ул башланган урында Казанка авылы бар. Казансу белән бергә элеккеге чишмәләр дә саегып, кайберләре юкка да чыкты. Һәр кешенең үз өендә су булгач, чишмәләргә игътибар кимеде. Безнең районда аларны карап торалар әле, эшмәкәрләр дә моңа зур өлеш кертә, – дип сөйләде Луиза ханым.

30нчы елларда кара ат җигелгән тарантаска утырып, авылга драматург Кәрим Тинчурин белән композитор Салих Сәйдәш кайтып төшә. Ул чорда Казанбаш белән Көтек авыллары арасындагы болында су тегермәне була. Яшьләр шунда җыелышып, уеннар уйный торган була. Тинчурин белән Сәйдәш бер атна шунда яшәп, яшьләр белән аралашканнан соң, «Кандыр буе» пьесасы иҗат ителә.

– Безнең авыл янында Өчиле авылы да булган... – дип әңгәмәдәшем сөйли башлагач, мин:

– Тукайның Өчилесеме? – дип бүлдердем.

– Юк, бу Гариф Ахуновның туган авылы. Тукайның Өчилесе Кенәр ягында урнашкан – анысы башка. Гариф Ахуновның авылы 13 йорттан гына торган. Юлы булмаганга, халык әкренләп йә Көтеккә, йә Казанга күченеп киткән. Үткән гасырның 80нче елларында колхозлар, җирләрне сугарабыз, дип, плотина төзегәч, Өчиле су астында кала. Гариф Ахунов безнең мәктәптә укыган бит.

ГЕРОЙЛАР ИСЕМЛЕГЕННӘН СЫЗАЛАР

Габдулла Заһидуллинның бертуган энесе – Габделхәй, әңгәмәдәшем теле белән әйтсәк, чак кына Советлар Союзы Герое булмаган. Габделхәйне Мәскәү тирәсендәге шәһәргә очучылыкка укырга җибәрәләр. Берничә елдан соң ул авылга кайта.

– Сугышта Габделхәй Заһидуллин очучы була, 300дән артык очыш ясый, дошманнарның бик күп объектларын бомбага тотып юкка чыгара. Аңа «Кызыл Йолдыз» ордены бирелә. Үзен дә, аның белән экипажда бергә хезмәт иткән берничә кешене дә Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итәләр. 1945 елның мартында Габделхәй фашистлар территориясенә бомбалар ташлаган вакытта, аның самолеты дошман утына эләгә. Ул, «мин бервакытта да әсирлеккә эләгеп черемәячәкмен» дип, үзенә бомбалар таккан килеш сикерә һәм шартлый. Фашист территориясенә төшкәч, аны таба алмыйлар. Шуңа да Советлар Союзы Герое исемлегеннән сызып аталар, – дип аңлатты музей хезмәткәре.

ТАРИХИ БЕЛЕШМӘ

Авылны урталай бүлеп Казансу ага. Казансуга Киек үр асты елгасы килеп кушыла. Элек авыл тирә-юнендә калын урман булып, анда бүре, аю һәм боланнар яшәгән. Боланнар хәтта кешедән дә курыкмаганнар. Бу елга атамасы киекләргә нисбәттән барлыкка килгән. Тагын Казансуга Аракы чишмә елгасы һәм Акчалы чишмә елгасы килеп ялгана. Авылдан ерак түгел иңкүлектә зур күл булган, анда аюлар еш очраган.

1933 елда авылга бер геолог килеп, бу күлне тикшергән һәм аның төбендә чишмәләр күп булуын, күлнең гади күл түгеллеген әйткән. Янындагы калкулыкта ятып тыңлаганда, җир астында су аккан тавышлар ишетелеп торган.

(Фирдәүс Гарипованың «Авыллар һәм калалар тарихыннан» китабыннан, I том. 2001 ел.)

ТАРИХ КҮЗЛЕГЕННӘН: АКБҮРЕ

Акбүре авылы Яңа Чишмә район үзәгеннән 21 чакрым ераклыкта урнашкан. Авылга әлеге исем 1994 елның июнь аенда бирелә, аңа кадәр ул Татар Волчье дип атала.

«ВОЛЧИЙ БИЛЕТ» КЕМГӘ БИРЕЛГӘН?

Русское Волчье авылына XVIII йөз ахырында нигез салына. Аның исеме шактый сәер яңгырый. Авыл атамасының барлыкка килүенә карата олылар хәтерендә шундый легенда-риваятьләр сакланып калган. Имештер, бу якларда төрле ерткыч җәнлекләр яши торган калын урман булган. «Волчий билет» алган кешеләр, кемнеңдер эзәрлекләвеннән качып, бу якларга килеп чыкканнар, урман кискәннәр, үзләренә нигез корганнар һәм шунда яши башлаганнар. «Волчий билет»лы кешеләр авыл атамасын да шул сүздән алганнар.

«Волчий билет» атамасының икенче мәгънәсе дә бар. Закон бозган кешеләрне төрмәгә утыртмыйча, бирегә гаиләләре, хезмәт кораллары һәм атлары белән сөргәннәр, аларга игенчелек һәм сәүдә белән шөгыльләнергә рөхсәт бирелгән. «Билет»лы кешеләр һәм хөкүмәт өчен бу иң яхшы ысул булган – яңа төбәк үзләштерелгән, дошман һөҗүмнәреннән саклану өчен дә көч җитәрлек булган.

Икенче легендада исә, беренче нигез салынасы урында бүре оясы булган, шуңа күрә булачак авылга шундый исем кушу турында сүз бара.

ЯҢГЫР БОТКАСЫ

Авылда татар, рус һәм чуашлар бергәләшеп яшиләр. Бер урамда татарлар гына торган, аны руслар хәзер дә Татар урамы дип йөртә. XIX йөз башларында татарлар: «Балаларыбыз руслар белән катыша», – дип, аерылып чыгарга уйлыйлар. Татар гаиләсеннән бер кыз рус гаиләсе – Портновларга килен булып төшә. «Венчание» йоласын башкару өчен парларны чиркәүгә алып керәләр. Авылдашлар бу хәлгә нык ярсый һәм руслардан аерылып чыгарга уйлый. Халыкның Русское Волчьедан аерылып чыгу датасы төгәл билгеле түгел, якынча 1825–1852 еллар арасында булгандыр, дип фаразлана. Руслар болын ягын күрсәтәләр, ә татарлар урман ягын сайлыйлар. Агачларны кисеп һәм төпләп, үзләренә йорт салалар. Болар 11 татар гаиләсе, араларында мөселман диненә күчкән бер чуваш гаиләсе була. Шулай итеп, яңа татар авылы барлыкка килә. Ул Татар Волчье дип атала башлый.

Русское Волчье авылы янынннан Волчанка елгасы ага. Елга атамасы да «волк» сүзеннән алынган. 1994 елда, аерылып чыккан авылның атамасы рәсми рәвештә Акбүре дип үзгәртелә. Акбүре исеме белән авылга багышланган җыр да чыгарылган, сүзләрен Роберт Миңнуллин, көен Илгиз Закиров язган.

Авыл янында гына Җитенле суы ага. Халык аны Җитенне дип атый. Элек бу елгада халык җитен чайкаган. Елгасы хәзер бик сай, ә ярлары тирән һәм һаман ашала бара. 2000нче елларда шушы авылдан чыккан Әнвәр Мәхмүт улы Залаков инициативасы белән Җитенле суында заманча плотина төзелә. Ярлары плитә белән түшәлә. Элек ерымнар белән куркыныч хәлгә килгән Җитенледә хәзер юлчылар ял итә, тирә-яктан балыкчылар да шунда килә. Бу тирәдәге кырлар да Җитенле кырлары дип йөртелә. Җитенле тавы дип йөртелгән калкулык та бар. Аны менгәч, Кизләүләр өсте дип аталган урынга барып чыгасың. Җәй көннәре корыга китсә, монда авыл халкы элек яңгыр теләргә барган. Бу йола үзенә күрә бер зур һәм күңелле бәйрәмгә әверелгән. Йола башкарыласы көн алдан билгеләнгән. Авыл халкы өч-дүрт укымышлы әбигә алдан сәдака китергән. Тавык, ярма, ипи, чәй-шикәр, он, бәрәңге һәм башка төрле азык-төлекне билгеләнгән көндә атларга төяп, Кизләүләр өсте янына китергәннәр. Якындагы урманнан утын алып төшкәннәр, учаклар ягылган, тавыклар суелган һәм яңгыр боткасы пешерелгән. Карт-карчыклар, бала-чага, яшүсмерләр кизләүдән су алып, бер-берсенә су сибешкәннәр. Су сибешү авылга кайткач та дәвам иткән, моңа беркем дә ачуланмаган. Бәйрәм «яңгыр боткасы» дип аталган.

КЕМ КЕМНӘН КОТЫЛГАН?

Авылның икенче ягында Баһау бабай елгасы бар. Ул хәзер корыган инде. Аннан ерак түгел Фәткүч күле җәелеп ята, атамасы Фәтхулла исеменнән алынган. Узган гасыр башында су проблемасын хәл итү өчен Фәтхиев фамилияле кеше, авыл халкын җыеп, аларга акча түләп, туфрагын ат арбаларына төятеп күл казыта. Хәзер ул күлнең суы кипкән, урыны гына сакланган.

Авылның көнчыгыш ягында (Кизләүләр өстеннән якын гына) Ключ урманы үсә. Өстән күзәтсәң, ул ачкычка охшаган. Анда хәзер агачлар сирәгәйгән, нефтьчеләр ботарлап бетергәннәр. Шул урман буендагы зур иген басуы Зур алан дип атала. Ключ урманы аша олы юл уза. Элек аннан Күтәмә авылына базарга йөргәннәр. Шуңа ул юл базар юлы дип аталган. Урманның бер аланына халык Балчыклык дип исем кушкан. Бу аланда туфрак ак балчыктан тора. Кешеләр шуны алып кайтып, измәгә кушалар һәм лапас, мунча кебек хуҗалык корылмаларын сылауда кулланалар.

Авылда Түбән оч, Югары оч, Урта урам, Хорти урамы бар. Яңа урамнарның берсе Котылдык дип атала. Совхоз бу урамда яңа йортлар төзи һәм аларны яңа өйләнешкәннәргә бирә. Шуңа күрә шаянрак кешеләр аны мәзәк итеп Котылдык, ягъни кайнана-кайната белән торудан котылдык, дип шаяртып әйткәннәр. Хәзер инде ул урам бер көлкесез Котылдык урамы дип йөртелә.

(Мәгълүмат Фирдәүс Гарипованың «Авыллар һәм калалар тарихыннан» китабыннан (I том, 2001 ел) һәм Акбүре авылындагы «Буыннар мирасы» музее җитәкчесе Вәсил Вәлиуллин сөйләгәннәрдән алынды.)

Авыл уртасындагы Совет күленең исеме элек яр буенда авыл советы урнашканга килеп чыккан

Акбүре авылының көньягында Аккош күле җәелеп ята


Акбүре авылы күренеше

PRESSA.RU

БЕЗ КЫРЫМДА ЭЗЛЕБЕЗ

«Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклоры фестиваленең географиясе елдан-ел киңәя бара. Быелгы фестиваль, исәп буенча тугызынчысы, Кырымның Бахчасарай районында узды. Монда Россиянең 20 субъектыннан җыелган 40тан артык фольклор коллективы катнашты. Шулай ук – Кырым Республикасының вокаль-хореография коллективлары да.

Автор:
Луиза Янсуар

ХАЛЫКАРА ДӘРӘҖӘ, ЯКИ УРТАК БӘЙРӘМ

Татарстан, Әстерхан, Самара, Свердловск, Киров, Түбән Новгород, Омск, Оренбург, Төмән, Ульяновск, Чиләбе, Волгоград, Пенза өлкәләре, Пермь краеннан килгән милләттәшләребез – алар барысы да үз төбәкләренең күркәм гореф-гадәтләрен, җыр-биюләрен тәкъдим итте. Шулай ук Башкортостан, Мордовия, Мари Эл, Удмуртия, Чувашиядә гомер итүче татарлар да килде. «Түгәрәк уен» оештырылганнан бирле алар бу фестивальне калдырмый. Быелгы фестивальдә Бахчасарайның «Авдет» («Кайту») һәм «Эбедиет» («Мәңгелек») ансамбльләре катнашуы да ямь өстенә ямь булды.

Сүз уңаеннан, фестиваль тагын бер елдан 10 яшьлек юбилеен бәйрәм итәчәк.

– Юбилейны башкалабызда уздырырга ниятләп торабыз, – дип белдерде ТРның Традицион мәдәниятне үстерү үзәге җитәкчесе Фәнзилә Җәүһәрова. Дөрес, фестивальнең Гала-концерты вакытында Кырым Республикасының мәдәният министры урынбасары Исмәт Заатов тагын да куанычлырак тәкъдим ясады:

– «Түгәрәк уен»га халыкара статус биреп, аны дүрт елга бер Кырымда уздыра торган итик, – диде ул. – Ул безнең уртак бәйрәмебезгә әверелсен!

Киләчәктә, бәлки, нәкъ менә «Түгәрәк уен»ның җырлы-биюле җыеннары ике арадагы дуслык күперен төзеп бетерергә, ә аннары тагын да яхшырак итеп ныгытырга да ярдәм итәр. Һәрхәлдә, залда утыручы Кырым тамашачысы да, Казаннан килгән делегация вәкилләре дә, «Түгәрәк уен»ның барлык катнашучылары да бу тәкъдимне куәтле алкышларга күмде.

СЕБЕРДӘН КИЛГӘН «ДИНОЗАВРЛАР»

Бахчасарай районының Песчаное бистәсендәге «Бригантина» пансионатына таң беленгәндә килеп урнаштык.

– Диңгез пансионатка терәлеп үк тора, – дип ышандырды оештыручылар. – Вакыт тапсагыз, рәхәтләнеп коенырга була!

Әмма Кырым безне болытлы моңсу күк йөзе, салкын һавасы белән каршы алды.

– Коенып булмас микәнни инде, – дип хафаланып алды килгән халык. Бигрәк тә – балалар һәм... өлкән яшьтәге абзыйлар белән әбиләр пошынды. Әйтергә кирәк, фестивальгә килгән фольклор коллективлары катнашучыларының яше 8 белән 82 арасында тирбәлә.

– Килгән-килгән, коенмый калмабыз инде анысы, без бит Себер егетләре, – дип шаяртып алды Төмәннән килгән гармунчы абзыйлар. – Кырымга, дигәч, аеруча җилкенеп килдек фестивальгә...

Монда Себердән килгән татар коллективлары да бар, керәшеннәр дә, мишәрләр дә. Һәм, әлеге дә баягы агайлар кебек, фестивальдә сигезенче, тугызынчы ел рәттән катнашучы «динозаврлар» да. Шундый «динозаврлар»ның берсе – Төмәннән килгән Җәгъфәр абый Касыймов. Ул «Пышны» ансамбленең җитәкчесе.

– Ә исеме нәрсәне аңлата? – дип сорыйм Җәгъфәр абыйдан.

– Ә, безнең Себер гүзәлебез исеменнән ул, – дип елмая Җәгъфәр абый. – Пышма дип атала торган бик матур елга бар бездә. Моңа кадәр мин «Саз» ансамбле белән катнаша идем «Түгәрәк уен»да, аннары «Пышны»ны оештырдым. Монда безнең гаилә подряды, дисәк тә була. Ансамбльгә йөрүчеләр фольклор материалын да үзләре таба, үзләре өйрәнә дә, костюмнарны да үзләре хәстәрли. Мәдәният йортына карасак та, үзең янып тормасаң, булмый. Дөрес, безгә инструментларны алып бирәләр, бюджеттан күпмедер күләмдә финанслау каралган, монда фестивальгә килергә Бөтендөнья татар конгрессы ярдәм итә... Әмма спонсорлар юк. Бездә әле рухи мәдәниятне үстерү кирәк икәнне аңлаган чын мәгънәсендә зыялы татар меценатлары формалашып җитмәгән.

Фотолар: Луиза Янсуар, Йолдыз Миңнуллина

«БЕЗ ТӨРЛЕ ҺӘМ ШУНЫҢ БЕЛӘН ГОРУРЛАНЫРГА ТИЕШБЕЗ»

«Түгәрәк уен» фестиваленең төп таләпләре – тере башкару, үзенчәлекле, кабатланмас фольклор материалы һәм аның аутентик (чын, халыкчан, эшкәртелмәгән) булуы. Биредә фонограммага җырлау турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Хәзерге фолк юнәлешендә бик популяр булган стилизация дә хупланмый. Коллективлар үз төбәкләреннән алып килгән фольклор материалын борын-борын заманда әби-бабайлары тарафыннан ничек башкарылса, нәкъ шул рәвешле башкарырга тиешләр.

ТРның Традицион мәдәниятне үстерү үзәге белгече, сәнгать фәннәре кандидаты Эльмира Каюмова фестивальгә килүче коллективларның иң «авырткан» урыны шул булуы хакында әйтте:

– Еш кына булган материалны матурайтырга, бизәкләргә тырышалар. Бер-берсеннән күреп, костюмнарда стилизация ясый башлыйлар. Әмма бит безгә матурлык кирәкми, безгә төбәкнең йөзен билгеләүче материал үзе кирәк. Без һәммәбез дә төрле, һәм бу төрлелек – байлыгыбыз, горурлыгыбыз.

Күптән түгел генә ТР Традицион мәдәниятне үстерү үзәге «Татар халкының йолалары һәм аларның сәхнәдә куелышы» дип аталган өр-яңа видеобасма чыгарган. Әлеге җыентыкта Казан, себер, Урал ягы татарларының, керәшен, мишәрләрнең югалып бара торган уникаль гореф-гадәтләре, йолалары тупланган. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: бу материаллар нәкъ менә үзәк оештыра һәм уздыра торган «Түгәрәк уен» белән «Иске Казан» фестивальләрендә төшереп алынган. Басма DVD диск һәм аңа кереш буклет рәвешендә әзерләнгән.

– Буклеттагы мәкалә дә, диск үзе дә фольклор коллективларына ярдәм итү, аларны фольклор материалы белән дөрес эш итәргә өйрәтү йөзеннән эшләнде, – ди Эльмира ханым.

Болар хакында ул фестиваль кысаларында оештырылган мастер-классында да сөйләде. Диск «Түгәрәк уен» фестивалендә катнашучы коллективларга таратылды.

Әлеге үзәк фольклор коллективларына шул рәвешле, кулыннан килгәнчә, ярдәм итәргә тырыша. Ә бит фольклорны тергезү җиңел эшләрдән түгел, үз эченә бик күп аспектларны ала торган хезмәт: экспедицияләргә чыгып, яңа әсәрләр яздыру, борынгы уен коралларын барлау һәм табу, коллектив җитәкчеләре белән өзлексез бәйләнештә тору, репертуар туплау һ.б. Әлеге дә баягы кием сайлау да, Эльмира ханым әйткәнчә, белгечләр тарафыннан контрольдә тотылырга тиеш, чөнки, сүз үзебезнең этник үзенчәлегебезне дөрес иттереп киләсе буыннарга тапшыру турында бара.

ТЫПЫР-ТЫПЫР, ШЫТЫР-ШАТЫР

Фестивальгә килгән коллективлар, чыннан да, төрле – фольклор материалының үзенчәлеге ягыннан да, әзерлек ягыннан да. Шуны да әйтергә кирәк: төбәкләрдә сайлап алу турлары узганнан соң, бирегә инде иң яхшылары җыела.

Нәтиҗә ясар һәм урыннар алыр өчен. Әмма быелгы Кырым фестивале аерылып тора иде – биредә урыннар бирелмәде, ул махсус бәйрәм җыены рәвешендә оештырылды.

Инде үзенчәлекләргә бераз тукталып үтик. Әйтик, шул ук «Пышны» «егетләрен» алыйк. Алар үзләренең гармуннары һәм шул гармун көе астына «аяк тыпырдатуы» белән данлыклы.

– Читекнең төбенә махсус пластина куела, үзенә күрә чечетка инде бу, – дип елмая Җәгъфәр абый.

Мордовиядән килгән катнашучы – 82 яшьлек Нурия Әбделрәшитова – «Түгәрәк уен»ның янә бер «динозавры». Ул «Дуслык» фольклор ансамблендә бәетләр башкара. Репертуарында XVI гасырга караган бәетләр дә бар, ди хәтта.

– Мин аларның тарихын-ниен әллә ни белеп җиткермим инде, балам. Әбиемнән отып алган идем, ул ничек җырласа, мин дә шулай җырлап йөрим, – диде Нурия апа.

Мари Элдан килгән коллективларның берсе гөсләдә уйнап һушландырды.

– Гөсләдә уйнау үз заманында керәшеннәрдә бик киң таралган булган, – ди Эльмира Каюмова. – Аларда уникаль борынгы гөсләләр сакланып калган. Әйтик, быел сез ишеткән ике яклы (ягъни берьюлы ике кеше уйный торган) гөслә – әле өр-яңа табылдык. Моңарчы аның барлыгын да белми идек. Безгә бит инструментларның сызымнарын ясау өчен, менә шушындый уникаль табылдыклар кирәк. Аннары, схемалары билгеле булгач, бәлки, аларны осталар эшли дә алыр. Тик андый осталар да бетеп бара шул, кызганыч.

Бу урында Төмәннән килгән «Шытыр-шатыр» коллективы белән таныштырып узасы килә. Аның җитәкчесе Гаяз Габдуллин һәм аның кечкенә башкаручылары – берничә ел рәттән «Ту-

PRESSA.RU

гәрәк уен» җиңүчеләре, чып-чын йөзек кашлары. Күптән түгел генә бу балалар коллективы Италиядәге фольклор фестивалендә катнашып, андагы тамашачыны да шаккатырып кайткан. Быелгы чыгышлары вакытында «Шытыр-шатыр»лар халыкны янә гаҗәпләндерде – алар үзләре инструментларда уйнап, җырлап-биеп торды, ә барабан өстендә... кәҗә биеде. Ансамбльнең солисты Илүсә Габдуллина безгә бу кәҗәнең серен ачты:

– Әти аны үз куллары белән ясады, – диде ул. – Без аның белән чиратлашып идарә итәбез. Музыканың темпына карап, кәҗәнең сикерү рәвеше дә үзгәрергә тиеш. Әтием бит без уйный торган уен коралларын да үз куллары белән ясый...

– Ясамый нишлисең?! – дип кул гына җәя Гаяз абый. – Борынгы уен коралларының бит сызымнары да сакланып калмаган. Менә, йөрим шулай авыллардагы картларга, сораштырам. Әбиләрдән җырлау манерасына өйрәнәбез, бер авылның башкару рәвеше икенчесенекен кабатламый беркайчан да. Уен коралларын ясау серенә балаларны да төшендерә башладым, алар бу серне үзләреннән соңгы буыннарга тапшырырга тиешләр.

– Теләп өйрәнәләрме? – дип сорыйм Гаяз абыйдан.

– Өйрәтүче булса, өйрәнәләр, – дип кистереп куя Гаяз абый. – Без инде болай да «компьютер буыны» тәрбиялидек бит, ә монда алар үз куллары белән борынгылыкка кагыла ала...

– Уен коралларын нәрсәдән ясыйсыз? – дип төпченәм. – Акча белән кем дә булса ярдәм итәме?

– Мәдәният министрлыгына, Конгресска рәхмәт – менә, йөреп торабыз ич әле фестивальләргә... Ә уен коралларына килгәндә... Алар өчен кем акча түләсен инде. Шөкер, агач бар әле, урманнар бай бездә. Нарат, ат ялы, хайван карыны... – барысы да чиста экологик материалдан хәстәрләнгән, – дип шаяртып, дөресрәге, чеметтереп тә ала Гаяз абый.

«КҮҢЕЛ КУШУЫ БУЕНЧА... »

Фольклор коллективлары алты авылда концерт программасы белән чыгыш ясады. Болар – Почтовое, Угловское, Каштановское, Песчановское, Табачное, Плодовое. Безнең төркем үзенең тәмәке үстерү традицияләре белән данлыклы Табачное авылына барды.

– Элек бездә тәмәке җитештерүнең эре производствосы булган, – дип башлады сүзен җирле үзидарә башлыгы Иван Шаповалов. – Атаклы «тәмәке патшалары» Стамболилар турында ишетә беләсездер шәт. Хәзер инде Кырым тәмәкесенең данлыклы чорлары тарихта гына калды.

Табачное авылы 1925 елда Кырым тикшеренү үзәгенең бер пункты буларак оеша, монда Тәмәке совхозы була, билгеле. Хәзер биредә Тәмәке җитештерү музее эшли. Без килеп кергәндә, Мәдәният сараеның фойесында тәмәке күргәзмәсе оештырылган иде. Әмма тәмәкене инде сату һәм керем алу өчен түгел, ә элеккеге заманнардан килгән уникаль тәҗрибәне югалтмас өчен үстерәләр һәм әзерлиләр. Куакларга патша Россиясе заманыннан ук данлыклы булган, совет чорында да үз маркасын саклап килгән кырым тәмәкәсе сортларын бүләк иттеләр: «Дюбек», «Вирджиния», «Американец»...

– Кырымның Россия составына керүенә бик шатланабыз, – дип тә өстәде Иван Шаповалов. – Яңаруга йөз тоту сизелә башлады. Менә, сез килдегез. Ә җирле халыкның инде 20 еллап читтән килгән артистны күргәне юктыр, чын әйтәм!

Ә үз Мәдәният сарайларында берничә коллектив эшли булып чыкты аларның. Шуларның берсе – Табачное авылының данлыклы тынлы уен кораллары оркестры. Автобуслардан төшеп, Мәдәният йортына таба атлауга, иң беренче эш итеп, аларны ишеттек: хәрби марш, сугыш чоры көйләре... Баксаң, ансамбльнең җитәкчесе диңгез флотында хезмәт иткән булган икән. Аннары мәктәптә математика укыткан. Ә 1976 елда, «күңел кушуы буенча», мәктәп укучыларын җыеп, менә шушы оркестрны оештырып җибәргән. Безне аның гына түгел, ә укучыларның үзләренең дә энтузиазмы сокландырды. Кич буе, таралышырга теләмичә, уйнады да уйнады алар...

Табачное авылының Мәдәният сарае 500 кешегә исәпләнгән. Безнең коллективлар «буш залга җырлап-биеп кайтабыз икән» дип борчылган иде. Ә концерт башлангач, аһ иттек! Зал да тулды, тамашачы да һәр чыгышны тоташ алкышларга күмде. Юкса, Табачноеда яшәүче халык – нигездә, украиннар һәм руслар. Күрәмсең, җыр-бию белән музыканың милләте юк, алар һәркем өчен дә аңлаешлы...

Фестиваль кысаларында Кырым Республикасы хакимияте безнең өчен Корбан ашы оештырды. Исмәгыйль бәй Гаспралы каберен дә зиярәт итеп кайттык. Һәм, әйтерсең, Җәгъфәр абыйның теләген исәптә тотып, мондагы җирле химаячеләр – кырымтатар мәдәниятен үстерүгә ярдәм итәргә әзер торучы эшкуарлар белән дә очрашып сөйләштек.

ВАТАНГА КАЙТУ

– Ә Кырымда чип-чиста кырымтатар авыллары сакланып калганмы? – дип сорыйм Кырым Республикасының Мәдәният министрлыгы вәкиленнән.

– Сез бит тарихны ишетеп булса да беләсез инде... – дип, соравымны ярымҗавапсыз калдыра ул. Хәер, мондый җавап та – җавап.

Шулай да фестиваль кысаларында кырымтатар мәдәнияте буенча мастер-класслар оештырылган иде: кырымтатар биюләренә өйрәтү һәм кырымтатар чигү эшләре буенча. Мине иң кызыксындырганы – чигү буенча мастер-класс булды. Аны «Эвджияр» оешмасыннан килгән оста Халидә Кыпчакова уздырды. («Эвджияр» – кырымтатар теленнән безнеңчәгә күчерсәк, «өй җыю» дигәнне аңлата. – Авт.) Кырымтатар чигешенең символикасы белән таныштырды ул безне: менә монысы тау билгесе, дип, ә монысы сугышны белдерә.

– Чигү ул заманында сакраль сәнгать булган, – ди Халидә ханым. – Әй-

тик, кияүгә чыгар алдыннан кыз бала бирнә әзерләгән. Аның мендәрләренә һәм чаршауларына, әлбәттә инде, ир-ат символларын чигәргә ярамаган...

– Ә ничек аерырга аларны, – дип төпченәбез.

– Бездә, мәсәлән, кипарис агачы – ир-егет символы, шулай ук, үлемне дә гәүдәләндерә. Яшь киленчәкләргә анар агачы һәм җимеше килешәчәк, ул әле уңдырышлылык билгесе дә. Кыз бала, тормышка чыккач, нәселнең дәвамы өчен җаваплы була бит.

Сакраль, дигәннән, Халидә ханым атаклы тәмәке янчыкларының серен дә чиште. Баксаң, алар формасы белән дә, бизәкләре белән дә хатын-кыз сынын гәүдәләндерә икән.

– Ире яу кырына чыгып киткәндә, хатыннар бу формадагы янчыкларны үзләрен хәтерләтеп торсын өчен хәстәрләгән, – дип елмайды ул. – Фотога төшү юк бит әле ул чакта, хәер, рәсем бездә тыелган да, димәк, менә шушындый ысул калган...

Хан сараендагы затлы мендәрләр – Халидә апа һәм аның белән бергә эшләүче осталарның уртак иҗат

җимешләре икән. Алар китапларда сакланып калган борынгы эскизлар буенча әзерләнә, ди.

– Бер мендәргә кайчак тугыз айлап вакыт китә, бәби алып кайткандай булабыз, – дип елмайды Халидә ханым. – Шулай да, шөкер, хәзер заказлар ала башладык. Димәк, киләчәккә өмет бар, дигән сүз.

Гала-концертта кырымтатар вокаль-хореографик ансамбльләренең чыгышларын аеруча дулкынлану белән тыңладым һәм карадым. Грек, төрек, балкан мотивлары көчле яңгыраса да, нәрсәседер белән тарихи хәтерне кузгатты алар – бәлки, Урда чорыннан чәрдәкләнеп җилгә таралган моң-зар беләндер?

«СӨТ БЕЛӘН КЕРГӘННЕ ОНЫТТЫРЫП БУЛМЫЙ!»

Ава Азаматова, «Авдет» кырымтатар ансамбле җитәкчесе:

«Авдет» – гарәп теленнән тәрҗемә итсәк, «ватанга кайту» дигәнне аңлата. Без, депортациядән соң, беләсез инде, ватаныбызга бик озак һәм урау юллар белән әйләнеп кайттык. Миңа, Кырымнан сөрелгәндә, 10 яшь иде. Ниһаять, 1988 елда гаиләбез белән туган җиребезгә – Бахчасарайга әйләнеп кайттык. Мин Бахчасарайның мәдәният йортында эшлим, кырымтатар биюләрен сәхнәләштерәм.

Халык 50 ел буе сөргендә яшәсә дә, авыллардагы әбиләр-бабайлар арасыннан әле традицияләрне саклап калучыларны табарга мөмкин. Мин үзем Краснодар шәһәрендә югары белем алдым – андагы мәдәният институтында хореография бүлегендә укыдым. Аңлашыла инде, кырымтатар биюләренә өйрәтмәделәр безне анда. «Кырым татарлары» дигән халык гомумән юк дип исәпләнә иде бит. Безнең биюләрне әниемнән өйрәндем. Буыннан-буынга килгән күнекмәләр бу. Балаларымны да үзем өйрәтәм.

Безнең мәдәниятне, шөкер, өлешчә Хан сараендагы тупланмалар саклап калды. Анда төрле тарихи чорларга караган эскизлар бар, сәхнә костюмнарын, алардагы орнаментларны, бизәкләрне шулардан өйрәнеп әзерлибез. Мин бу мәсьәләдә бик консерватив кеше, аз гына да чит элемент, стилизация булырга тиеш түгел, дигән карашта торам. Безнең костюмнарда билгә кадәрге өске өлеш тоташ алтыннан булган, ә аскы өлештә алтын элемент кертү, бизәкләр өстәү зәвыксызлык билгесе саналган.

Бию элементларын, җырлау манерасын без авыллардагы кырымтатар туйларына йөреп өйрәндек. Китаплардан укып өйрәнеп булмый бит инде аларны! Кызганыч, миңа Үзбәкстандагы «Хайтарма» кырымтатар ансамблен күрү бәхете насыйп булмады. Шунысы кызык, улыма 1 яшь вакытта, күрәм, бу җилкәләрен сикертә. Нишләп икән, дип аптырыйм. Соңрак белдем: кырымтатар биюләрендә ир-атларның төп хәрәкәтләреннән берсе икән ул! Әнкә сөте белән кергәнне, күрәмсең, хәтердән сызып ташлап булмый...

P.S.
Фестиваль 24 сентябрьдә Симферополь Дәүләт академик музыка театрында тантаналы рәвештә ябылды. Аңа кадәр, төп рәсми программадан тыш, һәр кичне катнашучылар – яше дә, карты да – традицион «Кичке уен»га җыела торган иде. Таңга кадәр диңгез ярында Россиянең төрле төбәкләреннән килгән татарларның, түгәрәккә басып уйнаганда уйнала торган көйләре, җырлары яңгырап торды. Күңелләребез түгәрәкләнеп кайттык!

PRESSA.RU

Авторлар:
Альберт
Нигамаев

Фаяз
Хуҗин

БОРЫНГЫ АЛАБУГА

Алабуга республикабызның Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә яхшы билгеле шәһәрләре исемлегенә керә. Аны мәшһүрләребез – рәссам Иван Шишкин, шагыйрә Марина Цветаева, кавалерист кыз Надежда Дурова, невропатолог Владимир Бехтеревлар танытты.

Соңгы елларда Алабуга республикабыз бюджетына сизелерлек өлеш кертергә сәләтле туристик шәһәргә әверелде. Ул – искиткеч бай тарихлы борынгы кала. Җирле халыкта «Шайтан каласы» дип йөртелгән борынгы тарихи истәлек тә шәһәрнең янәшәсендә үк урнашкан. Галимнәр шәһәр тарихының борынгы чорларын тикшерүне әле XVIII йөздә үк нәкъ менә шул Шайтан каласыннан башлап җибәрәләр.

БЕЗНЕҢ ШӘҺӘРМЕ, ТҮГЕЛМЕ?

Озак еллар буена тарихчылар арасында, Алабуга шәһәренә XVI гасыр урталарында, йә булмаса, шул гасырның икенче яртысында нигез салынган, дигән фикер өстенлек итеп килде. Тарихи энциклопе-



дияләргә дә кертелгән бу фаразда мантыйк бар иде, әлбәттә: нәкъ шул чорда хәзерге Алабуга территориясендә рус авылы һәм каласы барлыкка килә. Ә инде 1614–1616 елларда борынгы болгар каласы урынында Троица ирләр монастыре ачыла.

Әмма узган гасыр урталарында киң таралган, хәтта аксиома дәрәҗәсенә җитә язган яңа фараз тарафдарлары Алабуга тарихын 1780 елдан башлап җибәрергә тәкъдим иттеләр. Хәтта 1980 елда шәһәрнең 200 еллык юбилеен да билгеләп үттеләр. Әлбәттә, бу фаразның да нигезе юк түгел: 1780 елда Екатерина II фәрманы белән волость үзәге булып торган Алабуга шәһәрчеге өяз шәһәренә әверелә һәм чын шәһәр статусын ала.

XVII гасырга караган кайбер чыганакларда әлеге рус авылының исеме Трёхсвятское дип бирелә. Гафу итегез, аңлашылып җитми, дип туктатыр безне игътибарлы укучы. Нишләп соң әле ул шәһәрнең исеме Трёхсвятское түгел, ә Алабуга?

Урынлы сорау. Эш шунда ки, шул вакытка караган архив документларының барысында да диярлек Трёхсвятское авылы һәм Троица монастыре «Алабуга» исеме белән янәшә кулланылган: «Трёхсвятское, тож Елабуга», «село Трёхсвятское, что на Елабуге», «Троицкий каменного городища монастырь, что на Елабуге» һ.б. Ни өчен дисезме? Чөнки Трёхсвятское һәм Троицкий кебек авыл, монастырьлар күп ич Россиядә, шуңа күрә берсен икенчесе белән бутамас өчен, боларның Алабугада урнашканнарын күрсәтә торган булганнар. Ни генә димә, Алабуга бит инде данлыклы кала, үзенең Шайтан каласы белән еракларда мәгълүм.

Шулай икән, Алабуга тарихы Трёхсвятскоега караганда борынгырак булып чыга түгелме соң? Әлбәттә. Әле 1960нчы елларда ук танылган тарихчы Евгений Чернышев тарафыннан төзелгән «Казан ханлыгы чорындагы торак пунктлар исемлеге»нә юкка гына кертелмәгәндер инде ул. Ханлык чорындагы Алабуга халык авыз иҗаты әсәрләрендә дә очрый:

Алабуга – ак шәһәр, тарихы озак яшәр,
Дошманга, яуга бирелмәс, юлына каршы төшәр.
Алабуга урыс кулына Сөгән ханнан калгандыр,
Сөгән ханның маҗарасы тарихта язылгандыр.

Алабуга – болгар шәһәре һәм ул XII йөздә үк барлыкка килгән! Әлеге сенсацион хәбәр 1993 елда Шайтан каласында профессор Альберт Халиков җитәкчелегендәге экспедиция туплаган табылдыкларга нигезләнгән иде. Алабуганың борынгылыгы турындагы яңа хәбәрне галимнәр шикләнебрәк каршы алды. Бигрәк тә Әби патша фәрманына табынган рус туганнарыбыз пошамангa төште. Рус шәһәре бит инде ул Елабуга, чишмә башы – Трёхсвятское, нигә тагын казынып ятарга, янәсе.

Казан кремлендә казу эшләрен башлап җибәреп, башкалабызның тарихын монголларга кадәрге чор белән бәйләрдәй табылдыклар килеп чыга башлагач, без башкачарак фикер йөрттек: Кама аръягында гына түгел, аның бирге ягында да X–XII йөзләргә караган болгар калалары булган икән, димәк, Казанның «яшьтәшләрен» эзләп карарга кирәк.

Алабугадыр, бәлки? Шайтан каласының XII гасырдан сакланып калган таш манарасы хәзерге шәһәрнең борынгылыгына ишарәле кебек.

Шайтан каласы Алабуганың көньяк-көнбатыш читендә, Кама белән Тойма елгасы кушылган җирдә, биеклеге 50–64 метрга җиткән тау башында урнашкан. Табигать тарафыннан яхшы гына ныгытылган булуга карамастан, ясалма саклану корылмалары да бар – җирдән өеп ясалган өч рәт үрләр һәм тирән чокырлар. Кызганыч, начар сакланган борынгы калабыз. Ныгытмаларның беренче һәм икенче рәтләре, культура катламының күп өлеше бөтенләй диярлек җимерелгән (бире дә 1938–1962 елларда ак таш карьеры булган). Болгар чорыннан калган

PRESSA.RU

аталы таш манара шәһәрлекнең көнчыгыш өлешендә урнашкан.

ШАЙТАН КАЛАСЫ СЕРЛӘРЕ

Шайтан каласын һәм ул тирәдәге таш бина хәрабәләрен беренчеләрдән булып 1769 елда штабс-капитан Н.П. Рычков тикшерә. Ул вакытта әле бу бинаның өч манарасы һәм алар арасындагы дивар сакланып калган була. Хәрабәләрне Рычков болгарлар чорыннан калган мәчетнеке дип бәяли.

1820нче елларда шәһәрлектә Казан университеты галимнәре Фёдор Эрдман һәм Николай Кафтанников булып китәләр. Бу вакытта инде әлеге таш корылманың бер генә манарасы калкып торган, калган икесе җимерелеп юкка чыккан. Галимнәр ике катлы манараны рәсемгә төшерәләр, шәһәр ныгытмаларының планын сызалар. 1855 елда тиздән дөньякүләм танылачак яшь рәссам Иван Шишкин Алабугадан чыккан Мәскәү профессоры Капитон Невоструев үтенече буенча сакланып калган ныгытмаларның һәм таш хәрабәләрнең рәсемнәрен ясый.

Шайтан каласы рәссамнең әтисен, Алабуга тарихында якты эз калдырган шәһәр башлыгы Иван Шишкинны да, күптән кызыксындырып килгән. 1867 елда аның тырышлыгы белән борынгы таш бинаның ике катлы манарасы төзекләндерелеп, элекке рәвешендә үк булмаса да, торгызыла. Шул хәлендә әлеге манара – монголларга кадәрге болгарларның безнең көннәргә кадәр килеп җиткән бердәнбер архитектура һәйкәле – һаман да Алабуганың күрке, шәһәрнең үзенчәлекле символы булып, ераклардан ук күренеп тора.

1888 елда Алабуга шәһәрлегенә күренекле рус археологы Александр Спицын килә һәм таш корылма хәрабәләрне үлчи һәм алар янында казу эшләре үткәрә. Бу борынгы бинаның нигезе квадрат формасында булып, почмакларына түгәрәк манаралар утыртып куелган була. Александр Спицын раславынча, әлеге бина XIII гасырдан элегрәк төзелгән һәм ул йә кәрван-сарайның бер өлеше, йә берәр атаклы мөселман «изгесенең» төрбәсе булган. Шушы төрбәне карарга XIV йөз ахырында Аксак Тимер килмәдеме икән әле, дип яза ул, дилетант тарихчыларның чынбарлыктан ерак торган шикле мәгълүматларына таянып. Галимнең тагын бер ачышы шуннан гыйбарәт: үзенең казылмаларында ул элгәреге тимер гасырына, Ананьино чорына караган әйберләр дә таба. Бәлки, өч рәт балчык ныгытмаларның һичьюгы берсе шул чорда ук төзелгәндер?

Узган гасыр урталарында Алабуга шәһәрлеге совет болгар фәненә нигез салган атаклы археолог, профессор Алексей Смирновның да игътибарын җәлеп итә. Шәһәрлектә ул казымый, үзенә кадәр тупланган мәгълүматларны гына өйрәнә. «Әлеге кала борынгы ырулык җәмгыяте чорында, моннан якынча 2600–2700нче еллар элек, хәрби ныгытма буларак төзелгән – ди ул, Спицын материалларына таянып. – Бу җирләргә X–XI гасырларда болгарлар килә һәм алар борынгы кала территориясендә таштан биек манаралары белән яңа корылма – цитадель торгызып куялар». Болгар иленең төньяк чигендә иң мөһим хәрби пункты, крепосте була ул. Алабуга каласыннан болгарлар күрше удмурт кабиләләренә яу чапканнар, аларны феодал бәйлелектә тотканнар, салым түләткәннәр.

1981 елда, Спицын тикшеренүләреннән соң йөз елга якын вакыт үткәч, Алабугада тагын бер археолог, СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәре Морат Кавиев казу эшләре үткәрә. Ул ныгытмаларның икенче рәте болгар чорында төзелгәнен ачыклый, Ананьино (б.э.га кадәр VII–V гасырлар) һәм Имәнкискә кабиләләре (IV–VII гасырлар) белән бәйле катламнарны аерып ала һәм, болгарлар калада даими яшәмәгәннәр, сугыш куркынычы килеп туганда гына качу-саклану урыны буларак файдаланганнар, дигән нәтиҗә ясый.

1993 елда Альфред Халиков Алабуга шәһәрлегендә киң казу эшләре үткәрде. Болгар катламы калын түгел, әмма таш бина хәрабәләре нәкъ шул катлам белән бәйләнгән иде. Нигезе яхшы гына сакланган: һәр як стенасының озынлыгы 21 метр, почмакларда диаметры 6 метрга җитә торган түгәрәк манаралар. Бүгенге көнгә кадәр сакланган манараның гына диаметры зуррак – 10 метр чамасы. Күрәсең, бу манарада бинага керү өчен ишек тә булган. Бинаның тагын бер кызыклы һәм әлегә аңлашылып җитми торган үзенчәлеге бар: өч якның стеналары уртасында ярымтүгәрәк, ә дүртенчесендә өчпочмаклы манаралар. Нигә кирәк булган алар? Шунысы да әһәмиятле: бина өчпочмаклы манара ягы белән төп-төгәл кыйблага карап тора. Шуңа күрә дә Альфред Халиков аны мәчет дип атады. Бер үк вакытта ул кечкенә крепость ролен дә үтәгәндер, мөгаен. Төзелү вакыты XII гасырның икенче яртысы дип фаразлана, әмма тагын да борынгырак булуы мөмкин.

Казылмалардан искитәрлек әйберләр чыкмады, барысы да гадәти табылдыклар, әмма алар арасында Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорына караганнары да аз түгел. Шуның белән кыйммәтле алар.

АЧЫШЛАР, ТАБЫШМАКЛАР

1994 елдан башлап биредә Алабуга дәүләт педагогика университеты галимнәре эшләде. Кала ныгытмаларыннан 130 метр чамасы читтәрәк культура катламының җимерелгән участокларын чистартканда археологлар хатын-кыз каберенә юлыктылар. Сакланып калган әйберләр арасында көмештән эшләнгән чигә алкасы һәм шалтыравык асма бизәк чылбыры бар иде. Чигә алкасы X–XI гасырларда Идел Болгарында, ә асма бизәкләр борынгы удмуртларда һәм угыр халыкларында бик еш очрый торган әйберләрдән санала. Табылдыкларны угырлар археологиясе буенча зур белгеч Евгений Казаковка күрсәттек.

– Бу каберлек X гасыр ахырында Урал якларыннан Кама буйлап күченеп килгән угырларныкы, – диде ул. – Угыр телле халыкларга хантлар, мансилар һәм венгр-мажарлар керә. Биредә, һичшиксез, бер мажар кызы күмелгән.

Бу фикер белән килештек. Болар инде шактый гына төркиләшкән угырлар, дип кенә өстәмәкче булабыз. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, Алабуга шәһәрлегендә тупланган табылдыкларның яртысыннан артыгракы шушы угырларга карый.

Угырлар артыннан ук биргә болгарлар килеп төпләнә. Бу вакытта Болгар дәүләте күзгә күренеп ны-

гый, чикләрен төньякка һәм дә көнчыгышка таба киңәйтә, яңа җирләр үзләштерә, күрше фин халыклары (мари, удмурт, комиларның борынгы бабалары) белән сәүдә, икътисадый мөнәсәбәтләрен җайга сала. Болгарлар Алабуга каласында туктапып калалар. Бар яктан да уңайлы урын була ул: табигать тарафыннан яхшы ук ныгытылган, сәүдә итү өчен янәшәдә генә су юлы, тирә-юньдә бай көтүлекләр, урманнар...

Нәкъ шулай, Калатауда эзләре бар болгарларның, хәтта таш мәчетләре дә шунда, тик йортларын, каралты-кураларын һаман таба алмыйбыз. Кайда яшәгән соң ул борынгы Алабуга халкы? Хәзерге Алабуганың элгәресе, чишмә башы дип санап буламы соң тау башындагы бу каланы? Бераз шикле.

Әлеге табышмакны да әкренләп чиштек.

Әле 1911 елда ук хәзерге Алабуганың үзәгендә, иске шәһәрдә, кечкенә бер хәзинә табылган. Бүгенге көндә ул дәүләт Эрмитажында саклана. Бу хәзинәдә дүрт көмеш алка, 17 көмеш гривна (борынгы акчалар) һәм өстенә алтын йөгертелгән төймә була. Табылдыклар XI–XIII гасырларга карый. Очраклы гына күмелмәгәндер ул, дип уйладык, бистә халкы яшәгәндер биредә.

Шәһәрнең иске өлешендә, Спас һәм Покров чиркәүләре арасында археологик тикшеренүләр үткәрергә кирәк, дигән карар кабул ителде.

1997 елдан башлап, Олы Покрау урамында казу эшләре үткәрелде. Культура катламы Казан кремлендәге кебек артык калын булмаса да, болгар-татар (XIV–XVI гасырның беренче яртысы) һәм болгар (X–XIII гасыр башлары) чорында тупланганнарын аерып алырга мөмкин булды. Борынгы катламнардан чыккан табылдыкларның яртысыннан артыгы болгарларныкы түгел, ә хәзерге Пермь якларында яшәгән фин-угырларныкы. Ә мөнә мәетләрен алар мөселман йоласы буенча күмгәннәр.

Табылдыклар коллекциясенә тагын бер тапкыр күз төшерик: төрле асылташлардан һәм пыяладан ясалган муенса төймәләре, бакырдан эшләнгән беләзек, үрдәк рәвешле асма бизәк, тимер кайчы, пычаклар, ачкыч-йозаклар, ук очлары, орчыкбашлар һ.б. Соңгырак катламнан Үзбәк хан идарә иткән чорда (1312–1342 еллар) сугылган бакыр тәңкә чыкты. Ат фигурасы кебек эшләнгән бронза йозак бик кызыклы. Мондый йозакларны монголларга кадәр Биләр осталары ханәләрендә ясаганнар.

КАБЕРЛЕКЛӘР НИ СӨЙЛИ?

Борынгы Алабуга территориясендә урнашкан зират Тукай урамындагы бер шәхси йортның яшелчә бакчасында чокыр казыганда табыла. Унбишләп муенса төймәсе, көмештән ясалган чигә алкасы, ватылмыйча сакланган болгар чүлмәге ише табылдыклар турындагы хәбәрне ишетүгә, археологлар йорт хуҗасы янына килеп җитә, матур гына сөйләшеп, үгетләп, әллә нинди юллар-ысуллар табып, археологик казу эшләренә рөхсәт ала.

Алабуганың яшен ачыклауда әлеге казылмалар хәлиткеч роль уйнады дисәк тә артык булмастыр. Биредә дүрт кабер ачыла. Аларның беренчесендә 20–30 яшьләрдәге хатын-кыз күмелгән. Баш янына болгар кувшины куелган, кулбашы тирәсендә муенса төймәләре сибелгән, шунда ук – көмештән ясалган чигә алкасы. Скелетның күкрәк өлешендә ике ягына вак кына чылбырлар белән шалтырама шарчыклар беркетелгән колак чистарткыч ята. Уң кулының терсәге янына тимер пычак куйганнар. Санап кителгән табылдыкларның датасы X гасырның ахыры – XI гасыр башы белән билгеләнә.

Икенче кабердә тәртипсез рәвештә аунап яткан кеше сөякләре, шул исәптән 16–18 яшьлек кызның баш сөяге, каеш аелы, пычак, чүлмәк ватыклары табылды. Монголларга кадәрге болгар чорында күмелгән, кайчандыр таланган кабер.

Өченче кабердә 16–20 яшьлек хатын-кыз мөселман йоласына туры китереп күмелгән. Агач табуттан дүрт кадак кына сакланган. Башка әйберләр юк.

Дүртенче кабер дә начар сакланган, скелеттан калган бер-ике сөяк кенә аунап ята. Табылдыклардан бер тоткалы чүлмәк һәм шалтырамалы асма бизәктән башка әйбер юк иде.

Әлеге зират X гасыр ахырында барлыкка килә. XII гасырга кадәр күмгәннәр, дип уйларга җирлек бар. Әмма бу саф болгар зираты түгел. Мәҗүсилектән мөселманлыкка күчеп, болгарлаша баручы угырлар яисә финнар җирләнгән булса кирәк.

Казылмаларда табылган әйберләрне, һәм иң әһәмиятлесе, борынгы йорт һәм хуҗалык корылмалары калдыкларын өйрәнеп, без Алабуганың X гасыр ахырында, йә булмаса XI гасыр башында барлыкка килгәнлеге һәм шул вакыттан башлап шәһәрнең бөрөзлексез – Алтын Урда, Казан ханлыгы чорында һәм соңрак та яшәп килүе турында мөһим нәтиҗә ясадык. Әлеге нәтиҗә Татарстан Фәннәр академиясе президиумы һәм Россия Фәннәр академиясе галимнәре тарафыннан расланды.

XI гасыр башлары (1006–1026 еллар) – Болгар илендә мәшһүр Ибраһим хан хакимлек иткән чор. Икътисадның һәм мәдәниятнең гөрләп чәчәк ата башлау, Казан һәм Алабугадан башка Кирмән, Кашан, Ашлы, Җукәтау, Чаллы кебек күпсанлы шәһәр-калаларга нигез салынган чор. Борынгы Алабуга каласы урнашкан биек тау башына куелган болгар әмире Ибраһим бине Мөхәммәт һәйкәле – халкыбыз хәтерендә данлыклы бабаларыбызның истәлеген мәңгеләштерүче бер символ ул.

Михаил Кирсанов фотолары



PRESSA.RU

КАБЕРЕН ДӘ... КАДЕРЕН ДӘ БЕЛ

Казанның Яңа бистә зиратындагы йөзләгән каберне пыр туздырганнар! Бу хәбәр сентябрь башында яшен тизлеге белән таралып, шул арада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка да барып иреште. Вандалларны бүгенге көнгәчә тота алмадылар. Аларны күрүче дә, белүче дә юк. Югыйсә, хәбәр салган кешегә биш миллион сумлык премия дә вәгъдә ителде... Яңа бистә һәм башка зиратларда мондый җинаять кабатланмас, дип беркем дә вәгъдә бирә алмый. Республика каберстаннарында бернинди саклык чаралары күрелмәгән.

Автор:
Линар Закиров

Яңа Татар бистәсендәге зират 250 ел элек, бистә белән бер вакытта барлыкка килгән. Мәйданы – 26 гектар. Габдулла Тукай белән Салих Сәйдәшевтән кала, биредә скульптор, рәссам Бакый Урманче, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани, язучы Әмирхан Еники, композиторлар Җәүдәт Фәйзи, Сара Садыйкова, җырчы Хәйдәр Бигичев һ.б җирләнгән.

СОЛДАТ СУРӘТЕН ӨЛЕШЛӘП ҖЫЙГАННАР

Яңа бистә зиратына теләсә кем үтеп керепп, теләсә нәрсә кылана ала, видеокүзәтү камералары төп капкалар янында гына тора. Вандаллар зиратның капкасы бикләнми торган икенче урыннан үтеп кергән, дигән фараз бар. Туздырылган каберләр тирәсендә Габдулла Тукайныкы да урнашкан, әмма аңа бер зыян да килмәгән. Аның каравы, Салих Сәйдәшевнең кабер ташы, урыныннан кузгалып, бер почмагы кителеп төшкән, дигән хәбәр таралды. Казанның Башкарма комитетында әйтүләренчә, ул хәл вандаллар һөҗүменә кадәр үк булган.

Иң күп зыян бишенче һәм сигезенче аллеядагы кабер ташларына китерелгән. Әйтик, яшь хәрби хезмәткәрнең чәрдәкләнгән сурәтен өлешләп җыйганнар. Аударылган ташларны зират хезмәткәрләре күтәртеп куйган. Башкаланың ритуаль хезмәтләрне оештыру идарәсе башлыгы Марат Ишкин сүзләренчә, җимерелгән каберләрне аларның хуҗалары тәртипкә китерергә тиеш.

Шул ук вакытта Татарстанның Диния нәзарәтендә атаклы татар дин әһелләре һәм җәмәгать эшлеклеләренең каберләрен өйрәнү һәм саклау буенча махсус төркем төзелгән. Мөфтияттә революциягә кадәрге чордан бүгенге көнгә кадәр Яңа бистә зиратында җирләнгән барлык имамнарның исемнәре теркәлгән энциклопедия эшләнә.

Казан Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисе Искәндәр Гыйниятуллин хәбәр иткәнчә, 99 кабернең 14е төзәтелмәслек хәлгә китерелгән, җинаятьчеләр үз кыланмышлары белән 700 мең сумлык зыян салганнар.

БАШКАЛА ЗИРАТЛАРЫ ШЫПЛАП ТУЛГАН

Каберстаннарны «куллары кычытып торучылар»дан саклау өчен видеокүзәтү камералары урнаштырырга кирәк, дигән фикерләр дә яңгырады. Татарстан Дәүләт Советында бу мәсьәлә каралып, тиешле карар Казан Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык идарәсенә җибәрелгән. Әмма ритуаль хезмәтләрне оештыру идарәсендә безгә әйтүләренчә, Башкарма комитетка Дәүләт Советыннан бернинди запрос та килмәгән. Күрәсең, хатны «Россия почтасы» белән җибәргәннәр...

Зиратларда югары дәрәҗәдә куркынычсызлык системасын булдыру өчен, күпме камера таләп ителә дигән сорауга, «һәрберсенә 24 камера таләп ителә» дигән җавап алдык. Бу мәсьәлә Казандагы Арча зираты мисалында өйрәнелгән.

– Камералар каберләрне һәм ташларны вандаллардан саклый алмый, әмма җинаять очракларын ачыклауда ярдәм итә ала. Моннан тыш, камералар вандалларны каберләрне мәсхәрә итүдән тыеп торырга да мөмкин. Барлык зиратларны тәүлек буе сакчылар белән тәэмин итү бик күп чыгымнар сорый, – диделәр безгә Казан Башкарма комитетында.

Башкалада 319,6 гектар мәйданны колачлаган 34 зират бар. 2015 елда аларны тәртиптә тотуга 12 миллион 972 мең сум чамасы бүлеп бирелгән. Чагыштыру өчен: 2014 елда – 16 миллион 103 мең сум, 2016 елда – 15 миллион 920 мең сум (соңгы аукцион нәтиҗәләре буенча берникадәр кимергә дә мөмкин.)

Башкаланың барлык зиратлары шыплап тулган диярлек, 1-5 процент кына буш урын калган. Ә мөселман һәм «Юдино» каберстаннарында урын җитәрлек әле. Бүгенге көндә М-7 «Волга» юлының 824нче километрында 77,76 гектар мәйданда ике җәмәгать зиратын оештыру буенча эш алып барыла.



Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU

ЧИРӘМНЕ ТИГЕЗЛИЛӘР, ЯФРАКЛАРНЫ СЕБЕРӘЛӘР

Вандаллык очрагыннан соң, Яңа бистә зиратына мемориаль статусы бирү кирәклеге турында да фикерләр яңгырады. Бирү-бирмәү мәсьәләсе Казанның Башкарма комитетыннан тора. Ритуаль хезмәтләрне оештыру идарәсендә әйтүләренчә, «мемориаль» диган статус зиратка бер өстәмә мөмкинлек тә бирми, шул исәптән финанслау ягыннан да. Казанда бер генә мемориаль зират бар, ул Н. Ершов урамында, төгәлрәге, М. Горький паркы биләмәсендә урнашкан.

Без башта Яңа бистә, аннары мемориаль зиратны да барып карадык. Горький паркында безне биек матур капкалар каршы алды, өске бер җиренә «Мемориаль зиратка керү сәгатьләре: 8.00 дән 16.00 гә кадәр. Сишәмбе-шимбә» диган билге эленгән. Зиратта ниләр тыелганы язылган, әйтик, «мәрхүм булганнарның истәлеген каралту һәм аларның каберләрен зиярәт кылырга килүчеләрнең хисләрен рәнҗетү», «чәчәкләрне өзү, кәс алу, учак ягу», «роликларда, скейтта, велосипедта, мопедта, мотоциклда, самокатта йөрү», «йорт хайваннарын йөртү һәм аларны күмү». Эчкә кереп, күпмедер ара узгач, беренче булып шагыйрь Һади Такташ, атаклы актер, режиссер Габдулла Камал I, ТАССР министры Зия Габделманов һ.б. лар каберләре күзгә чалынып китә. Монда очраклы кеше юк, һәркем дә республика үсешенә зур өлеш керткән шәхес.

Зираттагы чисталыкка һәм матурлыкка таң калдык. Эшчеләр ямь-яшел газонны махсус җайланма белән тигезлиләр, саргаеп төшкән өрәңге яфракларын себерәләр. Кыскасы, тирә-якта чисталык. Кызганыч, Яңа бистә зираты андый пөхтәлек белән мактана алмый. Ара-тирә чүп контейнерлары торса да, алар бик шыксыз күренә. Мемориаль зираттагы яктырткычларга видеокүзәтү камералары да урнаштырылган.

КАБЕРНЕ ИНТЕРНЕТ АША ТӘРТИПТӘ ТОТУ

Казанда каберләрне тәртиптә тоту буенча түләүле сервис эшли. Мәгълүмати технологияләр һәм элемтә идарәсе башлыгы Рифат Ханнанов әйтүенчә, әлеге сайт күп мөмкинлекләр бирә. Үлгән кешенең якын кешесе, акча түләп, кабергә билгеле бер көнне чәчәк салуларын, шулай ук аны ел әйләнәсе карап торуларын: чүптән арындыруларын, чардуганны буяуларын сорарга мөмкин. Эш башкарылганнан соң, хисап рәвешендә фото җибәрелә.

Моннан тыш, cemetery.kzn.ru адресы буенча бердәм реестр эшли, кемнең кайда җирләнгәне хакында мәгълүмат табарга була. Анда 1980 елдан 13 зиратта күмелгән 160 мең кеше буенча белешмә бар. Бу ике идеяне Казан мэры Илсур Метшин да хуплады.

– Хәрби хезмәт, эш буенча яшәү урынын алыштырып, чит төбәкләргә, илләргә китүчеләр күп. Бу уңай күренеш – дөнья һәркемгә ачык. Андый кешеләрнең бердәнбер теләге – туганнарының каберләрен карау, әмма һәр яз-көз килеп йөрергә мөмкинлекләре юк. Үзеңне дә, тарихыңны да хөрмәт итү йөзеннән бу рухи яктан бик әһәмиятле проект, – диде шәһәр башлыгы.

Ритуаль хезмәтләр күрсәтү идарәсенә, яңа системаның халыкта ни дәрәҗәдә кызыксындыру тудырганын, кайсы илләрдән мөрәҗәгать итүләрен сорап, хат юлладык. Ике атна буе көткән җавап хатында шушы сорауларга, ахыр чиктә, «Андый мәгълүмат юк» дип кенә язылган.

P.S. Соңгы мәртәбә Казанда вандаллык очрагы 2012 елда Арча зиратында кылынган иде. Җинаятьчеләрне шул ук елда тотып, хөкем иттеләр. Яңа бистә зиратына кизәнгән җинаятьчеләр тиешле җәзасын алыр, диган өмет бар. Үлгәннәрнең каберен генә түгел, кадерен да белергә кирәк.



Туган-тумачаларының каберләрен чистартырга килгән кешеләргә без бер генә сорау бирдек: «Зиратларны вандаллардан ничек сакларга?»

Илдар Җәләлетдинов
– Арча зиратын ничек телиләр, шулай пыран-заран китерәләр. Хәзер инде монда да килеп җиттеләр. Җинаятьчеләрне, совет чорындагы кебек, бөтен кеше алдында хөкем итсәләр, файдасы булыр иде. Шушы эшне кылган кешеләрне, һичшиксез, тотачаклар. Биш миллион сум күләмендә премия дә вәгъдә ителде бит. Әгәр моны балигълык яшенә җитмәүчеләр эшләгән булса, аларны шартлы рәвештә хөкем итеп, ирекка җибәрәчәкләр. Аларга берни дә булмаячак. Әйтте диярсез. Зиратның һәр почмагында сакчы куйсаң да, мәгънәсе булмаячак. Видеокамераларның файдасы, бәлки, булыр да иде. Яңа бистә зиратында әтием, әнием һәм ике абыем җирләнгән. Моңа кадәр биредә тыныч иде, шундый хәл килеп чыга алыр, дип башыма да китермәдем.
Рус, яһүд, хәзер инде мөселман зиратына кизәнәләр. Бу хулиганлык кына түгел, берәрсенең заказы буенча эшләнгәндер, дип уйлыйм, татарлар белән русларны бер-берсенә каршы котыртыр өчен. Мәрхүмнәрнең каберләре кемгә комачау итә? Дошманың нинди генә булса да, ул бит инде бакыйлыкка күчкән.

Флюра Мәхмүтова
– Бу хайваннан да явызрак кешеләр эше. Каберләрнең туздырылганын ишеткәч, ике дә уйламый килеп җиттек. Безнең туганнарга тимәгәннәр, алар моннан читтәрәк – макарон фабрикасы тирәсендәрәк урнашкан. Бу хәлгә бик каты хәсрәтләндек. Үлгән кешенең ни гаебе бар?! Шушы җинаятьне кылган кешеләрнең дә үләсе бар бит, әллә алар дөньяга гомерлеккә дип килгәнме? Бу безнең төп йортыбыз, аны хөрмәт итәргә кирәк. Бернинди саклык чаралары да ярдәм итмәстер, Аллаһ Тәгаләгә генә ышанабыз.

Тамара Гыйльфанова
– Әти-әниебез Салих Сәйдәшев кабере янында 1956 елда, композитор вафатыннан соң берничә ел үткәч җир куенына иңдерелде. Шунысы сәер: кемдер каберләргә элэнгән яхшы калын чылбырларны салдыра, плитәләр да юкка чыга. Видеокүзәтү камералары куйсалар, тынычрак булыр иде шул.

Хәлимә Байбекова
– Без Яңа бистә зиратына елына ике мәртәбә – язын һәм көзен киләбез. 27нче аллеяда 1987 елда – әнием, 1972 елда әтием җирләнгән. Каберләренә тигәннәре юк. Моңарчы вандалларның зиратыбызга килеп, шундый эшләр кылганын ишеткәнебез булмады.

Камил Сәмигуллин, Татарстан мөфтие:

– Мондый мәсхәрә кылучыларның безнең арада яшәвенә ышану да авыр. Бу хәлнең килеп чыгуы барыбыз өчен дә шомлы билге. Бер караганда, үз бабаларының хәтерен, гасырдан-гасырга күчеп бара торган әхлак кыйммәтләрен саклаучы җәмгыятьтә мондый вакыйганың булуы мөмкин түгел. Димәк, уйланырга җирлек бар.

Феофан, Татарстан һәм Казан митрополиты:

– Бу эшне иманга бернинди кагылышы булмаган кешеләр башкарган кебек тоела. Бу варварлык галәмәте җәмгыятебезгә – хөкүмәткә, хокук саклау, дини органнарга нәрсәдер эшләргә кирәклеге турында сигнал. Мондый күренешләрне булдырмас өчен, тиешле дәрәҗәдә дини белем бирергә кирәк. Моны эшләмәгән очракта, теләсә нинди яман агымга кереп китә ала торган гарип рухлы кешеләр үсеп чыгачак.

PRESSA.RU

СӘҮДӘГӘРЛӘРНЕҢ СОҢГЫ СӘЛАМЕ

Казан сәүдәгәрләренең иске йортлары әкренләп юкка чыга бара. Алар яңа Казанның контекстына туры килми шул. Өсләренә заманча затлы йортлар ябырыла. Кысрыклый, урыннарыннан куа. Мөгаен, моңа фәлсәфи карарга кирәктер.

Озын гомерле бу йортларның кайберләрен әле Волков, Низенькая, Овражная, Ульянов-Ленин урамнарында, берән-сәрән урнашканнарын исә шәһәрнең тагын берничә җирендә очратып була. Кайчандыр алардан йомычка, майлы буяу исе килгән. Сәүдәгәрләр гөрләтеп өй туе үткәргән, үзләреннән алда мәчеләрен керткән. Хәзер исә бу йортлардан сөрсегән ис килә.

Әлбәттә, бер-ике йортны саклап калып булыр иде. Ремонтлап, музей, сувенирлар кибете, кафе ачарга мөмкин, тик алардагы элекке тормышны инде барыбер кайтарып булмаячак... Верандаларында самовар төтенләп утырган, ресторациягә рессорлы пролеткага утырып чыккан, киенеп-ясанып, күпсанлы гаилә белән чиркәүгә яки мәчеткә барган вакытларны...

Әмма миңа бәхет елмайды. Мин бу йортларда яшәүчеләрне, элекке тормышны хәтерләүчеләрне, соңгы могиканнарны күреп калдым әле!

Автор:
Гадел Хәеров

СӘҮДӘГӘР КЫЗЫ

Бервакыт мине әнием үзе карый торган әби янына алып барды. Ул аның авырып киткән дус хатынының туганы иде ахры. Дарулар, ризык илтергә кирәк иде. Һәм менә без җәяүләп Тихомирнов урамындагы йортыбыздан Щаповкага таба барабыз – ара ерак түгел, тик караңгы төшкән һәм урам бушап калган инде. Эш шунда, бу көннәрдә телевизордан беренче совет «сериалын» – «Семнадцать мгновений весны» картинасын күрсәтә башладылар. Мин ул чакта сирәк кешедә генә булган телевизорларның тәрәзәләрдә чагылган «зәңгәр утларына» карап барам. Бездә «Темп-3» бар иде, һәм телевизордан нинди дә булса кызыклы тапшыру башланса, диварга шакып, бабай күршеләрне чакыра. Кайвакыт безнең өй «кинозалына» җидешәр кеше кереп тула.

Минем, әле бәләкәй булгангамы, әлеге фильмга әллә ни исем киткәндә, шунлыктан әнием әйткән «дворянка» янына бик теләп киттем. Чынлыкта «дворянка» сәүдәгәр кызы булып чыкты, аның әтисенең зур җимеш бакчалы, ике катлы йорты Эрмитаж бакчасы каршында урнашкан иде.

Без капкадан ишегалдына кердек, почмактан кызыл күзләре белән безне күзәткән караңгы шыгырдавык баскыч буйлап өскә күтәрелдек. Әллә җен баласы карап тора инде?! Калын ишекне шакыдык. Телевизордан аерганга ачуы чыккан хатын килеп ачты һәм, безнең Варвара Ивановна янына килүебезне белгәч, бармагы белән почмакка төртеп күрсәтте дә, йөгереп кереп тә китте.

Мамык мендәрле тимер карават һәм борынгы кәнәфи көчкә-көчкә сыйган кечкенә бүлмәдә бу йортның элекке хуҗасының кызы яши икән. Әнием ризыкны төргәкләрне ачты, сөлгегә төргән кәстрүлдәге тавыкны хуҗабикә алдына куйды. Кухняга чыгып, чәйнекне кайнатып керде. Һәм менә кайнар чәй эчеп җылынган карчык үзенең тормышы турында сөйли башлады. Бер дә күңелле булмаган аның язмышы. Революция вакытында өйләренә солдатлар бәреп кергән дә, әтисен, аның энесен, үзләренә ниндидер мәсьәләне хәл итәргә дип кергән идарәчене Эрмитаж бакчасындагы чокыр янына алып чыгып атканнар. Әнисе шуннан соң мантымаган, ярты елдан җан тәслим кылган. Өйдәге хезмәтчеләр үзләренең чоланнарыннан сәүдәгәр гаиләсе яшәгән бүлмәләргә күченгән, җиһазларны да, хуҗаларының шәхси әйберләрен дә үзләштергәннәр. Җыелыш үткәреп, 17 яшьлек Варвараны пешекче бүлмәсенә күчерергә карар кылганнар. Безгә ишек ачкан хатын әнә шул пешекченең оныгы икән.

Минем саргайган обойлы диварга элеп куелган, рамкалары тәмам каралып беткән иске фоторәсемнәрне кызыксынып каравымны күргәч, карчык аларда сурәтләнгән кешеләр турында сөйли башлады. Әти-әнисе, түтиләре, туганнан туган абыйлары, бәләкәй Варя үзе. Караваттагы ике кечкенә мендәргә чигелгән Гагарин һәм Терешкова, елмаеп, сәүдәгәрләр гаиләсенә карап тора.

Бакчадан эт шыңшуы ишетелә. Шулчак карчык минем башымнан сыйпады да: «Киткәндә, аңа тавык сөякләрен ташларсың, яме? Тарас кушаматлы ул. Мин аның белән тәрәзә аша сөйләшәм. Аны беркем дә ашатмый. Ачлыктан ул инде алма кимерә башлады», – диде.

Сәүдәгәр кызы бакчада гаиләләре белән рәхәтләнеп чәй эчүләрен искә төшерде. Зур корсаклы самовардан, җиде төрле җиләктән һәм әстерхан чикләвегеннән әнисе ясаган кайнат-

Автор фотолары

PRESSA.RU

ма белән. Чәй пешергәндә, карлыган яфрагы салганнар. Эре яфраклы чәйне колониаль лавкадан үлчәтеп ала торган булганнар. Элек мич ягучы булган Миша дәдәй революциядән соң калган запасларны тәмәке урынына тартып бетергән – ул чакта нәрсә тартырга белми аптыраганнар. Баздагы җиләк-җимеш төнәтмәләре белән яңа хуҗалар кыш буена сыйланган.

Гадәттә Варвараның әнисе якшәмбе саен җәен балыгы, йомырка һәм дөгедән зур бәлеш сала торган булган, чәй эчәргә алма яки кура җиләге белән татлы бөккәннәр пешергәннәр. Әбисе исән чакта йөземле, баллы күмәч пешереп сыйлый торган булган.

Мин карчыкны игътибар белән тыңламадым. Аның сөйләгәннәрен дә өзек-өзек кенә хәтерлим. Ул йортта мин башка булмадым. Киткәндә, Тараска сөяк ыргыттым. Чылбыры шалтырады. Эт, үзенчә миңа рәхмәт әйтептер инде, өреп куйды.

Сирәк кенә бу урамнан үткәндә, сәүдәгәр йорты урынындагы күзгә дә ташланмаслык яңа өйгә карап китәм. Варвара Ивановнаның арыган тавышын искә төшерәм. Ерак ул кичтә, моңланып, борынгы романсның һаман бер юлын кабатлаган иде: «Прошли года, повсюду льются слезы...» Соңрак мин бу романсны эзләп таптым. Менә ул:

Прошли лета, и всюду льются слезы...
Нет ни страны, ни тех,
кто жил в стране...
Как хороши, как свежи ныне розы
Воспоминаний о минувшем дне!

ТЫЙНАК КНЯЗЬ

1991 елның ноябре иде. Бер редакциядән шалтыратып, авырып киткән корреспондентны алыштыруымны үтенделәр. Адрес яздырдылар. «Интервью алыгыз. Анда князь яши», – диделәр. «Нинди князь инде ул тагын? Алар бармыни әле?» – дип уйлап куйдым мин.

Адрес язылган кәгазьгә карый-карый барам. Пушкин урамындагы Тукай һәйкәле каршындагы ишегалдында революциягә кадәр төзелгән иске йорт тора. Шалтыратам. Бусагада бик әдәпле, илтифатлы карт пәйда була, «Борис Сергеевич Хованский», дип үзе белән таныштыра һәм керергә өнди. Тар баскыч буйлап икенче катка, тәрәзәләре бакчага караган, хуҗаның үзе кебек кечкенә фатирга күтәреләбез. Ул бу йорт турында бөтен нәрсәне белә, үз фатирына килеп кергәнче үк, үзе беренче катта яшәп, икенче каттагы бүлмәләрне вакытлыча яшәүчеләргә биреп торган сәүдәгәрнең фамилиясен атап өлгерә. Аның Кабан күлендә су коену өчен махсус ясалган түләүле корылмалары һәм трактирлары да булуы турында сөйли.

Борис Сергеевич аңлатуынча, әтисенең үз йорты булмаган, шуңа акча түләп кеше фатирында торган. Шул вакытлардан бирле Борис биредә яши икән.

Ул шыпырт кына сөйли, картның ишарәләре һәм мимикасы бик тыныч. Мин аның кулларына карыйм – алар пөхтә, тырнакларына кадәр каралган. Князь!

Бүлмәдә бернинди зиннәт тә юк. Тәрәзә төбендә бакыр шәмдәл ямансулап утыра. Диварда – Хованскийларның борынгы бөек бабасы, Литва князе Гедиминасның корал тоттырып, шлем кидертеп ясалган кечкенә портреты.

Сөйләшкәндә Борис Сергеевичны «элекке князь» дип атавыма ул йомшак кына каршы төште: «Нишләп элекке булсын? Мин хәзер дә князь... Мин бит үз Ватанымда яшәп калдым, аннан ваз кичмәдем. Әнә, эмиграциягә киткәннәрне «элекке» дип атап була. Ә мин ничек Казанда яшәсәм, биредә үк үләчәкмен дә».

Князь Совет властеннан яшеренмәгән. Эшкә кергәндә тутырыла торган анкеталардагы «чыгышыгыз» графасына Борис Сергеевич һәрвакыт «дворяннардан» дип яза торган булган. Мондый чиктән тыш оятсызлыктан соң аны хәтта ата да алмаганнар. Куллары күтәрелмәгән!

– Ә нигә яшеренергә миңа? Карак түгел бит мин! – дип ихластан гаҗәпләнә князь. – Аңлагыз, ул мизгелдә миңа мәңгелектән бөтен бабаларым карап тора лабаса! Алар бит титуллы шәхесләр генә түгел, эшләре белән Россияне данга күмгән затлар да! Һәм күңелем түрендә мин кайчан да булса тарихка караш үзгәрәчәгенә инанып яшәдем.

Ул киштәдән «Бәрхет китапны» («Общий гербовник Всероссийской империи») сузып алды, анда Россиядәге бөтен күренекле нәселләрнең шәҗәрәсен табып була. Борынгылык һәм аксөяклек буенча беренче урында Багратионнар нәселе тора, икенче урында – Хованскийлар, өченче урында – Голицыннар...

«Родъ Князей Хованскихъ происходитъ отъ Гедемина, Великого Князя Литовскаго. Сей Гедеминъ происшелъ отъ Великаго Князя Владимира Святославовича, который крести Русскую землю...»

Борис Сергеевич үзенең бөтен атаклы бабаларын яттан белә: князь Пожарский, Петр I вакытында финанс министры Шафиров, Бородино сугышы каһарманы генерал Николай Николаевич Хованскийның портреты Эрмитаждагы 1812 елгы Ватан сугышы залында саклана, декабристлар Тургеневлар һәм Ивашёв, язучы Алексей Толстой... Ул шулай ук патша Алексей Михайлович вакытында Казан воеводасы булган Иван Никитич Хованскийны да телгә алды.

Сүз уңаеннан, М.Мусоргскийның атаклы «Хованщина» операсы нәкъ менә аның борынгы бабалары турында.

Борис Сергеевич үзенең патша гаиләсенә тәкъдим ителүен дә яхшы хәтерли. Бу тулы бер ритуал була. Бориска җиде яшь тулгач, Казан Ратушасына чакыру килә, билгеләнгән сәгатькә әти-әнисе белән баралар. Анда 1915 елда Казанга бөек княгиня Елизавета Федоровна Романова килү хөрмәтенә бал оештырылган була. Борисны княгиня янына алып киләләр, ул аның белән сөйләшә, башыннан сыйпап куя. Поднос күтәргән лакей килеп баскач, княгиня малайны җир җиләкле пирожное белән сыйлый. Ул шуннан аларның нәрсә әйтергә теләгәнен аңлап кала, янәсе, «син хәзер безнеке, без сине Россия империясенең бөек нәселләре кочагына алабыз, киләчәктә үзеңне лаеклы тотарга тырыш».

– Титул бернинди өстенлек тә бирми иде, – ди князь. – Мөгаен, бу Петр I дән үк башлангандыр, чөнки ул, борынгы нәселләрне санга сукмыйча, җәмгыятьтә лаеклы урын алу өчен һәркеменең үзенең тырышуын таләп иткән. Титул өстәмә бурычлар да йөкләгәндер әле, чөнки аксөяк нәсел вәкиленең кылган гамәлләре һәрвакыт күз алдында булган.

Революциядән соң гаиләдәге борынгы бизәнү әйберләрен һәм көмеш савыт-сабаны ашамлыкка алыштырырга туры килгән. Князь Хованский киез итек басу фабрикасына эшкә урнашкан. Яхшы эшләгән өчен князьгә хәтта мактау грамотасы да биргәннәр әле!

Пенсиягә чыккач, Борис Сергеевич бакчачылык белән мавыккан. Аның өч сутый җирендә төрле сортлы алмагачлар җимеш биргән. Ул шулар белән мәш килгән, үсентеләрне күршеләренә дә өләшкән.

Бервакыт, кәрзин тулы алма белән өенә кайтканда, князь урамда егылган. Һаман каядыр ашыгучы кешеләрнең аяк астына сибелгән алтын төсендәге ранет алмалары арасында бакыйлыкка күчкән.

ТУКТАЛГАН СӘГАТЬЛЕ ЙОРТ

Яңа таш йортлар арасына кереп кысылган бу сәүдәгәр өе Айвазовский урамында хәзер дә тора әле. Ничектер бик сәер буялган. Иске капка өстенә учреждениенең гаять зур элмә тактасын менгереп куйганнар. Монда минем бер танышым фатирда тора иде. Бу – 1990 нчы еллар уртасы. Көз. Вакыт каралткан йортны беренче кар бәйрәмчә бизәгән – ул ап-ак булып болдырда, баскычларда, тәрәзә йөзлекләрендә, капка баганаларында ята. Болдыр янында үскән өрәңге салкында яуган яңгырдан соң бөтенләй бозланган. Бәллүрдәй тора! Өй кыегында исә уклары күгәргән сәгать циферблаты агарып күренә.

Бу ике катлы йорт асылташлар һәм сәгатьләр белән сәүдә итүче Петр Ионович Климовныкы булган икән. Александр Пассажында сәүдәгәр үз кибетен тоткан. Һәм өй кыегындагы сәгать үзенә күрә бер реклама булган.

Хуҗабикә аралашучан булып чыкты, иптәшем җыенганчы, без аның белән бераз сөйләшергә дә өлгердек.

– Өй кыегындагы сәгатегез матур, – дидем. – Кызганыч, йөрми генә!

– Ә мин әле аның һәр сәгать саен сукканын хәтерлим. Хуҗасы, Петр Ионович, театр ярата иде. Һәм сәгать операдан ниндидер көй уйный. Та-та-та… – Карчык көйләп күрсәтмәкче була. – Мин әле бәләкәй идем. Әни белән апа исә аларга хуҗалыкта булыша. Биредә бит зур хуҗалык иде. Ишегалдында теплицалар, кар базы, алма бакчасы, кареталар лапасы… Әллә нәрсәләр бар иде. Кер юу йорты да аерым. Хуҗага ашарга әзерли торган мич аерым йортта, янгын-фәлән чыга калса дип шулай төзелгән… Хәтерлим әле хуҗаны, мәһабәт ир-ат! Коеп куйган сәүдәгәр инде менә! Жилет кесәсендә дә, пиджагында да – чылбырлы алтын сәгатьләр. Без, кызлар, кышын сәүдәгәр бакчасы кырыендагы җылы итеп ягылган йортка җыелабыз да, җеп эрлибез, кул эшләре белән шөгыльләнәбез, халык җырларын сузабыз. Ул исә шыпырт кына керә дә, тыңлап тора. Үзеннән хуш ис килә. Иртәләрен хушбуй белән юына. Затлы тәмәке тарта, «Благоуханный» дигәнен. Һәм менә концертыбызга рәхмәт йөзеннән ул безне алма һәм сидр белән сыйлый. Раштуага унар тиен акча һәм шоколад конфет бирә. Аны хәзергә кадәр хөрмәт итәм һәм рәхмәт хисе белән искә алам. Революциядән соң исә безнең барин югалды. Большевиклар Парижга куган икән, дип сөйләделәр. Анда таксист булып эшләгән. Казанны бик сагынган: «Өйгә кайтасым килә, урам себерергә дә ризалашыр идем», – дия торган булган.

Петропавел соборы манарасына «Казан сәүдәгәре Петр Климов яңа сәгать куйган (искесенең циферблаты гына калган булган), ак таш һәм алебастрдан ясалган бизәкләре реставрацияләнгән».

Мин урыны-урыны белән ватылмый калган мозаикалы паркет идәнне карап сокландым. Аннары дустым миңа чоландагы «Берндорф Металь-варен Артур Крупп» келәймәле ватык чуен унитазны күрсәтте һәм болай диде: «Хуҗасын куып чыгаргач, бу йортка пролетариат кереп утырган. Кайсыдыр, исергәч, кувалда алган да, әлеге «буржуйлар калдыгын» бәреп ваткан. Ишегалдында агач бәдрәф әмәлләгәннәр. Менә шулай, картлач, яшәешне аң тудыра! Хәзергә кадәр урта гасыр кешеләре кебек яшәп ятабыз менә».

PRESSA.RU

«АХЫРГАЧА БАРАМ...»

13 октябрьдә Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык шагыйре Мөдәррис Әгъләмгә 70 яшь тулган булыр иде. Юбилее уңаеннан, укучыларыбызга аның төрле елларда иҗат ителгән бер шәлкем шигырьләрен тәкъдим итәбез.

МИН ТАБЫШМАК ЧИШӘМ

Яралганмын кара туфрагымнан,
Идел-судан, халык җырларыннан;
Ак яулыклы татар карчыгының
Яргаланып беткән кулларыннан.

Яралганмын әнкәм көлтә итеп
Бәйләр өчен җыйган учмалардан;
Көлтәләрдән учма булып кына
Безгә килеп җиткән кыйссалардан.

Яралганмын җил-давыллар узып
Исән калган агач башларыннан;
Чиркәүләргә нигез булып яткан
Бабамнарның кабер ташларыннан.

Яралганмын халык иҗат иткән
Табышмактан, әйе, табышмактан...
Әткәм хыялланып эзләп йөргән,
Җавап итеп әнкәм мине тапкан.

Тапкан табышмакка җавап итеп, -
Шулай тапкан әткәм эзләгәнен...
Тик барыбер бер табышмак булып
Калган минем һәрбер күзәнәгем.

«Үзе атлап йөрсен, дөнья күрсен» –
Еллар минем аяк-кулны чишкән;
«Тапкырлыкның татлы тәмен белсен» –
Туган халкым сөйләр телем чишкән.

...Яралганмын кара туфрагымнан,
Идел-судан, халык җырларыннан;
Хәзер инде дөнья, чишәр өчен,
Үз алдыма табышмаклар куйган.

Мин дә җавап эзлим әткәм кебек,
Мин табышмак чишәм нәселемә.
Аяк-кулын вакыт чишәр аның,
Сөйләр телен кемнәр чишәр менә...

Мин табышмак чишәм нәселемә.

ЧАПТАР БУЛЫП...

Кешелекне бизгәк тотар иде,
Җир сөйләсә әгәр үз кайгысын;
Безнең җанда җир хәстәре диләр,
Чынлап шулаймы соң?
Чынлап шулаймы соң?

Һәрбер адәм изге җир өстендә
Үзенә куыш сайлый, уңайлысын...
Бабам җире, диеп, кычкыралар,
Чынлап шулаймы соң?
Чынлап шулаймы соң?

Бәгъремне телгән әрнүләрне
Туган җирдән аккан елга юсын...
Әткәм елгасы, дип, кычкыралар,
Чынлап шулаймы соң?
Чынлап шулаймы соң?

Әйткән сүзем – күктә шушы кояш,
Биргән антым – күктә шул ай булсын,
Бу безнең җәй, бу безнең кыш, диләр;
Чынлап шулаймы соң?
Чынлап шулаймы соң?

Юлда кара тузан уйнаганда,
Ак чаптарлар көтә үз бәйгесен...
Чаптар булып бер үк җөмләм чаба:
«Чынлап шулаймы соң?
Чынлап шулаймы соң?»

Халыкларны бизгәк тотар иде,
Ил сөйләсә әгәр үз кайгысын.

ЯРСУ

Толпар бирегез миңа,
Бирегез көмеш йөгән...
Улмы хыянәт иткән,
Улмы ятларны сөйгән?

Толпар бирегез миңа,
Тамсын мәхәббәт яше.
Өзелсен өзәңгеләр
Үзәгем өзелгәнче.

Толпар бирегез миңа,
Кыйссалар буйлап чабыйм;
Үземнең сөюемә
Тиң булган сөю табыйм.

Толпар бирегез миңа,
Бирегез яхшы ияр...
Өметем, калма миннән,
Син минем белән ияр!

Толпар бирегез миңа,
Бер чабыйк томырылып....
Йөрәктәге кайгылар
Калганчы умырылып.

Толпар бирегез миңа!
Кешеләр,
Ник дәшмисез?
Мәхәббәтне аңларга
Әллә артык картмы сез?
Әллә артык яшьме сез?!..

***

Күп нәрсаләр якын булып китәр,
Күп нәрсәдән але бизелер...
Азмы җырлар яздым синдә, Казан,
Гомерем дә синдә өзелер.

Сезнең хакта әле минем
Сөйләр сүзем бетмәде;
Өрегез, әйдә, өрегез,
Казанымның этләре!

Койма өстенә менеп тә,
Капка астыннан кереп тә;
Өрегез, әйдә, өрегез,
Ялгышымны күреп тә.

Ялгышасыз – үз кеше дип,
Кемдер чәбә дисә дә...
Өрегез, әйдә, өрегез,
Белеп тә, белмичә дә.

Өрегез, әйдә, тик сезгә
Мәхәббәтем нык минем.
Тукай гүре туфрагында
Дошманнарым юк минем.

СОҢГЫ ЧИКТӘ

Ахыргача!
Ахыргача барам.
Үз язмышым үз язмышын табар.
Бал кортлары әнә соңгы чиктә
Канатлары тузып капланалар.

Ахыргача!
Ахыргача барам.
Җырланмаган җырым кирәк әле.
Былбыллар да әнә соңгы чиктә
Туктап кала, ярылып йөрәкләре.

Ахыргача!
Ахыргача барам –
Юк, калмады көчне саклар чама,
Чорлар аша хәбәр китерергә
Янып егылачак атлар чаба.

Яңа гасыр әнә капка ача –
Ахыргача барам,
Ахыргача!

ХӨРМӘТ ИТӘМ

Хөрмәт итәм дусларымны,
Гел үзгәреп торсалар да;
Хөрмәт итәм, кайчак күңел
Кайтарырлык булсалар да.

Хөрмәт итәм сөйгән ярны,
Сөйгән ярны ярату аз;
Әгәр хөрмәт булмый икән –
Тигез күреп яратылмас.

Хөрмәт итәм үземне дә,
Сөеп йөргән кыз баланы;
Кыз баланың газиз җаны
Әллә шуңа кузгаламы?

Хөрмәт итәм сабыйларны,
Әзер торам тезләнергә;
Үземне саф күрер өчен
Карыйм сабый күзләренә.

Хөрмәт итәм өлкәннәрне,
Тик теләмим баш ияргә;
Баш болай да иелә ул
Баш ирдәй кешеләргә.

КИТӘ АЛМЫЙМ...

Л...гә

Без йөзәбез... Дөнья ап-ак күбек.
Без йөзәбез менә шашкан кебек,
Безгә тәкъдир язган бөтен ләззәт
Бергә килеп, баштан ашкан кебек.
Мин китәргә тиеш таңга чаклы,
Ә бу кичә кабатланачакмы?
Кабатланачакмы бу кичә –
Китә алмыйм шуны белмичә.

Тирбәләбез, бу җир безгә бишек.
Юк, ул көймә... Без барабыз ишеп.
Кеше кулы койган матурлыклар
Безнең белән бара тирбәлешеп.
Бездән соң да шулай барачакмы?
Бу диварлар мәңге калачакмы? –
Меңләп сорау, меңләп уй кичә...
Китә алмыйм шуны белмичә.

Бездән соңгы буын кемчә сөйләр?
Яңгырармы анда безнең көйләр?
Кабатланачакмы шушы кичтә
Без ант эчкән татлы бу тәгъбирләр?
Безнең дәвам шулай яначакмы?
Арып-талып уйга талачакмы? –
Китә алмам, дөнья:
– Юк, – дисә,
Китә алмыйм шуны белмичә.

Илләр бәхетенә җиткән хәтле
Саклармы җир затлы хакыйкатьне,
Ялган матурлыкка төрмичә? –
Китә алмыйм шуны белмичә.
Меңләп сорау, меңләп уй кичә...

...Киләчәккә бара алмый кеше,
Бара алмый шуны белмичә.

PRESSA.RU



КҮБРӘК ТОРМЫШЛАРНЫ ЯШИ АЛЫР ӨЧЕН...

Әзерләде:
Луиза Янсуар

Әдәбият буенча быелгы Нобель бүләген музыкант, автор-башкаручы, соңгы биш дистә ел эчендә дөнья рок-музыкасында культ дәрәҗәсендә йөргән шәхес – Боб Диланның алуы аның иҗатына мөкиббән күпләр өчен – сөенеч, иҗатын яратса да, әдәби кумирларының бу мәртәбәле бүләктән кабат мәхрүм калуларына күңелләре төшкән икенче берәүләр өчен көенеч булды. Яшерен-батырын түгел, мин Харуки Мураками уема китереп, бераз гына борын салындырып алдым. Ә аннары, бу арада машинамда да, плеерымда да туктаусыз яңгыраган үзәк өзгеч авыз гармуны аһәңе тәэсирендә, музыка өлкәсендә кайнашкан дусларымнан, танышларымнан белешергә булдым: алар нинди әдәбиятка өстенлек бирәләр икән?

1	2	3	4	5	6	7
Балачак, үсмер чорымда иң көчле тәэсир иткән китап?	Иң яраткан китапларым?	Нинди китаплар күңелемне кайтарды?	Хәзер нәрсә укыйм?	Кәгазь китапмы, электрон версияме?	Сезгә укырга тәкъдим итәм...	Китап минем тормышымда нинди урын алып тора?



«Без – «Обломов»лар»

Ания Фәйзрахманова, Juna төркеменең солисты, музыкант:
1. Балачакта иң тәэсир иткән китаплар – маҗаралар һәм хайваннар турындагы әсәрләр иде. Жюль Верн, Жак-Ив Кусто, Джеральд Даррелл, пиратлар турындагы китаплар, Көнчыгыш әкиятләре. Бу китапларда дөньяда ниләр барлыгы турында да бик күп мәгълүмат тупланган иде: физикадан башлап, җәмгыятьнең ни белән яшәвенә кадәр. Мин аларны нигездә җәйләрен дачада укый идем, авантюр холкымны дөрләтеп җибәрергә җитә кала иде ул китаплар! Соңрак миндә дә, бик күпләрдәге кебек үк, «Поттер чире» булып алды. Поттердан соң, аның Россия базарында таралган аналоглары – Таня Гроттер, Мефодий Буслаевлар чоры. Ара-тирә болар арасына Лев Толстойның «Война и мир» исемле «кирпече» дә кереп чыккалады.



Ул мине мавыктырса да, бар тирәнлегенә төшеп җитә алмавымны тоемлый идемме шунда – жанры тарта үзенә, ә асылы... кала.
2. Рэй Брэдбери. «Октябрьская страна» җыентыгы. Аның дөньялары стандарт кагыйдәләрне җимерә алуы белән җәлеп итә. Аларга «керәсең» дә, үзеңне ниндидер кызыклы вакыйгаларның, мажараларның бер өлеше итеп хис итә башлыйсың, чынбарлыкта да шуларның параллельләрен эзлисең. Иван Гончаровның «Обломов» әсәре. Мин аны көч-хәл белән укып чыктым, шундый эчпошыргыч булып тоелган иде беренче укыганда. Ә аннары, кайта-кайта укый башлагач, гаҗәеп кызыклы була башлады – нәкъ үзең турында язылганны укыйсың бит! Ул китаптан соң, яшәү гадирәк һәм җиңелрәк булып тоела башлый, җиңел сулап куясың. Адәм затының камил түгеллеген аңлыйсың да, бу тойгы белән дә яшәргә мөмкин булуына төшенәсең. Үзеңне аклап, кулыңны төшерәсең дигән сүз түгел бу, ә шул камиллеккә ирешү юнәлешендә һәр көн эшләргә дә, эшләргә кирәк икәнлегенә инанасың. Шул ук тема Кафкада һәм Достоевскийда да дәвам итә – «Процесс»та, «Преступление и наказание»да.
3. Күңел кайткан китабым юк әлегә. Мин бит күңелем кайтыр дәрәҗәдә күп укымыйм! Китапны, гадәттә, беренче битләреннән үк ошамаса, укымыйм, һәм аңа кире кайтмыйм гына.
4. Тревор Бейкерның «Том Йорк в Radiohead и соло» китабын тагын бер кат укып чыгарга булдым.
5. Ничек тә ярый, әллә ни зур әһәмият бирмим.
6. Балалар өчен – Жюль Вернны һәм Джеральд Дарреллны. Иҗатында авыр чор кичергән, үз-үзенә ышанмаганрак талантларга Леонид Тишковны укырга киңәш итәм. Бер тамчы сәләтең дә булмаган килеш, ничек итеп даһи рәссамга әверелергә мөмкин соравына җавап табар өчен генә булса да.
7. Сиңа бирелгән тормыш кысаларыннан чыгып, күбрәк тормышларны яшәп карый алу мөмкинлеге.

«Үз-үзең белән бергә-бер калу ысулы»

Рәдиф Кашапов, автор-башкаручы, музыкант:
1. Маҗаралы романнар – Сабатинидан алып Крапивинга кадәр. Соңрак кулыма башка төр китаплар керә башлады – Кафка, Сартр, Бёлль. Мин аларны 12–14 яшемдә үзләштерә башладым, ләкин хәзер уйлыйм – бу дөрес булмагандыр, мөгаен. Иртәрәк булгандыр. Шуларны укый башлаган чордан бирле әсәр каһарманының аңында сюжетлылык булуын яратам.
2. Сэлинджер. Хәтеремә бик яхшы уелып калган: диванда ятам, тирә-юньдә ниндидер ыгы-зыгы, янә кер юуу белән мәшгульләр, ә мин «Ловец»ны (турыдан-туры тәрҗемә итсәк – «Ловец над хлебным полем», бездә ул «Над пропастью во ржи» дигән вариантта күбрәк таралган. – Авт.) 20нче тапкыр укып чыгып маташам. Аннары мин Сэлинджерның барлык әсәрләре дә кергән зур бер томлыгын сатып алдым. Хикәяләр, ә аннары зуррак та әсәрләр яза башлавыма, нигездә, ул сәбәпче булды. Рус язучыларыннан Достоевский үз миңа – күпсүзлелеге, шик-шөбһәләр белән мыжлап торган булуы һәм диваналыкның рухи биеклеккә алып менә торган төрен сурәтли белүе белән җәлеп итә, ахры. Татар язучыларыннан – Аяз Гыйләҗев. Хәзер менә «Качак» әсәрен укыйм. Өстәлдәге иң затлы ризык шикелле бу әсәр минем өчен.
3. Китап киштәбездә рәт-рәт булып тезелеп торган төрледән-төрле чит ил язучыларының әсәрләре – классика – мине беркайчан да җәлеп итмәде. Диккенс, мәсәлән, юкса мин хәтта «Домби и сын» әсәрен дә ихластан укып чыгарга тырыштым. Тагын... никтер «Доктор Живаго» тәэсирләндермәде. Мин шагыйрь Пастернакның чын мәгънәсендә фанаты, ә монда... Ул миңа авторның сюжет уйдырмаларыннан ясалма рәвештә җыелган озын-озак хикәяләве булып кына тоелды.
4. Хәзерге вакытта The Smits «There Is a Light And It Never Goes Out» төркеменең биографиясен оригиналда укыйм. Музыкаль төркемнәрне шулай өйрәнергә яратам – еш кына иҗатларыннан башлап та түгел, ә биографияләренә күмелеп. Шулай иткәндә, аларның музыкасын да көчлерәк ярата башлыйсың.
5. Кайсы да ярый. Ридер ватылгач, мин хәтта телефоннан укып йөри башладым. Достоевскийны 2 гә 3 сантиметрлы тәрәзчектән үзләштердем, мәсәлән...
6. Ю Нёсбе детективларын. Алардан соң, минем яңадан салкын-төксез Ослога әйләнеп кайтасым килде. Ул нәкъ Нёсбе сурәтләгәнчә – ачык йөз белән каршыламаса да, ымсындыра, сихерле...
7. Мөгаен, үзем яза башлаганчы һәм музыка иҗат итәргә керешкәнче, ул минем иң зур коткаручым булгандыр. Мин мөмкин булган барлык китапханәләргә язылган идем. Кайда нәрсә күрсәм, шуңа ябыша идем. Хәзер, безне мәгълүмат ташкыны басып китеп, дулкыны астында калдыргач, китап үз-үзең белән бергә-бер калу ысулына әйләнде бугай.







«Әкиятләр – балалар өчен түгел»

Миләүшә Хәйруллина, композитор, музыкант:
1. Балачагым әкиятләр белән истә калган – халык әкиятләре дә бар анда, авторлар тарафыннан язылганнары да. Иң кадерлеләре, мөгаен, Һанс Христиан Андерсен белән Оскар Уайльд әкиятләре булгандыр. Алар бит, асылда, балалар өчен түгел, моңсу, катлаулы өлкәннәр дөньясы турында ул әсәрләр. Хәзер дә кайта-кайта укыйм шуларны. Үсә төшкәч, Эрих Мария Ремаркның «Три товарища» әсәре тетрәндерде, Тамара Смирнова-Карпинскаяның «Вера Горская» романы, Алексин хикәяләре һәм повестьлары зур тәэсир ясады. Аларда күңелнең әллә кайсы төпкелләренә үтеп керә торган тормышчан дөреслек тә, сагыш та бар, сүз белән генә аңлатып та бетереп булмый...
2. Югарыда санап чыккан китаплар. Тагын: Джек Лондонның «Мартин Иден»ы, О. Генри новеллалары, Чеховның хикәяләре, Лев Толстой әсәрләре.
3. Андый күңелсезлеккә әлегә юлыкканым булмады.
4. Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр»ен укый башладым, менә. Соңгы арада аның турында бик күп сүз булды. Моңарчы укыганым юк иде.
5. Басма китаплар күбрәк ошый, шулардан укырга тырышам.
6. Оскар Уайльдның «De Profundis» дип аталган тәүбәсен һәм күбрәк әкиятләр укырга киңәш итәм.
7. Китап минем өчен – аңга тәэсир итеп, хисләрне киеренкелеккә китереп, нәрсәгәдер төшенү мөмкинлеге.

«Безнең белән нинди көчләр идарә итә?»

Зөлфия Камалова, автор-башкаручы, музыкант:
1. Студент чагымда «Студенческий меридиан» журналын яздыра идем. Анда Игорь Акимов белән Виктор Клименконың «О мальчике, который умел летать, или Путь к свободе» дигән әсәрен бастыра башладылар. Ул сәләтле кешеләрнең шул сәләт белән ничек идарә итүе турындагы әсәр иде. Ә минем бик тә иҗат дөньясына кереп китәсем килә. Менә шул әсәрнең тәэсире көчле булгандыр, дип уйлыйм.
2. Минемчә, нәрсәгә өстенлек бирүең яшь белән үзгәрә бара. Хәзер мин нигездә нон-фикшн укыйм. Эзотерика, фәнни-популяр әдәбият, вакыты-вакыты белән магик реализм жанрына караган әсәрләрне. Аерым атаганда, болар: Михаил Булгаковның «Мастер и Маргарита»сы, Милорад Павичның «Хазарский словарь», Джулия Камеронның «Путь художника»сы. Әле яңарак ошатып укыганнарым – Виктор Пелевинның «Любовь к трем цукербринам», Дэйвид Иглманның «Мозг», Роберт Ланцның «Биоцентризм», Манкусо һәм Виоланың «Brilliant Green» китаплары, соңгысы үсемлекләрнең аңлы булуы турында. Миңа заманның алдынгы фикерләрен күзәтеп бару кызыклы, кеше аңы, галәм аңы, табигать белән рух арасындагы бәйләнешләр хакындагы китаплар җәлеп итә.
3. Күңел кайткан очраклар турында әйтә алмыйм, гадәттә, алар онытыла бит.
4. Мин һәрвакыт берничә китапны берьюлы укыйм. Хәзерге вакытта болар – Пелевинның «Лампа Мафусаила» романы, Александерның «Джаз физики», Кастанеданың «Путешествие в Икстлан», Джорданиянең «Почему люди поют» китаплары.
5. Төрлечә була. Электрон версия сәяхәтләр вакытында уңайлы, йә булмаса, тиз кирәк булганда.
6. Чыгышы белән Япониядән булган Америка язучысы Рут Озеки китабын. «Моя рыба будет жить» дип атала ул. Тагын – Александр Маккол-Смитның «Воскресный философский клуб» китабы бик җиңел һәм мавыктыргыч.
7. Мине кызыксындырган сорауларга җавап табу чыганагы. Нейролингвистика, баш мие эшчәнлеге, космология – болар миңа кызыклы. Уйландыра торган китапларны яратам. Кеше яшәеше, дөньяның асылы, без, кешеләр, белән нинди көчләр идарә итүе, үзебезнең нинди булуыбыз турындагы китапларны – андыйларга юлыксам, кайта-кайта укыйм.

МАХСУС ПРОЕКТ

— 16нчы чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

PRESSA.RU

КМҖБ: ЯҢА ВАКЫТ, НЫКЛЫ ТРАДИЦИЯЛӘР

Россиядә иң эре авиация һәм машина төзү предприятиеләренең берсе үзенең 85 еллыгын билгеләп үтә.

«Казан моторлар җитештерү берләшмәсе» АҖ үзенең традицияләренә сакчыл карый, һәм бу легендар оешмага, базар таләп иткән продукцияне чыгара торып, туктаусыз камилләшергә комачауламый.

Оешманың елъязмасы ерак 1931 елда Воронеж шәһәрендә башланып китә. Заводны сугыш елларында Казанның 27нче моторлар төзү заводы мәйданына эвакуацияләлиләр. КМҖБнең юбилей датасы уңаеннан без журнал укучылар өчен предприятие турында – тарихыннан башлап, бүгенге көнгә кадәр – иң кызыклы фактларны җыйдык.

Сугыш елларында җыелган двигатель завод конвейерыннан һәр 50 минут саен төшеп торган.

Казан моторлары легендар Пе-2 бомбардировщикларын һәм ЯК-3 самолет-истребительләрен һавага күтәргән. Сугыш чорында барысы 18 меңнән артык мотор эшләп чыгарылган! Ә бит фронтка киткән ирләр урынына станоклар янына яшүсмерләр һәм хатын-кызлар баскан, ашау, йокы һәрвакыт җитмәгән, өстәвенә, даими рәвештә яралы сугышчылар өчен кан да тапшырып торганнар.

Заводның тәҗрибә-конструкторлык бюросында Валентин Глушко белән Сергей Королёв илебезнең сыеклыкта эшләүче беренче реактив двигателен – илдәге бөтен реактив техниканың элгәренә әверелачәк РД-1не булдыру өстендә эшләгәннәр.

Баш конструкторның очу сынаулары буенча урынбасары булган Сергей Королёв бу двигательне сынауда шәхсән үзе катнашкан. Заводта эшләү Королёвны ракеталар белән шөгыльләнә башларга инандырган. Казанда аның кулы белән баллистик ракеталар проекты өчен эшләнгән сызымнар һәм исәпләүләр сакланып калган.

РД-1не ясау киләчәктә гигант темплар белән үсеп китәчәк реактив техника чоры башлануга нигез салган – завод тиз арада двигательләрнең төрле модельләрен чыгаруны үзләштерүгә керешкән.

Илдә пассажирларны ташу күләменең яртысы диярлек Казанда җитештерелгән двигатель куелган самолетларда башкарылган.

КМҖБндә илебезнең иң яхшы самолетлары – МиГ-9, Як-23, МиГ-15, Ту-16, Ил-62, Ту-154, Ил-86, Ил-96, Ту-204, Ан-70, Ту-324, Як-48 өчен двигательләр җитештерелгән.

АМ-3 турбореактив двигателе илебез авиациясендә искиткеч зур роль уйнаган. Ул иң көчле реактив двигатель булган. Ул Ту-16 һәм Ту-104 самолётларына урнаштырылган. Ә бит нәкъ менә Ту-104 белән тизлек һәм йөк күтәрүдә 26 тапкыр дөнья рекорды куелган.

Россиядә газ транспорты агымнарының 30%ы диярлек КМҖБндә җитештерелгән двигательләр ярдәмендә тормышка ашырыла.

1980нче еллар башында КМҖБ төзелеп килүче Уренгой – Помары – Ужгород магистраль газүткәргеченә газ суырту агрегатлары өчен НК-16СТ газ-турбина двигателен үзләштерүгә керешә. Шулай итеп чит ил җитештерүчеләреннән бәйлелек юкка чыгарыла.

КМҖБнең яңа буын газ-турбина двигательләре экология, ягулыкның нәтиҗәлелеге һәм куллану ышанычлылыгы буенча заман ихтыяҗларын канәгатьләндерә.

2016 елда КМҖБ тарафыннан серияле җитештерү башланганнан бирле 100нче ГПА эшләп чыгарыла.

Завод табигый газны табу һәм аны магистраль газүткәргечләр буенча транспортлау өчен каралган тулы комплектлы газ суырту агрегатларын (ГПА) серияле җитештерүче.

КМҖБ филиалы булган Яшел Үзән машина төзү заводы мәйданында ГПА чыгаруның барлык җитештерү этаплары үзләштерелгән. КМҖБ 25 МВт егәрлектәге төрле приводлы ГПАларны өйрәнүне дәвам итә.

КМҖБ заказчылары арасында: «Газпром» ГАҖ, «НОВАТЭК», «Роснефть», «Сибур», «Лукойл», «Сургутнефтегаз», якын чит ил компанияләре.

Реклама

КМҖБ инжиниринг проектларын соңгы ноктасына кадәр үтәп тормышка ашыра.

Газ сәнәгате һәм энергетика өлкәсендә комплекслы чишелешләр – компрессор станцияләре өчен җиһазлар тәкъдим итәлә. Гомумстанцион җиһазлы ГПАларны үзләштерү КМҖБнә көндәшлекле өстенлек бирә, чөнки нефть-газ базары операторлары чыгымнарны оптимальләштерү һәм югалту куркынычын киметү өчен, күбесенчә бер тәэминатчы белән контрактлар төзи.

КМҖБ импортны алыштыруга караган программаларда катнаша.

КМҖБ «Климов» ААҖ өчен ВК-2500 вертолёт двигательләре буенча импортны алыштыру программасы буенча эшли. Кооперация кысаларында һава стартерын, көч турбинасын, 3нче баскыч сопло аппаратын – двигательнең 30%ка якын өлешен әзерли. Ягулыкны янга калдыру һәм авырлык характеристикалары буенча двигатель иң яхшы дөнья стандартлары сафында тора. Перспективада Россия җитештерүендәге ВК-2500не илебез вертолётларының күпчелегенә урнаштырачаклар. 40%тан югарырак ФЭКна ия 25 һәм 32 МВт егәрлекле индустриаль типтагы бер валлы газ турбинасын булдыру өстендә эш алып барыла.



КМҖБ хезмәткәрләренең дүрттән бер өлеше диярлек – яшьләр.

Предприятиедә барлыгы 5 меңгә якын кеше эшли. Яшь хезмәткәрләрнең 60%тан күбрәге – эшче профессия вәкилләре, 13%ы – җитәкчелек вазыйфаларын башкара. Яшьләргә ярдәм аерым урында тора: өйләнешкәндә, бала туганда матди ярдәм, армиядә хезмәт итеп, кабат оешмага кайтучыларга ярдәм. КМҖБ үзенә кадрларны «мәктәп эскәмияләреннән» әзерли – профильле уку йортлары проектлары эшли.

КМҖБнең социаль һәм карарлар сәясәте бүләкләр белән билгеләп үтелгән.

Завод кешеләрен социаль яклау – өстенлекле урында. Бу – төрле ташламалар, гарантияләр һәм компенсацияләр, медицина һәм шифаханә-курорт хезмәте, уңайлы һәм куркынычсыз хезмәт шартлары, торак программалары.

Оешма «Россия бизнесы лидерлары: динамика һәм җаваплылык-2015» конкурсында – «Кадрлар потенциалын үстерү» номинациясендә, ә КМҖБ директоры ел саен үткәрелә торган «Ел җитәкчесе-2015» республика конкурсында «Югары социаль җаваплылык» номинациясендә җиңүче була.

Ел хәйриячесе

Предприятие шәһәр һәм республика хәйрия проектларына ярдәм итә.

Башкаланың 1000 еллыгына «КМҖБ» АҖндә Казан кремле эмблема-символы, Кремльнең каравыл манарасында урнаштырылган ЮНЕСКО билгесе коела. Предприятие Руханиагарту үзәге төзелешендә катнашты, ТР Мөселман Диния нәзарәтенә ярдәм күрсәтте. «Свияжск утрау-шәһәр» музееның фондларны саклау бинасы тулысынча компания эшчеләре тарафыннан реставрацияләнде. КМҖБ Казанның Урицкий паркын реставрацияләүдә катнаша. Завод «Ел хәйриячесе» республика конкурсында берничә тапкыр җиңеп чыга. Халыкара Хәйрия Фонды предприятиене «Йөзьеллык меценаты» дип таный.

PRESSA.RU

Вячеслав Югай,
«Газпром трансгаз Түбән Новгород» ҖЧҖнең генераль директоры

Данлы үткәннәрдән – матур киләчәккә

Хөрмәтле Дамир Җәүдәтович!
Кадерле ветераннар, хөрмәтле коллегалар!
Сезне «Казан моторлар җитештерү берләшмәсе» АҖ оешуның 85 еллыгы белән тәбрик итәм!

Сезнең юбилей – данлы тарихыбыз гына түгел, ә матур бүгенгебез һәм киләчәккә ныклы ышаныч та. Сез җитештерү берләшмәсе узган якты юл, берләшмәнең чишмә башында торганнарның исемнәре һәм бүгенге көндә җитештерелгән продукциягә ихтыяҗны, аның абруен тәэмин итүче кешеләр белән хаклы рәвештә горурлана аласыз.

Бүген «КМҖБ» АҖ – Россиядәге иң эре машина төзү предприятиеләренең берсе, ул НК-38СТ һәм ГПА-16 «Волга» двигательләре кебек заманча, югары технологияле һәм көндәшлеккә сәләтле техника чыгара. Берләшмә үзенең бүгенге дәрәҗәсенә ирешү, оптималь һәм нәтиҗәле эшләү, кадрлар потенциалын һәм матди-техник базасын ныгыту максатында олы юл үтте. Мотор төзүчеләрнең бүгенге уңышлары һәм казанышларының барысы да газ тармагы һәм, аерым алганда, «Газпром трансгаз Түбән Новгород» җәмгыяте өчен бик әһәмиятле.

Соңгы елларда безнең компанияләрнең уртак эшчәнлеге белән 25 ГПА-16 «Волга» гамәлгә кертелде. Тыгыз хезмәттәшлек нәтиҗәсендә без НК-38СТ приводлы двигателенең ышанычлылыгын арттыруга ирештек.

һәм 2016 елда «Газпром трансгаз Түбән Новгород» җәмгыятендә әлеге двигательләрнең максималь дәрәҗәдә эшләү вакытын 12 меңнән артыграк сәгатькә җиткерә алдык.

«Казан моторлар җитештерү берләшмәсе» АҖ безнең предприятиенең төп бурычын – «Газпром» ГАҖнең газ табу, аны транспортировкалау һәм җир астында саклау өлкәсендә җитештерү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү өчен югары сыйфатлы, көндәшлеккә сәләтле газ-турбина двигательләргә ихтыяҗын тәэмин итү буенча булышлык итүне оештыруда ышанычлы партнеры булып тора. «Починки-Грязовец» яңа магистраль газүткәргеч төзелеше безнең тыгыз хезмәттәшлекнең ачык мисалы булып тора.

Яңа Арзамас, Лукояновск, Вязников һәм Ивановодагы компрессорлы станцияләр иң кыска вакыт эчендә нәтиҗәле эшли торган «Волга» газ куу агрегатлары белән җиһазландырылды – алар экологиянең иң заманча таләпләренә җавап бирә, җылылык ягыннан нәтиҗәле һәм куллануда ышанычлы.

Дамир Җәүдәтович, Сезне һәм җитештерү берләшмәсенең барлык хезмәткәрләрен бәйрәм белән котлыйм! Сезгә һәм коллективыгызга алга таба уңышлар һәм тотрыклы эшчәнлек, яңа кызыклы проектлар, ышнычлы партнерлар телим! Иң изге теләкләр!

Реклама

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА ЭЛЕКТРОН ЮЛ БЕЛӘН ЯЗЫЛУ

PRESSA.RU САЙТЫНДА ОНЛАЙН ЯЗЫЛУ:



1. »ЖУРНАЛЫ» төймәсенә БАС



2. «ОБЩЕСТВО И ПОЛИТИКА» бүлегенә КЕР

3. «ТАТАРСТАН» журналына КЕР



4. «КУПИТЬ» төймәсенә БАС

Реклама 16+

ТИЗ / ҖИҢЕЛ / АРЗАН

PRESSA.RU

НОВАТОР, ЭШКУАР, ҖИТӘКЧЕ

Татарстан Республикасының һәм Россиянең иң озын гомерле проект институтларының берсе «Казан Гипронииавиапром» АҖ һәм аның «Казан Гипронииавиапром» Инжиниринг компаниясе» ҖЧҖ бүлендек предприятиесе, икътисадтагы тотрыксызлыкка һәм санкцияләргә карамастан, үсештә һәм бер-бер артлы инновацияле эшләнмәләр белән сөендереп торалар. Боларның күбесенә 2016 елның октябрендә 55 яшьлеген билгеләп үтүче Игорь Михайлович Дюгуровның күпьеллык фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә ирешелгән.

Татарстан Республикасында, Россиядә һәм чит илләрдә Игорь Михайловичны үз эшенең остасы буларак беләләр. Холкындагы һөнәри һәм шәхси сыйфатларның үзара керешүе аңа башлаган һәрбер эшендә уңыш китерә.

Игорь Дюгуров 1961 елның 13 октябрендә Казанда туа. Балачагы һәм үсмер еллары Яшел Үзәндә – оборона өчен машина һәм кораблар төзелеше үзәгендә уза – боларның барысы да аның киләчәктә нинди һөнәр сайлаячагына, гомумән, бөтен тормышына үз тамгасын сала. Аның холкы формалашуга фронтовик бабасы Иван Алексеевич Дюгуровның өлеше зур була. Ул Бөек Ватан сугышына солдат булып киткән, офицер булып кайткан, Берлинны алуда катнашкан. Иван Алексеевич Игорь Дюгуров өчен мәңге ныклык, намус, рух көче, кыюлык һәм һөнәргә тугрылык эталоны булып калачак.

Яшел Үзән механика техникумын тәмамлау белән, яшь белгечкә уңыш елмая – аны ракета гаскәрләренә – иң заманча техника тупланган урынга хезмәт итәргә җибәрәләр. Хезмәттән соң ул, үзенең командирларының киңәшен тыңлап, артиллерия маршалы М.Н. Чистяков исемендәге Казан ракета гаскәрләре югары хәрби команда-инженерлык училищесына укырга керә. Училищены тәмамлагач, лейтенант Дюгуров иң яхшылар исәбендә юллама белән ул вакытта Кораллы көчләрнең чит илләрдәге иң эре оператив-стратегик берләшмәсе – Германиягә, совет гаскәрләре төркеменә җибәрелә.

Биш елдан соң яшь хәрби инженерның икенче бер мавыгуы үзен белгертә – фән, техника, инженерлык эзләнүләре, икенче төрле әйткәндә, «инжиниринг» (сүз уңаеннан, ул техник үсештә аерым бер юнәлеш буларак, нәкъ менә артиллерия гаскәрләрендә барлыкка килә). Яшь командир хезмәтен дәвам иттерү өчен Казанга – команда-инженерлык училищесына кайтарыла, анда ул адъюнктураны тәмамлап, техник фәннәр кандидаты була. Реактив системаларны һәм танкка каршы артиллерия комплексларын конструкцияләү, проектлау һәм куллану кафедрасында укыта. Фән белән ныклап шөгыльләнүе һәм инженер буларак әзерлеге, спортка мәхәббәт белән бергә (Игорь Михайлович хезмәт иткәндә спорт белән шөгыльләнә һәм хәрби спортның өч төре буенча «Спорт мастеры» квалификациясен ала), чын профессионалга армияне һәм оборона сәнәгатен үзгәртеп кору елларында югалып калмаска мөмкинлек бирә.

Спорт һәм фән Игорь Михайловичта җитәкчелек сыйфатлары, үз өстеңә җаваплылык алу сыйфатларын тәрбияли. Армиядән китеп, Игорь Михайлович үзенә яңа икътисадта да урын таба: «Тулпар» авиакомпаниясендә үсеш буенча генераль директор урынбасары, «Казан Гипронииавиапром» ААҖндә генераль директор урынбасары, «ТАТАВИА-СЕРВИС» фирмасында коммерция директоры булып эшли.

Үсешкә ихтыяҗ, перспективалы юллар эзләү Дюгуровны яңа үрләргә этәрә. 2009 елда Игорь Михайлович иң эре проект институты – «Казан Гипронииавиапром» эшчәнлегендәге яңа юнәлешнең «әтисе» булып китә. Төп эше белән параллель рәвештә ул «Казан Гипронииавиапром» Инжиниринг компаниясе» ҖЧҖ компаниясен дә җитәкли башлый.

Россиядә иң эре машина төзү предприятиеләре арасында лидер буларак, «Казан Гипронииавиапром» институтта эшләнгән проектларга туры килә торган иң заманча технологияле җиһазлар юнәлешен үзләштерә. Соңрак оптималь техник процесслар белән дә шөгыльләнә башлый.

Һәм яңа катлаулы эш шартлары – тышкы икътисадый вазгыятьнең кискенләшүе, Европа берлеге санкцияләре – Игорь Михайлович өчен

Реклама

киртә түгел, ә алга таба сикереш ясау өчен этәргеч була. Борис Иванович Тихомиров булышлыгы белән ул яңа – заманча җиһазлар җитештерү эшен Россиягә күчерү проектының илһамчысы һәм генераторы була. Катлаулы һәм күп тапкырларга сузылган сөйләшүләр барышында «Казан Гипронииавиапром» компанияләр төркеме 2005 елда Кытайның «Политехнолоджи» корпорациясе Dongling (Д ОНГл ИНГ) компаниясе белән берлектә Казанда климат һәм вибростенд камералары җитештерә башлый. Проектның зачончалыклы төстәге уңышы булып 2016 елның августында «АКТО-2016 – Авиакосмик технологияләр, заманча технологияләр һәм материаллар» күргәзмәсе кысаларындагы тәкъдир итү чарасында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановның катнашуын санарга була. Игорь Дюгуровны кыенлыклар да, киртәләр дә туктата алмый, ул яңадан-яңа идеяләр белән яши. Шуларның берсе – авиация сәнәгате эшләнмәләре өчен инновацияле саклау өслекләре – «Казан Гипронииавиапром» тарафыннан оештырылган яңача җитештерүдә гамәлгә куела башлаган да инде. Җиһазлар сатып алынган һәм сафка куелган, заказ бирүчеләр актив рәвештә «ишек шакый» башлаганнар – алар арасында оборона сәнәгатенең эре җитештерүчеләре дә бар.

Балачак хыяллары һәм үсмер чагындагы мавыгулары чынга ашкан кешеләр, гадәттә, бәхетле була. Совет чоры оборонасы атмосферасында үскән Игорь Михайлович та, вазыйфасы буенча ракеталарга хезмәт күрсәтүгә катнашып, самолетларга очарга ярдәм итеп һәм авиация сәнәгатен модернизацияләп, закончалыклы рәвештә бүгенге көндә иң югары мөнбәрләрдән сөйләнә торган сүзләрне гамәлгә ашыруга ирешкән. Бу сүзләр безнең өчен инновацияле үсешнең, инжинирингның һәм яңа технологияләрнең бердәнбер юл булуы турында сөйли.

Игорь Михайловичның дуслары һәм хезмәттәшләре, аның турында сүз чыкканда, холкының көтелмәгән бер сыйфатын әйтми калмыйлар. Ул – романтик, диләр. Тыштан кырыс күренсә дә, хезмәт вакытыннан калган «командир тавышы» саклanca да, ул, үсмерләрчә романтикага бирелеп, хатыны Елена Петровнаны, кызлары Анастасия белән Александраны ярата. Мөгаен, нәкъ менә аларның яратуы һәм кайгыртуы, алар өйдә тудырган тыныч атмосфера Дюгуровка уңышларга ирешергә, кыенлыклар белән көрәштә җиңеп чыгарга ярдәм иткәндер. Игорь Михайловичның уңышлары төрле яклап билгеләнә, рәсми бүләкләре дә, бизнес җәмәгатьчелекнеке дә бар: «Намуслы салым түләүче – 2013» Милли салым премиясенең лауреаты дипломы, «Тармак лидеры – 2014» Милли сертификаты, Эшкуарлык башлангычлары фондының Мактаулы әгъзасы сертификаты. Dongling компаниясенең бүләкләре: «Most improved Revenue growth Award» (Керемнәрнең прогрессия белән үсеше премиясе), «Sales Performance, 3rd Place, (Нәтиҗәле сату буенча бронза премия), «Ел бизнесмены – 2014», «Икътисад горурлыгы – 2015», «Импортны алыштыру – 2016».

Игорь Михайловичның үзе өчен Россиянең оборона сәнәгатен яңартуда катнашуының нәтиҗәләре мөһим. Аның җитәкчелегендә Королев шәһәрендәге «Корпорация «Тактическое Ракетное Вооружение» АҖнә, «Позис», АҖнә «ПО «УОМЗ» им. Яламова» АҖнә, «УПКБ «Деталь» ААҖнә, «Красный Гидропресс» АҖнә, «СмАЗ» АҖнә, «РКБ «Глобус», ААҖнә, «Утес» ААҖнә, «Тамбовский завод «Электроприбор» ГАҖнә, АНПП «ТЕМП-АВИА» ГАҖнә, «Наука» ФҖБнә заманча җиһазлар эшләп җибәрелгән.

«Казан Гипронииавиапром» компанияләр төркеме коллективы яраткан җитәкчесен юбилее белән котлый. Ныклы сәламәтлек, бетмәс-төкәнмәс егәр, яңа проектлар, барлык башлангычларыгызда уңышлар телибез! Без Сезне ихтирам итәбез һәм яратабыз!

PRESSA.RU

Риваятьләр темасын дәвам итеп, Әлки районының Иске Баллыкүл авылына юл тотабыз. Бирегә килгәч, үзе татлы да, үзе моңсу да бер хикәят сөйләделәр. Роберт Стивенсонның «Арчан балы» дип аталган шотланд балладасын хәтерләтте ул безгә.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: БАЛЛЫ КҮЛЛӘР

Иске Баллыкүл авылында кояш аеруча якты, әйтерсең, баллы нурлар тарата. Һәрвакыт. Хәтта кыш көне дә. Җирле җан ияләре дә – төрледән-төрле төсмерләрдә чагылган бал төсендә. Тавыклар – карабодай балы, әтәч – карамельләнгән бал төсле, этнең йоны юкә балы сыман уйнаклый, әнә, авыл башыннан арчын балы төсендәге сыерлар көтүе кайтып керде... Башка төстәге терлекләр монда бөтенләй юк кебек.

Авылның исеме Баллыкүл булгач, гаҗәпләнәсе дә юк. Тавыклар, әтәчләр, этләр, сыерлар суны күлләрдән эчә бит, шуңа күрә алар бал төсле, дип аңлата авыл кешеләре. Авылда, чыннан да, күпсанлы күлләр җәелеп ята, аларның исәбен биредә яшәүчеләр үзләре дә төгәл белми: кайсы – биш, ди, кайсы – җиде, егерме диючеләр дә бар. Безгә сөйләнгән матур риваять тә шушы күлләр белән бәйле булып чыкты.

– Элек, әле сыерлар булмаганда, димәк, сөт тә юк чакларда, шушы күлләрдәге суны эчкәннәр, – дип аңлата башлады Габбас бабай. – Бик тәмле булган сулары, татлы...

– Аларның төбенә умарталар төшеп киткән бит, менә шуннан соң күлләр балланган да инде, – дип өсти Мәгъдән бабай. Ә инде умарталарның күл төбенә ничек төшеп китүе турында безгә яшьрәк буыннар сөйли, алар исә үз әби-бабайларыннан ишеткәннәр. Менә ул риваять:

«Революциягә кадәр биредә бер бай яшәгән. Аның бик күп умарталары, бал кортлары, димәк, бик күп балы да булган: юкә, карабодай, чәчәк, арчан баллары. Баллы мичкәләр, чүлмәкләр белән базлары тулып торган һәм бөтен авылга ел әйләнәсе җәй исен тараткан. Яхшы яшәгән бай – мул һәм татлы яшәгән. Бөтен авыл да татлы яшәгән, зарланмаган. Һәм, билгеле инде, яңа хакимиятнең килүе байның милкенә юкка чыгу белән янаган. Большевиклар байларны яратмаган бит. Өстәвенә, күрше авылда бар нәрсәне туздырып ташлаулары, умарталыкларны яндырулары турындагы хәбәр дә килеп ирешкән.

Баллы бу мөлкәт большевикларга тәтемәсен өчен, бай җирле сихерчегә мөрәҗәгать иткән. Сихерче дигәннәре кара урманда яши һәм, бик кирәк булмаса, күренеп тә йөрми икән. Хәлне аңлаткан, күп акча вәгъдә иткән моңа бай. Сихерче карчык көлемсерәгән дә коедан алган бер чиләк су өстенә үзенең ниндидер сихер сүзләрен пышылдаган. Сихерләнгән судан байга да өлеш чыгарган, һәм шуны таң атканда бөтен умарталарга сибеп чыгарга кушкан. Бай ул әйткәннәрне төгәл үтәгән. Шуннан соң бөтен умарталар, сихерләнгән кебек (шулай булган да бит инде!), кортлары-ниләре белән бергә су төбенә төшеп югалган.

Тарихта кабатлану очраклары еш очрый. Хәтерлисезме:

Ә учак мине куркытмый,
Минем белән үлсен, әйдә,
Минем ачы арчын балым –
Һәм ачылмас серләрем дә...

Фото: Ләйсән Илһамова.

Узып киткән җәйнең соңгы җәнлеге: таптык, җылыттык, җибәрдек...

АЙ КӘЕФЕ: ГӨМБӘЛЕ КӨЗ

Быелгы көз гөмбәгә бай гына түгел, бик бай булып чыкты. Гөмбә җыярга һәвәсләр, юл читләрендә матур итеп машиналарын тезеп калдыралар да урманда яшиләр диярлек. Кояш баеганда гына, канәгать булып, пәрәвезләргә уралып, киемнәренә чәнечкеләр ияртеп, әмма һичшиксез бер-ике кәрзин гөмбә белән әйләнеп кайталар. Нинди генә затлы гөмбәләре юк анда: аклары, каен, усак гөмбәләре – гаҗәп матур күренеш!

Гөмбә авы, яшенә һәм җенесенә карамастан, һәммә кешене үзенә буйсындыра. Ә гөмбә белеме нәселдән күчә, кан белән, генетика дәрәҗәсендә. Шуңа күрә чын гөмбәче агулы гөмбәне җыймый, чебен гөмбәсе белән агуламый, шартлы рәвештә ашарга яраклы гөмбәне ашарга яраклысы белән бутамый, ялган төп гөмбәсен чын гөмбә дип кәрзингә салмый.

Һәм менә ау тәмам, рәхәт өлеше артта калды. Алда «ганимәтләрне» эшкәртү өчен озакка сузылачак эш көтә. Тик чын гөмбәчегә монысы да шатлык кына – күпсанлы тозлы һәм маринадлы гөмбә банкалары, җепкә тезеп киптерелгән гөмбәләр, пластмасс контейнерларда туңдырылганнары – уңган халыкның күңелен күтәрә, һәм «запас» көннән-көн тулылана бара, ни дисәң дә, «чоланнарың» тулы булса – кыш көнендә тук булырсың.

Шулай итеп, соңгы гөмбә санын исәпләүләргә караганда, Татарстанда быелгы көздә әзерләнгән:

548 тонна маринадланган майлы гөмбә;

489 тонна маринадланган төп гөмбәсе;

621 тонна маринадланган ак гөмбә;

347 тонна тозланган гөреҗдә;

324 тонна тозланган волнушка;

501 тонна кыздырылган каен һәм усак гөмбәләре;

220 тонна киптерелгән гөмбә;

335 тонна гөмбә уылдыгы;

218 тонна туңдырылган гөмбә.

«Чоланнар» тулы!

PRESSA.RU

www.protatarstan.ru
Реклама 16+
РУС | ТАТ
ТАТАРСТАН
Иҗтимагый-сәяси басма
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
мәңгелек
Мирасын халык үзе барлады
Сәяхәт итәргә яратучы фестиваль
Акмаңгай
WWW.PROTATRSTAN.RU